

Рәниф Шәрипов



# Мәңгелек сер

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2005

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)—5
Ш 95

**Шәрипов Рәниф**

Ш 95 Мәңгелек сер: Шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 191 б.

Әлеге китапка шагыйрьнең төрле елларда язылган нечкә лиризм белән сугарылган, уй-моңнарга бай шигырьләре тупланды.

ISBN 5–298–04074–8
© Татарстан китап нәшрияты, 2005
© Рәниф Шәрипов, 2005


Шигырьләр

# ҖЫР БАШЛАГАН ИДЕК

## *Авыл моңы*

Авылымнан читкә мәшәкатьсез дөнья,
Гамьсез тормыш эзләп китмәдем.
Хәтеремдә саклыйм ашап үскәнемне
Бу кырларның арыш икмәген.
Туган җирнең зур тарихын миңа җырлар
Китаплардан күбрәк сөйләде.
Күңелемдә һаман үзем тыңлап үскән
Авылымның моңлы көйләре.
Күрдем беркөн: таза куллы тимерче карт
Гармун уйный агач сәхнәдә.
Һәм уйладым: «Менә тормыш хакыйкате
Мәкерсез, саф, олы мәгънәдә».
Юк, беркем дә, ахры, авылыннан читкә
Җиңел тормыш эзләп китмәде.
Тән азыгы әллә җан азыгымы соң
Кирәк вакытында җитмәде?
Чит җирләрдә кемнәр бәхет тапкан икән,
Булса да чит дөнья бизәкле?
Онытылмый бит кечкенә тальян гармун,
Сагындыра, өзә үзәкне.
Еллар үткән саен күбрәк сагындыра,
Юаныч юк башка мәгънәдән.
Күрәсезме, авылдашлар, карт гармунчы
Төшеп килә агач сәхнәдән?
Ул һаман да күз алдымда минем,
Хәтеремнән ерак китмәдем.
Төн буена кайчак тыныч йоклый алмыйм,
Эшләп ашасам да икмәгем.

*1983*

# Ай, былбылым

Ай, былбылым, ай, былбылым,
Кызарып таңнар ата.
Тынгысыз көн, йокысыз төн
Уйлата да уйлата.

Ай, былбылым, ай, былбылым,
Ник борчулы бу таңнар?
Җил куба да яңгыр ява,
Сыгылып төшә таллар.

Ай, былбылым, нәрсә яңгыр,
Бер ява да, бер тына.
Дөнья тынмый, кунып сайрар
Тал агачлары сына.

Ай, былбылым, ай, былбылым,
Кызарып кояш бата.
Ерак былбыл тавышлары
Уйлата да уйлата.

*1983*

# Асылъяр

Әйдә барыйк сахраларга,
Гөлләр үбик, Асылъяр.
Күккә карап, җирдә ятыйк,
Алҗыдым бик, Асылъяр.

Кызу тормыш юлларыннан
Гөрләп үткән чагыбыз.
Моңлы-зарлы гомер буйлап,
Еллар сүткән чагыбыз.

Әйдә барыйк сахраларга,
Гөлләр урик, Асылъяр.
Мәшәкатьләрне онытып,
Җырлап йөрик, Асылъяр.

Кайда калды гөлләр кебек
Гөрләп үскән чагыбыз?
Өзә-өзә сөю багып,
Гөлләр үпкән чагыбыз?

Әйдә барыйк сахраларга,
Гөлләр күрик, Асылъяр.
Еллар сабырлыгын кушып,
Хисләр урик, Асылъяр.

Кызу тормыш юлларыннан
Гөрләп үткән чагыбыз.
Яшьлек туй иткән сахрада
Гөлләр үпкән чагыбыз.

*1983*

# Бердәмлек

Без бу чорга гармун моңы белән кердек,
Әниләрнең чабаталарын яшердек.
Без – авылдан. Үз бәябезне беләбез,
Килде көннәр калаларга тиңләшерлек.
Карап тордык беркөн, туган якта гына
Яшьләр бии яңа заман такмагына.
Читен түгел: билең борып, кулың болгап,
Алга-артка, уңга-сулга атла гына.
Дөнья безгә артык шәфкать күрсәтмәде,
Ә яшьләрнең кигән чалбар-күлмәкләре,
Килешләре, рәвешләре – барысы да
Каладагы соңгы мода үрнәкләре.
Тынды такмак. Менә егет гармун алды,
Әйлән-бәйлән уртасында басып калды,
Тынып калган бар авылга, үзебезчә,
Бик борынгы, бик тә моңлы аваз салды.
Халык моңы безнең канда тумыштан ук,
Эш белгәннең җыры моңлы, уены шук.
Тыпыр-тыпыр үзебезчә кызлар бии,
Ялындыру һәм оялу истә дә юк.
Ә каладан килгән кунак егетләре,
Вак сәнгатьтә «олы белгеч» кебекләре
Көлемсерәп күзәтсәләр дә кызларны,
Бар иде бар күзләрендә өметләре.
Күңел тулып, килдем шунда бер фикергә:
Моң сафлыгын тамырларга җир яшергән.
Түргә чабата элсә дә, зур калага
Ерак әле авыл белән тиңләшергә.

*1984*

# Галиябану

Күңелләргә моңнар сал да
Мәңгелеккә илдә кал.
Хәтерсез таш йөрәкләрне,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Гамьсезлектән тартып ал.

Тәрәзәңне ачып куеп,
Кемне эзли күзләрең?
Ялгыз карашыңны тоеп,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Шигырь яздым, түзмәдем.

Көткәнеңне күрмисең дә,
Күзең тала, арыйсың.
Җырга күчеп, еллар кичеп,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Һаман безгә карыйсың.

Һаман безгә карыйсың да,
Карап кемне таныйсың?
Безнең җырларның кайсысын,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Үзеңә тиң саныйсың?

Сөюләрне моңга сал да,
Күңелләрдә мәңге кал.
Бүләк итәм шигыремне,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Еллар аша тартып ал.

*1983*

# Ерак вальс көе

Ерак вокзаллар иле,
Сагышлы еллар иде.
Озак озату көне,
Сагышлы вальс көе.
Ерак вокзаллар тынды,
Күпме язмышлар сынды,
Килде кавышу көне,
Өметле вальс көе.

Кушымта:

Әйләндек, көйләп тә, җырлап та,
Әйләндек, көлеп тә, елап та,
Йөрәктә, тик йөрәктә калган
Саф мәхәббәт биюен.

Ялгыз аналар иле,
Алар әле яшь иде.
Сүнмәс өметләр көне,
Йөрәктә вальс көе.
Кемдер өметен күмә,
Кемдер саргая, сүнә.
Кара ялгызлык төне,
Еракта вальс көе.

Кушымта:

Чакыра, көйләп тә, җырлап та,
Юксынып күпләрне елап та,
Йөрәктә, тик еракта калган
Саф мәхәббәт биюе.

Ятим балалар иле,
Үсеп баралар инде.
Кичке уеннар төне,
Кайда син, вальс көе?

Коры куаныч мәллә,
Олы юаныч мәллә
Безгә бу Җиңү көне?
Сагышлы вальс көе...

Кушымта:

Биегез, көйләп тә, җырлап та,
Көлеп тә, уйнап та, зурлап та,
Еракта, бик еракта калган
Саф мәхәббәт биюен.

*2000*

## Кара урман

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Ябык еллар, авыр замана.
Ахры, кемдер юлдаш таба алмый,
Урман буйлап килә, зарлана.

Юкка түгелдер лә җырга кергән
Кискән пар каен һәм пар усак.
Өметкәйләре лә, һай, бик гади –
«Аерылмаек, дустым, дус булсак».

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Авыр еллар, ерак замана.
Кемдер ялгыз, дус-иш таба алмый,
Еллар буйлап килә, зарлана.

*1983*

# *Идел бит ул*

Идел бит ул, Идел бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Су буйларын моңга күмгән
Үз халкына тиң бит ул.

Еллар буйлап ага бу көй,
Моңы тормыш ярында.
Көй язганы ерак калган –
Җырның аргы ягында.

Безнең яктан җырлый берәү,
Килеп моңлы елгага.
Ике якта ике җырчы,
Ә уртада моң ага.

Ул елгага мин дә килдем,
Учлап-учлап су эчтем.
Гүя аргы якта калган
Җырчы белән күрештем.

Идел бит ул, Идел бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Сагышлы, моңлы, егәрле,
Үз халкына тиң бит ул.

*1983*

# Җырчы

1

Нинди уйлар уйлап, кинәт кенә
Киерелде кыйгач кашларың?
Бу борынгы көйне башың тотып,
Күзләреңне йомып башладың.

Сәхнәсез бу дөнья читлегендә,
Башны салып ерак көйләргә,
Тыелгысыз хыял сагышларын
Кайда, кемгә, кемгә сөйләргә?

Онытып тор сәхнә кануннарын,
Рәвеш түгел монда, моң түрә.
Ялгышларың һәркем белеп тора,
Сагышларың тагын кем күрә?

Барысы да ялган бу дөньяда,
Тормыш та бер ахмак саташу.
Мәхәббәт тә, акыл да чын түгел,
Тик яшәгән булып маташу.

Алкышлар да мескен мизгел генә,
Пәрдә ябык. Тагын ялгызлык.
Тагын тынлык. Тагын чолгый безне
Надан коткы, гайбәт, явызлык.

2

Нигә чиксез моңлы безнең көйләр,
Тын җитмәслек салмак агышлы,
Читлектәге торткын җыры кебек,
Бер өметсез тыйнак сагышлы?!

Көннәребез кәккүк авазында,
Дәвамыбыз да чит ояда.
Рәшәткәле күккә карый тоткын,
Маңгай тирен сөртеп куя да.

Җир югалган, ил буталган инде,
Тир булса да якты йөзендә.
Яшь киленнәр кебек тел яшерә,
Җыр булса да күңел төбендә.

Җырла әйдә бабаңнарның көен,
Җыр булганда әле өмет бар.
Чит эзләрдән телгәләнгән җирнең
Сагыш авазларын белеп кал.

Авазлары моңлы дога кебек,
Бу моң бездә җырга санала.
Кыйбла юлга чыкканыңны көтеп,
Тыңлый сине Ходай Тәгалә.

*1989*

# Моңлану

Көйләде ул, җырлады ул,
Сәер авазлар чыгарды.
Кыпчак далалары буйлап,
Болгар шәһәренә барды.

Яу артыннан яулар килгән...
Кемнең кемнән бу баласы?
Хәтергә очып кердеме
Үткәннәрнең бер авазы?

Карыйм аңа, бергә кушып
Борынгы белән бүгенне.
Җырлый белми күпләр җырлый,
Җыр тамыры шул түгелме?

...Сиздe җырның көйсезлеген,
Әйтте шуннан, миңа дәшеп:
«Җыр түгел бу, көй түгел бу,
Моңлану бу, энекәшем...»

*1988*

# «Оштырма» көе

Шәмсегаләм апа, син җырлаган
Нинди матур көй бу борынгы?
Күпме еллар ничек саклап килдең
Бу «Оштырма» дигән җырыңны?

Сәхнәләрдән элек җырланмаган,
Бай йортларда түргә узмаган,
Бу бит халык җыры, халык моңы,
Күпме җырланса да тузмаган.

Кеше белән кайчак җыр да үлә,
Кеше белән яши исәне.
Аз түгелдер картлар белән үлгән
Без белмәгән җырлар исәбе.

Бармы тагын истә тотучылар
Халыкның бу моңлы гозерен?
Җыр гомерен халык башласа да,
Җырлар үлчи халык гомерен...

*1985*

# Саба Жырчысы Рисәнә Мостафинага

Алып килә миңа җилләр
Моңлы бер җыр,
Кара урманнардан
Чыгып исә дә.
Сабаларда җырлый бер сандугач,
Исемкәйләре лә Рисәнә.

Чорлар җиле, татар җирен
Айкап килеп,
Бәгырькәйләремне кисә лә.
Кайдан килгән безгә
Шомлы, гүзәл бу моң?
Шаулый урман...
Җырлый Рисәнә...

*2003*

# Соң башланган җыр

*Апам Люциягә*

Җыр башлаган идек. Тик баштарак
Җырламадык карап нәрсәгә?
Җыр башлаган идек. Соңга калдык.
Башка җырлар инде сәхнәдә.
Хак Тәгалә читтән карап торды,
Язмыш белән һаман сынады.
Каерылып күпме сыгылсаң да,
Моңлы күңел җиңел сынамы?
Ул да сизде беркөн, «җырла!» диде,
Күктән сәер, сихри моң иңде.
Бер юаныч бирде, ансына да
Гомер узган иде, соң иде.
Җыр башлаган идек. Өзелгән җыр
Тынгы бирми һаман күңелгә.
Буылган моң ыңгырашып ята...
Соң түгелдер, бәлки, бүген дә?
Җырга бай без. Мөлдерәмә күңел.
Җан асрадык ипи-сөт өчен.
Залда башка халык. Яшьләр җырлый
Тормышның буш имеш-мимешен.
Үткән икән, үтсен инде гомер
Үкенечле сагыш моңында.
Өзелгән җыр өчен, читтән карап,
Бер еларбыз тагын соңыннан.
Җыр башлаган идек. Сәхнәләрдә
Аңлашылмый торган моң инде.
Җир үзгәргән, дөнья да чит, бүтән,
Гомер узган инде, соң инде.
Кайсы чиктән, әллә күктән килә –
Читтән керә аваз колакка:
«Җырла, кызым, җырла!» – дигән кебек,
Ә без инде ерак... еракта.

*1990*

# Ташып чыккан моң

Җырлый-җырлый әни оек бәйли
Керосинлы лампа каршында.
Тышта буран, кайчак тынып кала,
Җыр туктагач куба тагын да.

«Чишмәләр дә акмый тыңлады»,– дип
Күтәрдеме мине шигъри моң?
– Нинди көй бу, әни?
– «Рамай», улым,
Ник елыйсың? Йокла, инде соң...

Йомгак белән башны башка куеп,
Йоклап киттем, башка дәшмәдем.
Кипте тиздән, тарихлардан килеп
Ташып чыккан, саф күз яшьләрем.

Җилкендереп һәм тетрәтеп җанны,
Таян, диеп, шушы терәккә,
Моңнар фәрештәсе бер каурыен
Кадап китте нәни йөрәккә...

*1983*

# Халкым җырлары

Бала идем, әнкәм җырлаганда
Халкыбызның моңлы көйләрен,
Кыскартырга теләп кышның озын,
Хәсрәт кебек салкын төннәрен.

Озак вакыт аңлап бетермәдем
Бу җырларның моңын, сагышын,
Күзләремне йомып тыңламадым
Гасырлардан килгән тавышын.

Килде бер көн, бик еракта идем,
Туган җирдән моңлы сер булып
Килгән көйләрне бер ишеттем дә
Мин аңладым... барысын берьюлы!

Кузгалдылар күкрәк сөте белән
Канга сеңеп калган бу көйләр.
Онытылып тыңлыйм... Әнкәм сагышын
Җыр булмыйча миңа кем сөйләр?..

*1980*

# Хафизәләм, иркәм

Нинди матур сүзләр бәйләме бу –
«Хафизәләм, иркәм, аппагым».
Күпме җырлар тыңлап карадым мин,
Тик назлырак сүзләр тапмадым.

«Хафизәләм, иркәм, аппагым...» – дип,
Кемдер сиңа гыйшкын сөйләгән.
Сүзләр моңын тыя алмаган да
Сөюен җыр итеп көйләгән.

Күзем йомсам, күз алдыма килә:
«Хафизәләм, иркәм, аппагым».
Бер ишетеп гашыйк булдым сиңа,
Ягымлырак көйләр тапмадым.

«Хафизәләм, иркәм, аппагым»,– дип,
Мин дә сиңа гыйшкым сөйләдем.
Моңсу чакта бик күрәсем килгәч,
Күзем йомып җырың көйләдем.

*1982*

# Һаваларда очкан кошлар кебек

Язлар җиткәч, һаваларда кошлар
Очкан кебек туган ягына,
Көйсез йөрәк хәлсез талпына да
Ерак каеннарны сагына.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары җилдә сынамы?
Йолкыса да язмыш канатларны,
Ярсу йөрәк сүзсез тынамы?

Яз аенда һаваларда кошлар
Каурыйларын җиргә коялар.
Хәтта кошлар – адәм ничек түзсен! –
Туган якның көчен тоялар.

Бер җигелгәч тормыш арбасына
Сизелми лә гомер узганы.
Һаваларда кошлар, җирдә дуслар,
Канатларда чит җир тузаны...

*1981*

## ИЛ ЭЧЕНДӘ ИЛ

### *Арба*

Арба ватык, көпчәк черек, юл җимерек,
Кучерлары йә зиһенсез, йә исерек.
Алашасы шыр сөяктән, көчкә атлый,
Чыбыркыдан курыккан да солы капмый.
Чат саен юлчы җыйганнар акча сорап,
Юлчылары төшәр иде – ара ерак.
Иелгән баш, сыгылган сын – кем сурәте?
Ахры, безгә менә шулай көн күрәсе.
Камчы уйный, ничек әле ат чыдаган,
Әләгә ул баш күтәргән юлчыга да.
Уртак телдә, ялган сүздән, катнаш җөмлә,–
Димәк, кучер нәрсә дисә, шуны тыңла.
Китәм, дисәң, беркемне дә җибәрмиләр,
Акча түләп киләбез, тик гел әрлиләр.
Йә елыйбыз, йә җырлыйбыз, йә эчәбез.
Туктатыгыз арбагызны, без төшәбез!
«Төшегез!» дип җикерде дә бер исерек,
Орды берне, авыз-борынны җимереп.
Нәтиҗә шул – тешсез авыз, шешкән күзләр,
Җиде бабаң, әткәң-әнкәң тулы сүзләр:
«Беренчедән, төшәбез дип, кымшанма да,
Икенчедән, һәрбер сүзгә ышанма да,
Өченчедән, хуҗа дигән сүз бар әле,
Дүртенчедән, тел кычытса, узар әле,
Бишенчедән, алтынчыдан, җиденчедән...
Кыскасы, түз, тешсез авыз белән чиләнм.

Әгәр тыеп булмый икән бу теләкне,
Кур, күпме баш көпчәк астына эләкте...»

Кәперәеп камчы тоткан – кем сурәте?
Бу – бәхетсез юлчыларның бер түрәсе.
Камчы уйный, арба чаба алга таба,
Кан тамчысы тама... тама... тама... тама...

*2001*

## Гармунчы карт монологы

Гармун уйныйм, ә күңелдә сагышлы моң,
Тиңсез көйләр ятим кала, нишләргә соң?
Эшләдек тә, җырладык та кирәк чакта,
Моңлы булдык, горур булдык туган якта.
Туып үскән, чәчеп урган җиребез бар,
Җир йөзендә хур булмаслык җырыбыз бар.
Саклый белдек иске көйләр хәзинәсен,
Беркем илсез килмешәкләр бу, димәсен.
Гомер үтә, картлар бетә, заман башка,
Бу көйләрне белүче юк миннән башка.
Гомер чиге якынлаша. Яна йөрәк.
Әй, оланнар, сезгә дә бу көйләр кирәк!
Туган телен, туган җырын онытканнар –
Туң йөрәкле, фәкыйрь, гарип, сынык җаннар.
Җырсыз, моңсыз, нәселсез һәм тарихсыз, тук
Гамьсезләрнең беркемгә дә кызыгы юк.
Булмас аңа таянучы, булмас аның таянычы,
Килми калмас сынык җанга хәтерсезлек аянычы.
Кабатланмас көйләребез – хәзинәбез.
Җырлый белсәк, беркемгә дә баш имәбез.
Гармун уйныйм, ә күңелдә сагышлы моң –
Бу гармунны кайсыгызга тапшырыйм соң?..

*1985*

# Демократик мокытлык

Бүген безне хәрефләп сүтәләр,
Инде татар дигән сүз калмый.
Газиз әнкәң телен буасың бит,
Татармы син, әллә шакалмы?

Алтын балык тоттың. Ник дәшмисең?
Тагарагың шуңа ярыкмы?
Ачык капкаларга карап каткан
Халыкмы син, әллә сарыкмы?

Тәлинкәләр ялап йөрисеңме?
Хуҗаларда һаман мәҗлесме?
Байрагыңа абзаң аяк сөртә,
Шәхесме син, әллә нәҗесме?

Тарихыңда канлы каргыш исе,
Денсезләргә иман кирәкми.
Урыс түгел, татар түгел, кем син?
Милләтме син, әллә имгәкме?

«Кол калсагыз – мәңге минем дә
Сөякләрем сызлар гүремдә...»*
Шагыйрь – гүрдә. Ята ыңгырашып...
Ә имгәкләр көләч бүген дә.

*2000*

* Рәшит Әхмәтҗанов шигыре.

# Казан утлары

Аяз төндә җәяү юлга чыксаң,
Алдыңда юл булса нибары,
Күк читендә таң нурлары кебек,
Балкып торыр Казан утлары.

Таш коймалар, таш урамнар анда,
Хәтер белән Вакыт сугышы,
Җилләр булып урамнарда йөри
Гасырларның ерак сулышы.

Түбә саен, яу билгесе кебек,
Чит патшаның алтын чукмары.
Янәшәдә ятим бер манара –
Күкне тишеп баскан ук бары.

Манаралар ауган канга батып,
Җылы мәетләргә абынып.
Нигезенә кабер ташы салган,
Яши икән кемгә табынып?

Төнгә калдык, соңга калдык инде,
Бер генә юл алда нибары.
Күк читендә, соңгы өмет кебек,
Балкый әле Казан утлары.

Ә Тарихны төзәткәләп булмый,
Күбәләктәй утка ашкынып.
Мәңгелеккә бездә бу Хакыйкать,
Нигезләрдә яткан таш кебек...

*1985*

# *Вак мәшәкать*

Телләр озын безнең телләшергә,
Сүзләребез генә кечкенә.
Сүзләр китәр безнең белән бергә,
Ә Хакыйкать – бары Эш кенә.
Урын белән исем бүлешкәндә
Онытабыз халык турында.
Кушылырга сүзгә ирек бирми
Изге каләм фәкыйрь кулымда.
Ләкин бөек халык, моңлы халык
Бу хурлыктан ерак, бик ерак.
Еллар саен бушап, моңга сусап,
Карап тора безгә аптырап.
Ни гаебе аның безнең алда?
Ни укыган? Эзләп ни тапкан?
Миллионлап хәзер йөз чөерә
Меңәр-меңәр чыккан китаптан.
Укымый да, һаман такмак тыңлый,
Һаман бәйдә, һаман бил бөгә.
Бер дулый да, тагын тынычлана,
Кыскара тик бары дилбегә.
Сүз уйната белә бүген кем дә,
Сүзләр генә безнең арада.
Янгын сүнгән җиргә печ итәргә
Йөгереп килә сабый бала да.
Корыйбыз да кибәбез без бүген,
Тамырлар да көн дә өзелә.
Бетеп бара сөйли белүчеләр
Туры карап халык йөзенә.
Күтәрелсен күзләр, халык – бөек,
Күренми тик кәрлә түбәндә,
Пәһлеванның итек кунычына
Әшәке сүз язып киткәндә.
Моңнар көткән халык күз алдында

Бу мәшәкать артык кечкенә.
Эшләр беткәч, калмасмы соң бездән
Чыпчык булып очкан сүз генә?

*1986*

## *Ил*

Ил эчендә ил,
Җил себергән җир,
Җир астында ут.
Ярсып ала янар таулар –
Фәүзия, Зәки, Айдар...
Рәшит кенә янып бетте,
Рәшит кенә инде юк,
Көле һаман да кайнар.

Көл суына, таулар тына,
Кайда сез, яңа байлар?
Борчымыймы сезне бер дә
Догасыз үткән айлар?

Каргыш иле,
Сагыш җире,
Кем үлә,
Кем уяна.
Көл суына...
Тик онытма,
Тау астында ут яна!..

*2001*

# Кыйбла

Дүрт юнәлеш җирдә. Тик кыйбла юк
Кимсетелгән иман сагында.
Канын саклап җанын сатты күпләр
Ай тотылган төннәр ягында.

Якты көннәр көтеп, түрәләрнең
Юллар бутап йөргән чагында,
Калдык инде, калдык без адашып,
Ай тотылган төннәр ягында.

Анасын да белми, баласын да,
Карасын да күрми, агын да.
Телсез, денсез үле җаннар йөри
Ай тотылган төннәр ягында.

Йә бетәбез бүген, йә калабыз,
Язмыш яный безгә тагын да.
Адашканнар йоклый хәлсез калып,
Ай тотылган төннәр ягында.

Якты көннәр өчен уяуларның
Кыйбла эзләп үлгән чагында,
Кем уятыр безне, кем уятыр
Ай тотылган көннәр ягында?!

*1989*

## Өмет

Ишкәк сынгач, канлы куллар белән
Ишәсе дә икән, ишәсе.
Ватты кяфер бәреп көймәләрне,
Югалды нур – кадер кичәсе.

Азгын, бозык дөнья бәндәләре,
Бата-калка әле йөзәбез.
«Кыйбла-яр» дип талпынабыз да бер,
Өметләрне тагын өзәбез.

Без өметсез түгел әле, Раббым,
Ярлыка Син безне, якла Син.
Әнә кемдер ишкәк бирәм диеп
Суза безгә кабер тактасын...

*1999*

## Өч сүз

Йөз башлы аждаһа җан бирә.
Чаң суга гасырлар сәгате.
Җикереш, чишенеш, үтереш –
Таркалу дәвере сәнгате.

Аждаһа җан бирә. Баш кисә
Җыелган золымнар җәбере.
Киселми калганнар мал булә –
Таркалу сәнгате дәвере.

Җан бирә аждаһа. Уты юк.
Кыр саен агулы баш кала.
Кан белән сугарган кырларда
Дәверләр сәнгате таркала.

*1991*

## Маңкортка

Син кайтырсың әле исемеңә,
Җан тарта ул, тарта барыбер.
Шиксез кебек иде гомер юлың,
Ике чиккә ул да ярылыр.

Син кайтырсың әле җисемеңә,
Кан тарта ул, тарта барыбер.
Үз әнкәсен тапкан ятим кебек,
Кыйбласына сының сарылыр.

Елый-елый җыр тыңларсың беркөн,
Адашуларыңны зар итеп.
Үзең булып бер яшисең килер,
Гомер узган булыр бары тик.

*1990*

## Тел-нәсел

Тел-нәселнең ничек киселгәнен
Аңламыйсың әле үзең дә.
Гомер түгел, алтын мизгел китә
Онытылган һәрбер сүзеңдә.

Еллар үткән саен, чит көйләргә
Аз җырлана, сирәк биелә.
Карт агач та, еллар үткән саен,
Тамырларга таба иелә.

*1990*

# Милләт абруе

– Бигрәк инде син, энем...
*Ф.Шәфигуллин*

Белмисеңдер, бәлки, барлык табибларның
«Зыян итмә!» дигән мәгълүм гыйбарәсен.
Бар дөньяга шаулап, ыгы-зыгы килеп,
Кайчак, энем, бик арттырып җибәрәсең.

«Өлкән абзаң»ны беләсең, күптән чирле.
Ни күрсә дә «минеке!» ди, чөнки «бөек».
Андыйларның гайрәте күп, акылы юк,
Андыйларны дәвалыйлар арттан сөеп.

Ул бит хаста, үз аңында түгел, мескен,
Ә син аңа «юләр!» диеп җикерәсең.
Аңламыйсың, чыгырыннан чыкса әгәр,
Йорт-җиреңне килеп аның җимерәсен.

Белем белән җиңә белгән тел булмагач,
Мылтык тотудан халыкка нинди файда?
Юкка кырылган болай да күндәм халкың,
Чакырасың аны тагын нинди яуга?

«Милләтче»нең нигә һаман абруе юк?
Талымсыз сүз тыңлап, кайчак уйлап куям:
Теләсә кем ни теләсә шуны сөйли –
Аяныч бер хәл, ләкин күпме зыян...

*2001*

## Ук очы

Кайчандыр без
Ук идек,
Ук очында
Ут идек.
Хөр мәмләкәт,
Тук балалар,
Уйный идек,
Шук идек.

Хөр булырга,
Көр булырга,
Ук очында
Ут булырга,
Чит өстәлдән
Хәер эстәп,
Тук булганчы,
Юк булырга, –
Мәчет ватып,
Хәмер татып
Иелгәннәр,
Чит өйләрдә
Чит көйләргә
Биегәннәр
Өйрәталмый.

Килде вакыт –
Утлар сүнде,
Кыек атып,
Уклар сынды,
Илен сатып,
Туклар күнде,
Кырын ятып,
Шуклар тынды.

Бастырылу!
Бастырылу!
Төшме? Өнме?
Чолгый безне
Ут инде.
Уятыгыз!
Уятыгыз!
Ләкин тавыш
Юк инде, –

Ут эчендә,
Ук очында
Күпме язмыш
Юк инде...

*2001*

## МӘҢГЕЛЕК СЕР

## *Бердәнбер мәхәббәт*

Ак хыяллар, ак бәхетләр...
Акылдан яздым инде.
Ак күңелгә кара белән
Язмышым яздым инде.

Эх, сынап та карады соң
Чамалы түземлекне –
Аз да түгел, күп тә түгел,
Бердәнбер, үземнеке.

Сукыр булды сөюләрем,
Адым саен ялгыштым,
Адым саен, күрә торып,
Ялгышканга сабыштым.

Ел саен яндым, абындым,
Эзләдем, көттем инде.
Түзмәдем, эчтем хыянәт,
Югалдым, беттем инде.

*1983*

# Гамь

Яңа кипкән борын астын
Бизи өч бөртек мыек.
Без йөрибез ел туздырып,
Бер айлык акыл җыеп.

Хәл бар, гамь юк. Тән бар, тәм юк.
Ике башка бер мендәр.
Ташкын язлар, шашкын башлар,
Кара төннәр, ак көннәр.

Куеланса да мыеклар,
Сирәгәя башта чәч.
Еллык акыл да бер айда
Керер, башыңа төшкәч.

Тәм дә булды, гамь табылды,
Ике башка бер мендәр.
Моңсу күзләр, уйчан йөзләр,
Ак төннәр, кара көннәр...

*1988*

# Гөл...гә

Күпме көнне мин үпкәләп үттем,
Күпме гомер әрәм ителде.
Исем китеп каршы чыгам сиңа,
Тәпи киткән сабый шикелле.

Сабый димәс идем сине дә мин,
Сабыйлыгың һәрбер сүзеңдә.
Табан астың күрми йөгерәсең,
Кулларыңны җәеп үзең дә.

Мизгел саен бәхет булмас инде,
Мизгеленә дә без канәгать.
Күпме гомер артта сузылып ята,
Ә яшәдек бары бер сәгать.

Гөлләр үпкәләр күк, исемеңә
Гөл дигән сүз тагып кушмасам.
Болыныңа мин озатам сине,
Гүя гомер белән хушлашам.

*1984*

# Әйтелмичә калган сүз

Кайчакларда шулай була икән –
Әкрен генә поезд кузгала,
Ерагая ара, бер-береңә
Әйтеп өлгермәгән сүз кала.

Мин сизендем, ләкин аңламадым,
«Түз, сикермә, – дидем, – йөрәк, түз!»
Бәргәләнде вокзал почмагында
Син әйтәсе миңа кирәк сүз.

Син аңладың – поезд кире килмәс...
Йөрәгемне уйды карашың.
Нигә шулай авыр икән үтү
Күңел белән күңел арасын?

Инде тормыш поезд кебек чаба,
Ә бит ничек әкрен кузгалды.
Бик үкенеч: гомер почмагында
Әйтелергә тиеш сүз калды.

*1979*

## *Илаhи мәхәббәт*

Йөгерәдер кебек Мәхәббәт,
Кочакларын җәеп, каршыга.
Заман шаулый, кисәк җир тетри,
Очып йөри янда карчыга.
Мин кыяда. Куллар чылбырда.
Күкрәккә кош куна талпынып. –
Күккә менеп урлап кайттым мин
Мәңгелекнең сөю ялкынын.
«Мескен адәм, – күктә көләләр, –
Күпме өмет шул бер гомергә.
Килеп җитәр, бәлки, Мәхәббәт,
Алдыннан бит Вакыт йөгерә!»
Буа чылбыр, инде саташам:
Мәхәббәтме килә каршыга?
Әллә чукыр өчен йөрәкне,
Канатларын җәя карчыга?
Чукысаң да, сүнмәс, явыз кош,
Урлап кайткан сөю ялкыным,
Очкын булып төшәр җырлардан
Күңеленә Җирем халкының.
Вакытны да узып, очкыннан
Сүнгән утлар кайчак кабына.
Килеп җитәр Сөю, көтегез,
Тик кайвакыт ул еш абына.
Адәмнәрдән күктә көлмәсләр,
Мең өмет бар Җирдә, мең гомер.
Кочакларың җәеп каршыга,
Кил, Мәхәббәт, тизрәк кил, йөгер!

...Күккә менеп төшкән угрының
Юк бу Җирдә ише, тәрәге.
Аунап ята язмыш чукыган,
Канлы, яшьле, ялгыз йөрәге.

*1985*

# Кемдер тәрәзә кага

Шаулый дөнья, исә җилләр,
Тормыш ага да ага.
Кара төндә, кемне эзләп,
Кем ул тәрәзә кага?

Кабынган өмет кулымда,
Ачам ишекләремне,
Йөгерәм каршы алырга,
Таптап бар шикләремне.

Күкри дөнья, яшьни яшен,
Кара болыт агыла.
Яфрак койган агач җилдә
Тәрәзәмә кагыла.

Сүндерде җил өмет утын,
Каерды да кулымны.
Әкрен генә эзләп керәм
Йөгереп чыккан юлымны.

Яктыртып булмый дөньяны,
Тормыш ага да ага.
Өмет кабына да сүнә,
Кемдер тәрәзә кага...

*1985*

# Җил сурәте

Ерак әле, ерак ак кәфенең,
Ерак инде, ерак бишегең.
Кабаланып тәрәзәңне капла,
Язгы җилләр ачса ишегең.
Ә ишегең ничек ачылса да,
Бикләнергә кире ябылыр.
Ярсыган җил сыйпап-сыйпап үтәр,
Итәгеңә килеп кагылыр.
Бикле йортта кая гына китсен,
Сарылсын ул барып кемнәргә? –
Тетрәтер дә куе керфекләрең,
Башын салыр ап-ак мендәргә.
Шәмнәр сүнәр аның агышыннан
Кичке эңгер-меңгер кабызган.
Колакларга керер ул ут булып,
Өзелеп-өзелеп чыгар авыздан.
Үзәкләргә үтәр бу өермә,
Җимерер дә оят читлеген.
Тыелгысыз соңгы аваз булып
Өзеп ташлар әдәп битлеген.
Ерак очар төнге ак җәймәләр,
Җыерылып фани чынлыкта.
Җан бишеге күктә озак йөзәр,
Илаһи дәрт тынган тынлыкта.
Соңгы җиләс дулкын сискәндереп,
Кызыл томшыкларга кагылыр.
Уяныр да татлы йокысыннан,
Ак җәймәсен оят ябыныр.
Бөтерелеп күккә күтәрерлек
Әллә давыл керде ишектән?
Ак җәймәгә урелә хәлсез куллар,
Күктән төшеп килгән бишектән...

*1984*

# Күк һәм күңел йолдызлары

Чорлар аша безгә килгән
Бу яктылык кисәгенең
Чыганагы нинди хәлдә?
Ничек белик исәнлеген?
Әллә алдыйлармы безне
Вакыт һәм ерак аралар?
Йолдыз сүнгән, нурлар юлда,
Һаман да алга баралар.
Ничек сүнгән? Таркалыпмы?
Кисәкләргә ватылыпмы?
Безнең өчен исән бит ул,
Әллә Вакыт – яктылыкмы?
Күз күрерлек ара чикли
Безнең кыю уйлар күген.
Җирдә аң җитмәслек эшләр
Бу дөньяга берни түгел.
Ничек гаҗәп, ничек сәер,
Күреп була икән «юк»ны,
Күптән үткән вакытларны,
Инде күптән сүнгән утны.

Еллар аша безгә килгән
Ерак сөю хисләренең
Сүнгәнлеген мин әйталмам,
Син сорама исәнлеген.
Инде күптән алдый безне
Вакыт һәм ерак аралар.
Сөю сүнгән, хисләр юлда,
Һаман да алга баралар.
Язмыш безне бәргәләде,
Әллә күңелләр ватыкмы?
Еллар кебек уза икән,
Әллә мәхәббәт – Вакытмы?
Икеләнү кайчак чикли

Безнең кыю уйлар күген.
Көндез аң җитмәслек эшләр
Кичләр өчен берни түгел.
Кайчак шулай сәер генә
Тоеп була икән «юк»ны,
Янып үткән вакытларны,
Инде күптән сүнгән утны.

*1982*

## Күрешербез әле

Күрешербез әле, күрешербез,
Бергә үткән күпме еллар бар.
Мәхәббәтне татлы газап итеп,
Бергә тарткан күпме кыллар бар.

Килешербез әле, килешербез,
Сагынырбыз үткән елларны.
Уйнап кына тарткан идек юкса,
Ә өзгәнбез күпме кылларны.

Ирешербез әле, ирешербез,
Сайлый-сайлый көткән теләккә.
Тормыш көен көйләп йөргән чакта,
Өзелгән моң булыр йөрәктә.

Җитешербез әле, җитешербез,
Башламаган күпме еллар бар.
Башың ташка бәреп еласаң да,
Өзелмәскә калган кыллар бар.

*1978*

## *Мәхәббәт сурәте*

Син үзең дә шушы иртә кебек,
Сабыйныкы кебек йөзләрең.
Күбәләктәй кара керфекләрең
Каплаганнар зәңгәр күзләрең.

Кайнар сулыш йөзең сыйпап үтте,
Дерелдәде куе керфегең.
Чәчрәп чыкты керфек арасыннан
Зәңгәр күкнең ике бөртеге.

Агачлыкта инде кошлар сайрый.
Без сизмәдек... Күпме шау анда!
Яланаяк җылы асфальт буйлап
Үттек кебек яңгыр яуганда.

*1979*

## *Сөю йолдызлары*

Бөек хисләр, сөю йолдызлары
Очып йөри хыял күгендә.
Чынбарлыкта, бер тамчы наз тапмый,
Эссе чүлдә калдым бүген дә.

Инде август. Әле һаман эссе.
Ява бары йолдыз яңгыры.
Җиргә төшә сөю йолдызлары,
Үз-үзләрен юлда яндырып.

*1985*

## Серләр

Ачма, иптәш, күңел ишегемне,
Ташып чыгар хисләр һәм моңнар.
Мин курыкмыйм синнән,
ләкин Җирдә
Дуслар гына белгән серләр бар.

Узма, дустым, күңел түрләремә,
Иркә-назлар анда
оя корганнар.
Мин ышанам сиңа,
Тик сөйгәнем белән
Икәү генә белгән серләр бар.

Төшмә, бәгърем, күңел базларыма,
Язгы бозлар анда, тынган бураннар.
Мин яратам сине,
ләкин миндә
Үзем генә белгән серләр бар...

*1983*

## Торна

Сакламадым кулымдагы кош баласын,
Өметләнеп һавадагы торнага.
Ә кошчыгым «мин – торна!» дип аһ органда,
Очып киткән, мине көтеп тормаган.

Әнә оча, аваз сала матур торна,
Аста кала безнең яшьлек даласы.
Миннән качкан нәни кошчык булган икән
Чыпчык түгел, чып-чын торна баласы...

*1983*

# Сүнмәс тойгылар

Тормышның серләрен ачканда
Язмышның бормалы юлында,
Ашкынып яшәргә ашыктым –
Уйладым мәхәббәт турында.

Илаһи тойгылар эзләдем
Балкыган хыяллар нурында.
Яраттым, ялгыштым, туймадым –
Уйладым мәхәббәт турында.

Сыгылып чамасыз йөгемнән
Егылып ятканда урында,
Сызландым, ләкин сер бирмәдем –
Уйладым мәхәббәт турында.

Сыгылып, егылып калмадым,
Язмышым үземнең кулымда.
Үзгәрмим һаман да – уйларым
Һаман да мәхәббәт турында.

*1985*

# Ут капкач

Сөйде беркөн зифа буйлы каен кызы
Янындагы таза сынлы наратны.
Үскән саен сыенды ул сөйгәненә,
Үскән саен, нарат аны яратты.

Кышкы бураннарда нарат каплап торды
Куе ылыслары белән сөйгәнен.
Җәй буена каен аны иркәләде,
Җәй буена җилдә серен сөйләде.

Һәр ел саен бер саргаеп алды каен,
Искә алып үткән җәйләр җылысын.
Ел буена яшел торган нарат никтер
Ел буена койды сары ылысын.

Шаулап үскән яшь наратны җәйге яшен
Әйләндерде кинәт утка, төтенгә.
Кара көйде каенның сузган куллары,
Кара күмер булды нарат бөтенләй.

Кыш буена җил өшетте каен кызын,
Кыш буена туңды көйгән тармагы.
Яңа язда үзе генә яшь агызды,
Яңа җәйдә ләкин яфрак ярмады...

*1984*

## Утсыз калган учак

Ут алырга кергән идем
Мәхәббәт учагыңнан.
Кайнар күмер тартып алдым
Ялкынлы кочагыңнан.

Сакламадым ләкин җилдән –
Сүнде синнән алган ут.
Сиңа килсәм, мин ут алган
Учагыңда җылы юк.

Шул ук җилләр, шул ук яңгыр
Күмерләрне көл иткән.
Иң кайнарын миңа биреп,
Утсыз калгансың икән.

*1978*

## Хөкем

Пар табып та, чиксез ялгызлыкта
Аз түгелдер гомер кичкәннәр.
Канатларын күпләр яшергәннәр,
Күпләр бөтенләйгә кискәннәр.

Ә кемнеңдер канатлары исән,
Язмыш кына ләкин кителгән.
Мәхәббәт дип күккә үрелгәннәр
Ялгызлыкка хөкем ителгән.

*1989*

# Февраль бураннары

Ничек түзим җыр язмыйча
Февраль бураннарына.
Ничек түзим бер кайтмыйча
Авыл урамнарына.

Урамда ак буран дулый,
Ачык биткә кар сылый.
Өй түбәләренә менеп,
Морҗаны кочып елый.

Баганада ялгыз фонарь,
Төнге җилдә талпынып,
Учлап-учлап җиргә сибә
Бөртек-бөртек яктылык.

Мин урамда... Нәрсә буран? –
Кар белән җил нибары.
Мин ашыгам – йөрәгемдә
Мәхәббәт бураннары...

Ничек түзим җыр язмыйча
Февраль бураннарына.
Һаман буран күңелемнең
Кичке урамнарында...

*1978*

# Мең дә беренче тапкыр

Юатма, кызлар күп, үтәр, дип,
Сөйгәнен югалткан егетне.
Ошатыр, бүтәнне яратыр,
Тик тапмас сөйгәне кебекне.

Бүтәннәр яратып юатыр
Хыянәт кичергән күңелне.
Нәрсәдер कителгән, югалган,
Тик шулай да яшәү күңелле!

Ә еллар тыелмас хисләргә
Гамьсезлек кәфене ябалар.
Эзләгән кызларын егетләр
Табалар, һичшиксез, табалар!

Юатма, бәхет бер килер, дип,
Алданган, ташланган кызларны.
Шикәр дип, ялгышып кабылган
Тоздан да ачырак тоз бармы?

Юатма, сүзләр – буш. Бик авыр
Савыгу мәхәббәт чиреннән.
Кирәкми, каптырма баллы сүз,
Тоз тәме бит әле ирендә.

Ә еллар, өметле яшь еллар
Агалар, кайтмаска агалар.
Яр көткән кызларны егетләр
Табалар... кайвакыт... табалар...

*1975*

# Хушлашу

Уза көннәр, уза айлар,
Гомер – газап, мизгел – алтын.
Чәчәк тоткан кулың кайнар,
Хәнҗәр тоткан кулың салкын.
Җиде тапкыр телгәләгәч,
Үз туксаны – һаман туксан –
Бер генә кат үлчәр өчен,
Әзер түгел икән юкса.
Шөкер, диеп, тәүбә итеп
Китеп барам. Җитәр инде.
Салкын кулың. Менә юлың.
Тотма мине, җибәр инде.
Тормыш кырыс. Ә син тырыш.
Карап торыйм соң ничек мин?
Сукыр белән чукрак кебек,
Син күрмисең, мин ишетмим.
Савабым юк, гаебем күп,
Үз кырыгым – һаман кырык –
Мәхәббәтне кисеп була,
Ләкин булмый чагыштырып.
Шөкер итик, ирештең бит.
Китим инде, җитәр инде.
Менә юлың, менә улың,
Тотма мине, җибәр инде.
Уза көннәр. Уза айлар.
Тормыш – газап. Мизгел – алтын.
Нинди язмыш көтә безне?
Җан өшетеп керә салкын...

*1997*

# Рәшә

Юк инде, юк, өметләнмим,
Айныды күк акылым.
Мәхәббәт дигән рәшәгә
Барып кермим атылып.

Туйдырды кысыр өметләр,
Алданулар, алдаулар.
Туктатты шашкын хисләрне
Еллар дигән чал таулар.

Эх, шашкын җил, җилфердәтеп
Йомшак, бөдрә ялыңны,
Өзеп киттең минем соңгы,
Саргайган хыялымны.

Җан ялангач, хисләрем ач,
Чамалы тормыш башлыйм.
Кичен язган шигырьләрне
Иртән ерткалап ташлыйм.

Юк инде, юк, өметләнмим,
Айныды күк акылым.
Гамьсезлек дигән рәшәгә
Чыгып киләм атылып...

*1978*

# Хыял кызы

«Күрмим сине, күрмим, кил инде, кил,
Башта гына бераз оял да...»
Кулымда кул яна, тик иркәлим
Башка бер гүзәлне хыялда.

«Салма, салма бу ак күлмәгеңне,
Сары күлмәк, бәлки, киярсең,
Тышым ялкын, эчем салкын минем,
Мин ерактан килгән иярчен.

Балкып керәм ачык кочагыңа,
Мәңгелек боз, ләкин кан, йөрәк.
Сүзем ипле, җаным бикле минем,
Ә сиңа бит әле җан кирәк.

Бәйсез, үксез, юлсыз, тынгысыз мин,
Нәрсә көтеп йөрим, ни эзлим?
Ахыр сүзең алдан белә торып,
Баш сүзеңне тизрәк ник өзмим?

Язмышым да, ялгышым да түгел,
Килеп чыкты сиңа сукмагым.
Син минеке түгел, мин бары тик
Берүзеңне күреп туктадым».

Караңгы да, кара да бу дөнья,
Балкытырга иде төн күген.
Ләкин күңел, моңлы, бәйсез күңел:
«Ул түгел, – ди һаман, – ул түгел...»

...Килде ул көн, килде чын бәхеттәй,
Дистә еллар аша адашып,
Ялгыз кичләр аша өзгәләнеп,
Кара төннәр аша саташып.

Килеп керде, гомер узып бара,
Аңлашырга инде вакыт тар.
Килеп керде... Гүя җаныма да,
Тәнемә дә күптән хакы бар.

Килде кебек соңгы бәхет чиге –
Хыял кызы кайнар куенда.
Ләкин нигә, нигә уйлыйм хәзер
Ак күлмәкле кемдер турында?

«Ни уйлыйсың? Ни уйлыйсың?» – ди дә
Көлә сәер, затлы хыялым.
«Күрми калдым, – димен, – күрми калдым,
Күренмәде юри, оялып.

Бәлки, минем бәхет шул булгандыр...
Ник көләсең әле син?» – дидем.
Ә ул кинәт елый-елый дәшә:
«Мин идем ул, бәгърем, мин идем!

Күреп калдым йолдыз атылганын,
Тигез җирдә кисәк абындым.
Сары күлмәк кияр дигән идең,
Кара кидем, кара ябындым...»

*1990*

# Янды өмет

(Моңлы романс)

Бер шатлыкта, бер сагышта күңел,
Бәхет эзләп, шәмнәр кабыздык.
Шәмдәлләргә тамчы булып тамды,
Янды өмет, калды ялгызлык.

Кушымта:

Шәмдәлләрдә шәмнәр эреп акса да,
Өметләрне еллар утка якса да,
Тик син генә миңа якты истәлек...
Нишләдек без, бәгърем, әллә нишләдек...

Бер салкында, бер ялкында күңел,
Ялгышымны кичер, и Раббым.
Ярамыйдыр үлеп яратырга,
Ә мин менә шулай яраттым.

Кушымта.

Бер картлыкта, бер яшьлектә күңел,
Юанычым – якты истәлек.
Шәмдәлләрдә шәмнәр сүнеп бара...
Нишләдек без, бәгърем, нишләдек?!

Кушымта.

*1997*

## ҖИР БАЛАСЫ

### *Август ахыры*

Җәйләр белән саубуллашыр вакыт,
Урамнарда август ахыры,
Кырлар кия Кояш эшләпәсен,
Һәр көн саен ныграк батырып.

Соры йөзле, сары сакаллы көз
Килеп басты ишек төбенә.
Аның дымлы салкын тын алуын
Җәй дә инде ишетте менә.

Салкын суда яшел яфрак йөзә,
Җәйнең мунча ташы сүреләә.
Кояш кебек балкып, кайчак аның
Шәрә аяклары күренә.

Күңелләрдә әле җәй җылысы,
Урамнарда август ахыры.
Ишек ярыгыннан көз күзәтә,
Эшләпәсен күзгә батырып.

*1985*

# Автобиография

Ике капка арасы,
Сагышлы күз карашы.
Унбер яшьлек баласы,
Инде китеп барасы.

Ике авыл арасы,
Салкын икән чанасы.
Ялгыз гына барасы,
Анасыз бит баласы.

Ике төбәк арасы,
Чуен юлга саласы.
Кан-яшь гыйльме аласы,
Ярый күрми анасы.

Ике гомер арасы,
Берәүнең күз карасы,
Берәүнең җан ярасы,
Мин китәм, сез каласы.

Ике дөнья арасы,
Боз кебек күз карашы.
Әллә әйтеп каласы,
Әллә китеп барасы.

Чор белән чор арасы,
Дан-шөһрәт казанасы.
Барасы да барасы,
Күрми генә анасы...

*2000*

# Ана сагышы

Бер карашка кайгың күптән үтте кебек,
Урамнарда сөйләшәсең инде көлеп.

Мине күреп якын килдең әкрен генә:
«Беләсеңме, улым үлде минем менә...»

«Беләм...» дидем. Ә син, читкә борып башың,
Тавыш-тынсыз тешең кысып ыңгыраштың.

Күңел кайчак көзге юка боз шикелле,
Боз астында тып-тын ята сагыш күле.

Кагылуга хәтер аңа ялгыш кына,
Боз ватыла, сагышларың чәчрәп чыга.

«Беләм...» дидем, тик әйтмәдем башка бер сүз.
Үтә торган кайгы түгел. Түз, ана, түз.

Аптырама, бу шигырьне тапсаң әгәр.
Боз түгел бит минем күңел төпкә кадәр...

*1984*

# Бәхет кылы

Бу дөньяның бәхет кылы нечкә,
Тормыш тулы гыйбрәт язмышлар,
Төзалмаслык үкенечле хәлләр,
Төзәтерлек түгел ялгышлар.

Мәҗбүриме әллә афәт,
Аңлар өчен яшәү шатлыгын,
Тавыш-ызгышларның ахмаклыгын,
Үпкәләшүләрнең ваклыгын.

Бер мизгелнең мең кадерен белеп,
Тыйнак бәхет, тәүфыйк теләсәң,
Исеңдә тот: җирдә мизгел саен
Кемдер үлем белән көрәшә.

*1987*

# Гомер һәм тормыш

Хафаланма, кордаш, моңсуланма,
Безнең гомер инде үтте дип.
Гомер юлы олы хыялларны
Юл читенә чайкап түкте дип.

Үткән юлга карап, бер өметсез,
Киләчәкне сызып ташлама.
Кайвакыт бит гомер үткән була,
Әмма тормыш яңа башлана.

*1982*

# Диңгез

Чиксез дәһшәт, рәхимсез көч – диңгез.
Дулкыннарны ярып баручы
Кораб гүя бер дошманы аның,
Гүя аның бездә бар үче.

Без сыенган корыч зур корабны
Күтәрә дә ташлый упкынга.
Упкын төбе исә кабул итми,
Атып бәрә тагын дулкынга.

Беренче көн бүген без диңгездә,
Бу мәхшәргә ничек түзәргә?
Әллә диңгез суы, әллә маңгай тире
Әчеттереп керә күзләргә.

Баштанаяк каплап китә дулкын,
Тозлы сулар тама иреннән.
Диңгез суын ясаганнар кебек
Күз яшеннән, маңгай тиреннән.

Барыбер бер тына бит ул давыл,
Үҗәтлек бар аңа түзәрлек.
Диңгезнең дә бар бер юанычы,
Тыныч чагы – чиксез гүзәллек.

*1979*

# Әни

*(Дустым Рифкать авызыннан)*

Телгә оста түгел үзем,
Күп сөйләшмим әллә ни.
Күз алдымда артыбыздан
Йөгереп килгән әни.

Олы юлга җитә идек,
Ерак түгел әллә ни.
Чакрым диярлек араны
Йөгереп килгән әни.

Онытылган кабартмалар
Бәла түгел әллә ни.
Шуларны яулыкка төреп,
Йөгереп килгән әни.

Кемдер өчен бу күренеш
Гаҗәп түгел әллә ни.
Ә минем күзгә яшь тулды,
Йөгереп килгәч әни.

Олы юлга җиттек инде,
Ә күңелдә әллә ни.
Тыны кысылып кул болгый
Җитмеш яшьлек карт әни...

*2000*

# Йөрәк

Дөнья гаменнән таушалган
Йөрәк иде.
Соңгы, тагын бер ыргылу
Кирәк тиде,
Соңгы адым, соңгы чакрым
Калган иде.
Кирәк түгел! Бу сүз мәкер,
Ялган иде.
Алда упкын, алда юл юк,
Бетә иде.
Кемдер арттан йомшак кына
Этә иде.
Соңгы сугыш – соңгы сулыш,
Белә иде.
Кемдер елый. Бер кабахәт
Көлә иде.

Кызганыч бик. Күпләргә бер
Терәк иде.
Дөнья гаменнән таушалган
Йөрәк иде.
Кемгәдер бу котылу бик
Кирәк иде...

*2000*

## Кабер янында ана

...Соры чүлләр, соры җилләр.
Өстерәлә җәяүле ком.
Ялгыз кабер түбәсеннән
Күңелләргә үрелә шом.

Ялгыз ана кабер саклый.
Кемнәр кылган нинди золым?
Балачакта күргән кино...
Гамьсезлегем җуйган елым...

*1984*

## Җан сулышы

Туган илнең бер ягыннан бер ягына
Куды язмыш инде күпме еллар элек.
Гомеремнең бер кисәге калган җирдә
Җанымның да бер өлеше калды кебек.

Килер бер көн, тән сулышым өзеп ташлап,
Башка дөнья үз ягына мине алыр.
Күңелләрнең моң гөлләрен җилдәй сыйпап,
Җан сулышым бу дөньяда, ахры, калыр.

*1984*

# Картлык һәм хәтер

1

Әле яңа ачылганда дөнья яме,
Иң беренче әйткән сүзең исеңдәме?
Исеңдәме йөгергәндә егылганың?
Егылганда кайсы сүзне кычкырганың?
Кара төндә яман төшләр күргән идең,
Кемне ярдәмгә чакырдың, нәрсә дидең?
Тиргә батып, хәлсез чирләп яткан чакта,
Кайсы сүзең тел очында торды сакта?
Каерылган чакта нәни канатларың,
Елый-елый кайсы сүзне кабатладың?

2

Адәм булдың, кадерле сүз исеңдә юк.
Картлар йортында әниең, өеңдә юк.
Гомер буена көн күрми билен бөккән,
Көне-төне колхоз өчен тирен түккән,
Яклаучысыз җанда үпкә-яра гына,
Үлчәп кискән ипи үтми тамагына.
Яман төшләр күреп чирләп яткан чакта,
Шадра сөлге аның баш очында сакта.
Кыймылдатып хәлсез, ябык яңакларын,
Елый-елый һаман бер сүз кабатлар ул.
Тел очындагы ул сүзе «Алла» булыр,
Тик уенда Алла түгел, бала булыр.
Өметләнеп соңгы мизгеленә кадәр,
Мәрхәмәтсез баласыннан көтәр хәбәр.

3

Сүрелгәндә күзләреңдә дөнья яме,
Кем янында көн күрерсең? Өеңдәме?
Балаң өметсез – янында кысан аның.
Һич югында, Аллага да ышанмадың.

Искә төшәр беренче сүз, юлдаш булыр,
Сыныклар – аш, яткан урының таш булыр.
Алда көтә тыныч зират, соңгы торак,
Ләкин юлда үтәр ара әле ерак.
Тынычланып күз йомарга иртә әле,
Җәза җәһәннәмдә түгел, җирдә әле.
Онытылган беренче сүз еллар аша,
Соңгы юлда юл читенә чыгып баса.
Чыгып баса, елый-елый карап кала
Бердәнбер жәлләп калучы газиз Ана...

*1990*

## Җил егете

Егыла-тора, бәреләсугыла
Каен кәүсәләренә,
Җил егете киңлек эзли
Тынгысыз егәренә.

Карт җилләр инде югары,
Болытлар белән таныш.
Анда олы, анда туры,
Анда куәтле агыш.

Ак каеннар арасында
Җил егете юл яра.
Ә күктә ертык болытлар,
Кайсы ак, кайсы кара...

*1981*

## Җил оясы

Болыт килә бертуктаусыз,
Көнозын яңгыр коя.
Куак астында моңая
Коры, ләкин буш оя.

Котырган җил шаулап йөри,
Изүен ачкан килеш.
Агачлардан яфрак өзеп,
Давыл булмакчы, имеш.

Кич җитүгә, яңгыр тына,
Көн артыннан төн ага.
Алҗыган җил кереп ята
Йокларга буш ояга.

*1981*

## Җир баласы

Ни әйтсәң дә, туган моңнар белән
Чит җырларның ерак арасы.
Җырлаганда елап үскән, мин бит
Авылымның газиз баласы.

Ә шулай да чит җырларның моңын
Килә кайчак отып каласы.
Тыңлый-тыңлый күңел үскән, мин бит
Үз илемнең моңлы баласы.

Күңелемә үткән яктылыгы,
Күзләремә тулган карасы,
Бар илләрнең моңын җыйган, мин бит
Үз җиремнең җанлы баласы.

*1982*

## Килер ул көн

Тукта әле, тукта, һаваланма,
Күрәсеңме яфрак өзелә.
Өзелә дә төшә, өзелә дә төшә
Узып барган җәйнең эзенә.

Саргаюның сагышлары булып,
Яфракларга сары төс керә,
Шуышалар җирдә, әйтерсең көз
Чәчләреннән йөри өстерәп.

Ни чәчсәң дә җирдә, барыбер бит
Керәсең бар тормыш көзенә.
Төшәсең бар, ачы хәтер булып,
Исәннәрнең яра эзенә.

Төгәл буяу таба һәрчак Вакыт,
Тарихка да яңа төс керә:
Әнә килә, күпме исемнәрне
Пычрак юллар буйлап өстерәп...

*1990*

## Көз

Алмаларын җиргә коеп,
Узып бара чәчәк иле.
Берәм-берәм яфрак өзә
Агачлардан төньяк җиле.

Җәйләр үтә... Кошлар китә.
Ә Җир юлын дәвам итә!
Бары тик бер җәебезне
Еллар җиле өзеп китә.

*1979*

## Кукмараның үзәк урамы

Баскычлардан йөгереп менәр идем...
Вокзал һаман балкып торамы?
Бормалымы, якты елга кебек,
Кукмараның үзәк урамы?

Җәяүлеләр салган сукмаклардан
Үрелмәгән юллар буламы?
Авыл юлларының толымы ул
Кукмараның үзәк урамы.

Алып китте дулап, адаштырды
Вакыйгалар, еллар бураны.
Күпме юллар белән тоташтырды
Кукмараның үзәк урамы.

Баскычлардан йөгереп төшкән идем,
Язмышыма сагыш юрамый.
Сыйпап калды кебек аркамнан ла
Кукмараның үзәк урамы...

*1983*

## Моңлы җыр

Әкрен җилдә дулкын-дулкын
Чайкалды арыш кырлары.
Өзелеп-өзелеп, зәңгәр күктә
Тургай моңлы җыр җырлады.
Камышлыктан күк йөзенә
Очып чыкты кыр үрдәге.
Ә бытбылдык, кача-кача,
Болында мине үртәде.

Табигатьнең бишегеннән
Җиргә төшкән мин бер кунак.
Ул вакытта миннән зыян –
Ялгыш сынган ялгыз куак...

Арыш кырларына басып,
Бер балыксыз инеш буйлап
Авылсыз авыл баласы
Кайтып киләм ниләр уйлап?
Сулар акты. Төннәр якты.
Утта яна күз карасы.
Адым саен, адым саен
Төзәлмәслек Җир ярасы!
Кырлар һаман дулкын-дулкын,
Бу – балачак арышы бит!
Бер карасам – туган җир күк,
Бер карасам – барысы чит!

Кырга чыгып ниләр эзлим?
Юлга чыгып кая барам?
Юлда тәгәрмәчләр шавы,
Кырлар авазларга саран.
Балачакта күккә очкан
Кыр үрдәге кайтмый бүтән.
Бер суга, бер күккә карыйм,
Канат каккан тавыш көтәм,
Кайда син, шаян бытбылдык?
Исәнме син? Бармы җирдә?
Үле тынлык... Тик тын гына
Арыш кыры шаулый җилдә.

*1994*

# Нуриягә

– Шомырт, сирень, зәңгәр чәчәк...
Ходай биргән ләззәт, дисең.
Күрми шулай сөенәсең,
Сөенәсең, ләкин ничек?
– Чәчәкләргә битем куям,
Урманнарда җиләк җыям,
Син белмәгән, син сизмәгән
Мин бит аның исен тоям.
– Курчак уйнап утырасың,
Дусларым шул минем, дисең.
Сыйпап кына аңлашасың,
Аңлашасың, ләкин ничек?
– Һәр курчагым тере җанлы,
Курчак өе – минем оям.
Башларыннан сыйпаганда,
Мин бит аның битен тоям.
– Чәчәк – мәхәббәт билгесе,
Шундый бер шигырь яз, дисең.
Шигырьдәге мәхәббәтне
Яратырга мөмкин ничек?
– Үз хәлемне үзем беләм,
Үз җаныма үзем сыям.
Әгәр дә син яза белсәң,
Мин бит аның хисен тоям.
– Тормыш тулы чокыр-чакыр,
Ә син чабып йөрим, дисең.
Күңел упкыннары аша
Ничек узасың син, ничек?
– Бар нәрсәм бар, күрмим генә,
Хисләремне кайчак тыям.
Өстә чәчәк, аста упкын...
Мин бит аның чиген тоям.

*2001*

## Сез гөлләр булырсыз

Карлар эрер. Орлыклар да
Яктылыкка үрелер.
Кайсы бөртек кайсыбызның
Җаны булып күренер.

Сез инде гөлләр булырсыз...
Әлеге дә баягы,
Мин генә читтә чайкалган
Ялгыз шайтан таягы...

*2002*

## Табыну

Бер сүзгә дә кайчак ышаныч юк,
Йә сабырлык җитми, йә әдәп.
Юк, иблискә җаным сатылмады,
Фәрештәсе аның – Мәхәббәт.

Еллар үткән саен күреп киләм,
Сафлык иле – бары Шәригать.
Омтылышы җанның – шушы кыйбла,
Хак Тәгалә, дога. Табигать.

Олы мәгънә, илаһи моң эзлим
Көнкүрештән, кылган һәр эштән.
Бир ышаныч миңа, Табигатем!
Ташлама син мине, Фәрештәм!

Юанычым, ышанычым бетсә,
Шигърияте калыр – иманым.
Мәхәббәт тә, моң да, хакыйкать тә
Шунда миңа. Шунда җиһаным...

*1983*

## Таңнар яктысы

Кояш сүнде диеп еламадым,
Кара төскә көннәр буялгач.
Уянсам да кайчак ыңгырашып,
Тыным чыгармадым уянгач.

Күпме калды тагын? Үз юлымның
Үттем кебек инде яртысын.
Ә шулай да гомер иртәседәй
Каршы алам таңнар яктысын.

*1983*

## Тормыш

Рәхмәт сиңа игътибарың өчен, Тормыш,
Ямьле булды чынбарлыгың, ялганнарың.
Үткән көннәрне санадың моңа кадәр,
Хәзер инде санийсың тик калганнарын.

Рәхмәт сиңа мәрхәмәтең өчен, Тормыш,
Соңгы көнем белән миңа янамадың.
Үткәннәрне тезеп күрсәтсәң дә арттан,
Калганнарны алга тезеп санамадың.

*1985*

# Тәрәзәдә ут

Каршы йортта утлар сүнә,
Яңа тәүлек башлана.
Тик бер генә тәрәзәдә
Сүнми һаман ут яна.

Килүләрме, китүләрме
Утны сүндерми тота?
Кемдер берәү кайгыданмы
Йоклый алмый ут йота?

Әллә инде бер яшь шагыйрь
Вакыт узганын сизми,
Елый-елый шигырь яза,
Ут яндырып сүз эзли?

Ул янган ут мине борчый,
Сәбәбен белмәсәм дә.
Төннәр буена сүнми ут
Минем дә тәрәзәмдә...

*1979*

# Туръ булган, имеш...

Кем булдың – яхшы беләсең,
Тик кем идең – онытма.
Кемлегеңне белим дисәң,
Өреп кара болытка.

Күктә тузан да селкенмәс
Җил-давыллардан тузган.
Шул болытлар арасында
Син дә бит тик бер тузан.

Җиргә хуҗа булдым диеп
Тузынган тузаннардан,
Гасырлар бусагасында
Пычрак өеме калган.

...Кем булдым – бераз чамалыйм,
Кем идем – гел хәтердә.
Дөньяларны өреп йөрткән
Бер Алла хуҗа җирдә.

*2002*

# Урам этләре

Ах, бу урам этләренең
Җан көйдергеч карашы.
Түзә алмый сызлый башлый
Сынык күңел ярасы.

Карый, мескен, ышанмыйча,
Таяк атканны көтеп.
Өмет өзгән кешелектән
Хуҗасыз урам эте.

Карама син үпкә белән,
Үз кайгым да минем күп.
Кит! Карама! Үз-үземә
Хуҗасыз мин синең кук.

Зарланма язмышка, дускай,
Була төрле хуҗалар.
Чылбырын чәйнәп елаган
Йорт этләре җирдә бар.

*1978*

## Урманда Кыш

Ак мендәрләр куеп ылысларга,
Кыш черем итә төнге урманда.
Язны күреп төшендә, саташып,
Егыла да төшә ак юрганга.

Мендәр тотып арган яшь наратның
Җиңеләйгән иңе күтәрелә.
Куркып уянган Кыш ачулана,
Агачларга чатнап бәрелә.

*1980*

## Хәнҗәр каләм

Хәнҗәр бирдең минем кулга,
Ә очында гади каләм.
Каурый кебек җилгә очкан
Сүзләргәдер бу ишарә...

Каләмең телгәли җанны, –
Язганнар бит моннан элек
Йомшак каурый каләм белән
Үткен сүзләр, хәнҗәр кебек!

*1984*

# Хөснелбанат түти

Хөснелбанат түти, син бердәнбер
Әниемнең өлкән апасы.
Ятимлеге, ачлыклары белән
Төшкән сезгә тормыш җәфасы.

Шөкер, Ходай гомер биргән сиңа.
Моңландыра кырыс сүзләрең.
Сиңа гына карап төсмерлим мин
Әниемнең кара күзләрен.

Озак яшә әнкәм төсе булып,
Авыр чакта изге теләк бул.
Әнкәм кебек һаман сөйкемле син,
Истәлек бул, хәтер, терәк бул.

Көн саен биш намаз укыганда,
Мәхрүм итмә изге догаңнан.
Кичер безне – сансыз ятимнәрне,
Язмыш юлларында югалган.

*1996*

# Хуш инде, авылым

Хуш инде, авылым, хуш инде,
Нигәдер күңелем буш инде.
Кытыршы кулларың җылысын
Онытмый саклармын, хуш инде.

Син инде, авылым, син инде
Җырларым моңына тиң инде.
Тәнемне бирсәң дә читләргә,
Җанымны бирмәгән син инде.

Юк инде, авылым, юк инде,
Юллар киң, тамаклар тук инде.
Ярым ач, ярым тук йөгереп,
Без йөргән сукмаклар юк инде.

Чит инде, авылым, чит инде,
Арада күренмәс чик инде.
Никадәр сагынып кайтсам да,
Бу газиз урамнар чит инде.

Хуш инде, авылым, хуш инде,
Җанымны тәнемә куш инде.
Без йөргән сукмакта чит эзләр,
Безнеке түгел син, хуш инде.

*1987*

# Шәкәр апа

Кемең бар соң анда, дип сорыйлар...
Күңел ерак юлга ашыга.
Беркемем юк, ләкин, Шәкәр апа,
Син чыгарсың әле каршыга.
Мең мәхәббәт, мең бәрәкәт белән
Балаларың кайта ай саен.
Мең мәшәкать шулар арасында
Мин – алтынчы үги малаең.
Балачактан бирле бу капканы
Ничә тапкыр ачып яптым мин.
Биш малаең белән авылымның
Яшел бишегендә яттым мин.
Ялган шәфкать яисә ачу белән
Кимсетмәдең моңлы күңелне.
Гаепләрем күреп, дәшми генә,
Күпне әйтә белдең түгелме?
Авыл буйлап кайтып килгән чакта,
Туган йортым булыр җимерек.
Күрше йорттан, каршы алырга дип,
Син чыгарсың әле иң элек.

*1985*

## Юл читендә кызлар

Тән бирүләр – җан бирүдер.
Юл читендә тере мәет.
Җан сатып, тән ватып кына
Булмыйдыр ул, булмый баеп.

Бар байлыгым – җан саулыгым.
Җан сыеныр тәне юк бит!
Ни тапса да, ни капса да,
Тәме юк бит! Тәме юк бит!..

*2003*

## Язгы этюд

Җир җыерчыкларын урый
Ташкын сулар толымы.
Кышның ак сөтен суыра
Язның ала колыны.

Ә кояш, болыттан качып,
Кырлар белән үбешә.
Ялгыз каен юл буенда
Елый-елый су эчә.

*1979*

## Язмыш үче

Кызганмадың бу кызыңның балачагын,
Кем уйлаган язмыш үчен алачагын.

Өзгәләнеп чит кулларда балаң калды,
Качып чыкты, артыгыздан елап барды.

Гомер буе елап килде, булды артык.
Аннан алда куып җитте менә картлык.

Хастаханә һәм ялгызлык оҗмах түгел.
Зәгыйфьләндең, сабыйландың инде бүген.

Кызың килә. Ник елыйсың күргәч аны?
Телгәлиме күңелеңне сабый җаны?

Кызың үчсез. Аш китерә палатага.
Ага сабый күз яшьләре, ашка ага...

*1982*

## Мылтык

Ул, кечкенә улын ияртеп,
Мылтык алып, чыкты бакчага.
Күзен кысып ялгыз чыпчыкка,
Тыныч кына басты чакмага.

Күр әтисен, ничек төз атты!
Сынатмады улы алдында!
Туктый алмый елый баласы
Каны тамган чыпчык янында...

*1978*

## Яшьтәш дустым Фидаилгә

Шундый буладыр инде ул
Иллегә җиткән ир-ат.
Утырмадың кул кушырып,
Кемнәндер ярдәм сорап.

Ир белән ат яшәгәннәр,
Гомер буе җигелеп.
«Ир-ат» сүзенең асылы –
Таяныч һәм игелек.

Шундый буладыр инде ул
Иллегә җиткән ир-ат.
Укыдың, бала үстердең,
Төзедең нигез-торак.

Бакча утырттың җир сөреп,
Эштән эшкә җигелеп.
Ходай биргән һәр көнеңә
Шөкер иттең иң элек.

Җылы яңгыр, сау иминлек
Теләнеп түгел, сорап,
Калган барысын булдырдың,
Иллегә җиткән ир-ат.

Җиңелеп түгел, җигелеп,
Кылган эшең – игелек.
«Ир-ат» дисәк тә, син әле
Илле яшьлек ир-егет!

*2000*

# *Егетләр...*

*(Кайбер мәкаләләрне укыгач)*

Сәхнәләрдә каһарманнар түгел,
Бер сәгатьлек хәлиф кебекләр.
Күрә торып гөнаһ эшлисез бит,
Нәрсә булды сезгә, егетләр?

Бу гөнаһ бит тән языгы түгел,
Зур хисаптан, иман бәясе.
Сезгәме соң әрсез җаһилләрнең
Алларына келәм җәясе?

Милләтнең чын әдип-батырлары
Рәнҗетелә көн дә кадерсез.
Ул исемнәр тарих булып калыр...
Кемгә табынасыз хәзер сез?

Көн-заманга сылтап, йөгереп кенә,
Иман сатып кайтып килешме?
Күнеккәннәр өчен – гадәти эш,
Ә сезгә бит бер дә килешми.

Сез идегез безгә иман-кыйбла,
Чын шагыйрьләр. Тукай кебекләр,
Вакланасыз... Аннан акланасыз...
Нәрсә булды сезгә, егетләр?

*2001*

# *Дүртьюллыклар*

*

Искитәрлек табигатьнең
Сүзсез кисәтү теле:
Җирдә иң матур чәчәкнең
Сабагы чәнечкеле.

*

Сезнең күңел – кырдагы тай,
Белә ерак җилләр тәмен.
Аңламый түгәрәк буйлап
Чапкан алашаның хәлен.

*

Нинди кош ул өстән генә
Бик масаеп очып бара?
Канат белән һәркем оча,
Син канатсыз очып кара.

*

Авыр сүз әйтеп ташладым,
Усалланган бу, димә.
Йомшак булса да кулларың,
Зинһар, ярама тимә.

*

Күрше йортта бик күңелле –
Хуҗа кунагын сыйлый.
Тик нигәдер эте генә
Чылбырын чәйнәп елый...

*

Күпне күргән кеше күп сөйләмәс,
Күп өргән эт килеп тешләмәс.
Күп сөйләгән кеше беркайчан да
Сөйләгәне кадәр эшләмәс.

*

«Вак мәшәкать, ыгы-зыгы һәр көн саен,
Бу борчудан азат итче, и Ходаем!»
Кабул булды бу гариза, җавап килде:
«Җибәрермен хәзер сиңа Газраилне...»

*

Җиргә егарлык кайгыны
Күтәрерлек көч тапканмын.
Синең кебек зур бәхетне күтәрерлек
Батырлыкны югалтканмын.

*

Икебез дә ялгыз бергә,
Сөйләшергә сүзебез юк.
Синең миңа, минем сиңа
Искитәрлек серебез юк.

*

Ахырын һәм башын белми араларның,
Вакытын һәм яшен белми дөньяларның,
Әкрен генә Галәм буйлап агып барыш,
Ә күңелдә Галәм кебек чиксез сагыш...

*

Төшкә давыл керде, җилтерәтте мине,
Аяусыз һәм явыз көч булып.
Бик еракта, чын давылда кемдер
Сындымы миңа төш булып?

*

Яр буенда тамырлары ярым ачык,
Яфраклары өстә сары уттай яна.
Ялангач һәм бәйләп куйган адәм кебек,
Агач үзен каплый алмый азаплана.

*

Хисләр кайнар, серләр эссе, тын кысыла,
Саф тугрылык күле бездән һаман ерак.
Өзмә әле, өзмә җаның төймәләрен,
Шәрә күңел шәрә тәннән яманрак.

*

Бүләгеңне алмыйм. Җан иясе
Хөр хәрәкәт өчен туган ич!
Читлектә кош, чылбырда эт тоту –
Минем кулдан килми торган эш.

*

Шигъри күңел шундый инде,
Хыялдан хыял туа.
Кемдер яулык болгый дисәм,
Ул тик тәрәзә юа.

*

Һәрнәрсәнең үз вакыты, үз җае бар,
Вакытында тик җай табылмый.
Җае чыга аның гомер узгач,
Тик бу инде сиңа кагылмый.

*

Куе томанга ябынып
Йоклаганда җир,
Биек тауларга абынып
Егылгандыр җил.

*

Тән сакчысы йөрткән адәм
Тапсын җаны сакчысын кайдан?
Тәнен ваткан ишме хәтәр,
Әллә иманын алган шайтан?

*

Кемне эзләгәнем үзем белмим,
Нәрсә җитмәгәнен белсәм дә.
Сылуларга күзем бик тиз төшә,
Торып булмый беркем белән дә.

*

Итәгендә чишмә агып яткан
Тау башында кое казыма.
Моңлы көйдән үз телеңне өйрән,
Җырлы язмыш шулай языла.

*

Йөгерәм мин гүя тормыш язы буйлап,
Гөрләвектән кояш чәчрәтеп.
Алда әле егыласы көннәр,
Алда әле ачы хәсрәтем.

*

Җим эзләгән кош шикелле,
Сүз эзләдем җан атып,
Канатымны канатып...

*

Шәм ялкыны сары яфрак кебек,
Кара болыт күләгәсе өйдә.
Күзге мәхәббәт яңгыры
Шаулый бер көйгә...

*

Каурый-мамык оча җилдә,
Карап тора сабый.
Гүя язмыш-киләчәккә
Читтән әле карый.

*

Уку – яктылык кынамы?
Карада кара теләк.
Укымышлы кабахәтнең
Ачуы мәкерлерәк.

*

Кызыкмасыннар көнләшеп
Байлыгыңа.
Сөенерләр бирәр кайгың
Барлыгына.

*

Хуш ис бөркеп,
Сынын йөртеп,
Узып бара.
Түзеп кара...

*

Каһәрләнеп, рәнҗетелеп тик торганда,
Качар юлсыз бер почмакта кыйналганда,
Карусыз ат котырынып бер тибенер,
Юаш эт тә ахыр чиктә тешли белер.

*

Әй җилкендек, әй эзләдек тә соң
Яшьлек буйлап хыял аръягын!
Һәр тамчысы бәхет булган икән
Без колачлап йөзгән дәрьяның...

*

Егылсак та, әле көрәшербез,
Кирәк икән – басып үләрбез.
Тормыш безгә биргән гомер хакын
Без артыгы белән түләрбез.

*

Заман буйлап килә мәхәббәт –
Эчкерсез һәм чиксез мәрхәмәт.
Тик танымый аны беркем дә
Тук, ваемсыз, чуар төркемдә.

*

Сөю үтә, илһам китә, моң өзелә,
Терәк бетә. Бетми ир-егет,
Караш җиткән офык аръягында
Безгә күренмәгән җир кебек.

*

Җылы нурларга ачылып, давыл килгәч,
Ябылырга өлгермәгән гөл шикелле,
Яктылыкка, яхшылыкка омтылып тик,
Тормыш өчен бу көрәштә ул җиңелде.

*

Бер гомергә мең мәхәббәт эзләп,
Хыялларны ваклап өлгердек.
Кайда калдың икән син адашып,
Бер мәхәббәт, ә мең гомерлек.

*

Тырный-тырный тәнне юган чакта,
Тирләр, керләр ага, югала.
Вөждан җанны күпме тырнаса да,
Чыкса чыга җаның, кер кала.

*

Бәхет кошы кунды түбәгезгә,
Ике канат – ике терәк ул.
Каерылган канат – каурый түгел,
Чәлпәрәмә килгән йөрәк ул.

*

Ерак бәхет – ул безнеке түгел,
Безнең бәхет шушы мизгелдә.
Суга куйган ямьле чәчәк кебек,
Шиңми әле, ләкин өзелгән.

*

Син курыкма минем кырыслыктан,
Каты җәеп, йомшак салырмын.
Өметләрең аклый алмасам да,
Ышанычың аклый алырмын.

*

Кыс тешеңне, җый көчеңне,
Ваклыклардан күтәрел.
Ахры, һәркем гомерендә
Ут аша бер үтәдер.

*

Балачакны һаман оныталмыйм,
Истәлекләр җыям моңланып.
Әйтерсең лә поезд киткән инде,
Ә мин нидер көтеп соңладым.

*

Ике җырчы, ике тавыш. Җыр агыла җанга якын.
Беренчесе – югары хис, икенчесе – түбән акыл.
Бер талпынып күтәрелә, бер бәрелә җиргә янә,
Җир белән күк арасында моңлы күңел өзгәләнә.

*

Көпчәк астында туп шартлап,
Соңгы тапкыр хәлсез сикерде.
Бер кызчыкның шары күккә очты,
Үле тупның җаны шикелле.

*

Акыллылар һәр ел саен акыллырак,
Ә тиледән һәр ел саен акыл ерак.
Берәр җүнле сүз әйтәсең килер беркөн,
Тик тыңламас һәм ишетмәс сине беркем.

*

Исем биргән илһам җимешләрең бүген,
Убырылып, чорлар чоңгылына инде.
Үз-үзеңә исең китеп карап торсаң,
Былтыргы дан бер тиенгә тормый инде.

*

Кояшта да таплар бармы?
Безнекедәй таплар булса анда әгәр,
Җирне күптән караңгылык каплар иде,
Ә ул яна. Яктылыгы үзе кадәр.

*

Ишеткәнсең сүз. Лаек булгач түз.
Уймак – уеннан, гөнаһ – куеннан.
Каплама күкне. Яңгыры күпме?
Утырасың бит суда муеннан.

*

Тере мәет кебек, бу дөньяның
Нурсыз йөзен көн дә күрсенме?
Бер өйләнгән икән – торсын! Димәк,
Бер чирләгән икән – үлсенме?!

*

Тәмле, диеп күпме генә кылансаң да,
Балык башын озак чәйнәп булмый инде.
Хәмер тоткан куллар белән югары аң
Омтылышын һич тә бәйләп булмый инде.

*

Бу сикереш, бу җикереш – бик җиңел эш.
Җиңеллеге кадәр бардыр аның хакы.
Күзләр өчен ярыйсы ук бер күренеш,
Күңел өчен бушка үткән әрәм вакыт.

*

Тынгысыз җан күккә үрли –
Дан кая, ирек кая?
Менгән саен, гамь арта тик,
Богаулар авырая.

*

Кай арада якты кояш җәйге таңда
Аяз күкнең куначасына сикерде? –
Ерак офык диңгезеннән калкып чыкты,
Су төбендә батып яткан туп шикелле.

*

Аптырама сүз ишеткән саен.
Ниятең, шәт, изге юлдадыр.
Нәрсә әйтелсә дә, сүз – чүп бит ул,
Кем әйтә бит – хикмәт шундадыр.

*

Иркен генә, җиңел генә яшик әле,
Авырлыклар үзе килеп таба торыр.
Каш җыерып, бүксә киереп йөргәннең
Сөенечкә бәхет юлын яба торыр.

*

Безнең кебекләргә табыналар,
«Сөбханалла!» диләр кайвакыт.
Сезнең кебекләргә абыналар,
Сүгенәләр дөнья шаулатып.

*

Мәхәббәттә, моңда, нәфрәттә
Нигә әле болай мин янам?
Еллар узар... Көлке күренерләр
Болар барысы да берзаман.

*

Йөз ел сыя кайчак бер күз карашына,
Мизгел генә аны күрсәң дә.
Аңламаган һич аңламый инде,
Сөйли-сөйли егылып үлсәң дә.

*

Кыска булыр безнең бу очрашу,
Аңлатып та булмас барысын.
Аерыла юллар – мин үрмәлим өскә,
Синең аска төшеп барышың.

*

Олырак та, моңлырак та идең инде
Яшь-җилкенчәк сөйгән кешеңнән.
Синең гомер – алда, яшьлек – артта,
Сөю – буш уртага эленгән.

*

Чүп кенә ул бер кешелек тормыш,
Тере туа тора тередән.
Безнең гомер боз яңгыры кебек,
Җәен явып, җирдә эрегән.

*

Син дәшмисең, мин дә түзәм,
Җитә бездә кирелек.
Әйтерсең мең гомер алда,
Сөюгә чик юк кебек.

*

Җирдә бернинди киртә юк
Без генә белгән сергә –
Үзебез кавышмасак та,
Хыялларыбыз бергә.

*

Көзге юеш юллар буйлап
Китеп бара безнең Вакыт,
Җиргә яткан яфракларны
Урыннарыннан кузгатып.

*

Мәңгелек сер, гомерлек чир
Сыкрый күңел түрендә –
Сискәнеп, үксеп, иреннәр
Иреннәргә үрелә.

*

Вак усаллык колы булмам һич тә,
Вөҗдан яза хөкем сүземне:
Мин кичердем сине, тик беркайчан да
Гафу итмәм инде үземне.

*

Тирә-якта һава шундый тынчу,
Тынсыз калып җиргә ятырлык.
Бу заманда чәчәк булып шыту –
Тиңсез, ләкин соңгы батырлык.

*

Мәхәббәтне туздыргансың, инде кире китерәсең,
Исәп-хисап таләп итеп, истәлекләр җимерәсең.
Беренчедән, әрәм иттем бит мин сиңа күпме көчем,
Икенчедән, вак акчам юк өлешеңне бирер өчен.

*

Чын җырчылар белән бер рәттә ул.
Моңлы ташкын – бу көй агышы.
Бик тырышып ул да җырлый кебек,
Якын килсәң – чыкмый тавышы.

*

Ана – ана инде гомерлеккә,
Балам, ди ул көн дә, балам, ди.
Ә баласы: «Ун сум алган идең,
Кайтармыйсың, әни, һаман»,– ди...

*

Ни булса да, якты дөнья көчсезлектән
Кан-яшь түгәр өчен төзелмәгән.
Ачы язмыш кара тартма түгел әле,
Чебен булма бер файдасыз безелдәгән.

*

Кырыслыктан минем курыкма син бер дә,
Ул бары тик калкан кебек, күңел өчен.
Никадәрле ватылмаслык булса тышым,
Шулкадәрле саф һәм йомшак минем эчем.

*

Горурлыгың гүзәл җанлы булсын,
«Исеменә лаек!» дисеннәр.
Исеме юк тәкәбберләр түгел,
Җир терәге – горур исемнәр.

*1970–2003*

# ТУГАН ТЕЛЕМ ХӘРЕФЛӘРЕ

## *Туган телем хәрефләре*

Һәй, туган телем сулышы,
«Һе»ләре һәм «җе»ләре,
Җилләре һәм җиләкләре,
Җимнәре, энҗеләре.

«Әү!» дип аваз салулары,
Томау төшкән «эң»нәре.
Берәү, икәү, өчәүләре,
Йөзләре һәм меңнәре.

Үсә-үсә «ү» хәрефен
Үчти-үчти аңлатыр.
Көн дә үсә, төн дә үсә
Камыр батыр, Таңбатыр.

«Ә» дигәнең – әткәй-әнкәй,
«Ө» дигәнең өй булыр.
Өч кенә сүз, ике хәреф –
Моңлы, ямьле көй булыр.

«Әннә» дигән беркөн нәни,
Аннан соң «әттә» дигән.
Әттәсенең-әннәсенең
Түбәсе күккә тигән!

Көйдән көйгә, өйдән өйгә,
Сөяксез бу хәзинә,
Йә сөйдерә, йә биздерә,
Йә җиңелә, йә җиңә.

Һәй, туган телем сулышы,
«Һе»ләре һәм «эң»нәре,
Энҗеләре, мәрҗәннәре,
Йөзләре һәм меңнәре.

Көзге җилдә җепкә тезгән
Җиләк кебек «җе»ләре.
Җил котырган, җеп өзелгән,
Сибелгән энҗеләре...

*1999*

## Алия рәсеме

Бер сеңелкәш ямьле сурәт ясый иде,
Ике кояш элеп куйды күк йөзенә.
Карап торам – ниндидер бер сәер җиһан
Күз алдымда кәгазь битендә төзелә.

Ике кояш... Бигрәк сәер... Шулчак, имеш,
Бер «акыллы» фикер килә минем башка:
Әллә бу кыз яшәгәнме икән әүвәл
Чит Галәмдә, башка үлчәнештә башта?

Мыж киләләр сирәк вә зирәк фикерләр,
Бер кояшлы безнең җиһан тар аларга...
Ә кыз башын күтәрде дә әйтеп салды:
«Җылы күбрәк булсын җирдә балаларга».

Мин оялдым шулчак бераз уйларымнан.
Һәркемнең дә күңелендә үз Галәме, –
Абзаң кысыр хыял фараз кылган чакта,
Чебеш хәтле бу сабыйда дөнья гаме.

*1987*

# Мәктәп белән саубуллашу

Балачакның соңгы чәчәкләрен
Өзә яшьлек тормыш кырында.
Ак алъяпкыч аның иңнәрендә,
Ак канатлар моңсу җырында.

Бу көннәрнең тиңсез чәчәкләрен
Хәтерләрдә ничек сакларга?
Йөрәкләрдә бер үк моң булса да,
Уйлар инде төрле якларда.

Нишләргә соң, вакыт үткән җирдә
Чык коела, шиңә гөлләр дә.
Җырлар тына, күңел тынычлана,
Тоныклана үткән көннәр дә.

Бер килербез әле, җыелышып,
Ак чәчәкләр үскән урынга.
Төрле моңнар булыр йөрәкләрдә,
Ләкин уйлар – мәктәп турында.

Бүген безнең күңел кочагында
Гөлләргә тиң еллар бәйләме.
Шиңмәс кебек алар беркайчан да,
Күңелләрдә җырга әйләнеп.

Ак чәчәкләр белән саубуллашып,
Яшьлек йөри тормыш кырында.
Алъяпкычын тиздән онытыр ул,
Тик канатлар калсын җырында.

*1986*

# Әбиләр һәм бабайлар

(Жыр)

Кайт кунакка, балам, диеп,
Хәбәр килде авылдан.
Әби белән бабай безне,
Күрәсең, бик сагынган.

К у ш ы м т а:

Искән җилгә әйтеп калам,
Әйтәм күктәге айга –
Бездән сәлам җиткерегез
Әби белән бабайга.

Кайтмый түзеп буламы соң?
Бәйрәм көне җитә бит!
Тәрәзәдән күзен алмый,
Алар безне көтә бит!

К у ш ы м т а.

Күчтәнәчкә чәй алырбыз,
Чәй янына җимешен.
Кизүләре читтә йөрсен,
Борчулары кимесен.

К у ш ы м т а.

Догалары кабул булсын,
Табыннары мул булсын.
Җәен-кышын, язын-көзен
Өзелмәслек юл булсын.

К у ш ы м т а.

Кайтабыз дип, кайтабыз дип,
Кошлар кебек кагындык.
Әби белән бабайны без
Үзебез дә сагындык.

К у ш ы м т а.

*2001*

## Гөлбикә

Аягын бәрде Гөлбикә,
Бик авырткандыр инде.
Әнисе янына тизрәк
Кычкырып елап килде.

«Кая, кызым, күрсәт»,– дигәч,
Тынып калды Гөлбикә.
Кайсы аяк бәрелгәне
Онытылган да икән.

*1981*

## Ничек?

Киемнәрне салып ташлап
Йөгердек су буена.
Чыр-чу килеп, онытылып,
Малайлар су коена.

Көтмәгәндә аяз күкне
Килеп каплады болыт,
Без чамалап өлгергәнче
Ява башлады коеп.

Утырабыз су эчендә,
Елашабыз бер көйгә –
Ничек кенә чыланмыйча
Кайтып җитәргә өйгә?..

*1981*

## Беренче кар

Күзләр үткән. Бүген иртән
Кыш та җиткән икән.
Ә бәләкәч Әлфиянең
Моңа исе киткән:

«Җир өстенә, ап-ак итеп,
Нәрсә япканнар?» – ди.
Агач башындагы карга
Аңа әйтә: «Кар-р!» – ди.

*1982*

## Җәйге төндә

Салмак кына учак яна,
Сихри тынлык тирә-якта.
Күк йөзендә күпме йолдыз
Пышылдаша безнең хакта.

Пошкыралар атлар. Кайчак
Учак чатный очкын чәчеп.
Ат көтүен саклап яту –
Җәйге төндә безнең кәсеп.

Нәрсәдәндер өркеп бер ат,
Дөп-дөп басып килеп җитте.
Йолдызларны коя инде...
Әнә берсе төшеп китте!

*1982*

# Чаңгы ярышында

Физкультура дәресендә
Булды чаңгы ярышы.
Без җыендык. Хәмит кенә
Торды бераз карышып.

«Ярамый, – ди, – миңа ярыш,
Минем тиз хәл бетә», – ди.
Ә соңыннан шул чабышны
«Бишлек» итеп үтәде.

Аптырадык. Ул елга бер
Тота чаңгы таягын.
Хәмит көлә: «Тиленәрнең
Күп йөрер, – ди, – аягы».

Ләкин белдек, мактанырлык
Эшләр монда юк икән.
Хәмит әйләнчек җирләрне
Турыдан гына «кискән».

Укытучы сизмиме соң
Искитәрлек бу серне? –
«Бишле» әйләнчек булыр дип,
Куйды туп-туры «берле».

*1980*

# Шикәрле чәй

Әни: «Кара, кызым, – ди, –
Чәйгә бер шикәр салам.
Аннан соң тагын берне,
Ничә булды, әйт, балам?»

Чәйне озак болгаттым,
Шикәрләрне югалттым.
Тәмен татып карагач,
Хәйләле уйга баттым.

Әни түзмәде, әйтте:
«Әллә, кызым, син надан?»
Мин әйтәм: «Аңламадым,
Кабатлыйк өр-яңадан!»

Әни әйтә: «Болай да
Өчне салдым шикелле...»
Ә мин әйтеп җибәрдем:
«Ялгышасың, икене!..»

*1982*

# Халык язмышы

Афәт килгән таптап балачакны,
Көйрәп яткан дошман үткән җир.
Уникешәр яшьлек бала-чага
Уникешәр сәгать түккән тир.
Аңлаганнар алар барысын да,
Ашыктырып вакыт агышын,
Күтәрергә илгә булышканнар
Олыларның олы сагышын.
Инде хәзер кара чынбарлыкны,
Замананың яман чирләрен
Күрсәтикме, юкмы сезгә, диләр,
Балачакның ямен җибәреп?
Илдә хәзер башка көрәш бара,
Татар өчен көн дә бар хәтәр.
Күпме булса гамьсез битарафлык,
Куркыныч та хәзер шулкадәр.
Көрәшчеләр кирәк ышанычлы,
Зиһенле һәм моңлы күңелле.
Вак фикерле, надан, таш йөрәкләр –
Коллык өчен нигез түгелме?
Сезгә үрнәк – тарих битләрендә,
Сезнең моңнар – халык җырында.
Сезгә кодрәт китаплардан килә,
Сезнең көрәш – уку кырында.
Авыр булса кайчак, онытмагыз,
Дүрт гасырдан артык ел үткән –
Баласы да, анасы да бергә
Казансуга күпме кан түккән.
Уен-көлкеләрдән генә тормый
Халкыбызның ачы язмышы.
Хаталанмыйк! Җитәр! Телебезгә,
Җиребезгә яшик ябышып.
Сөйләшергә кирәк, серләшергә,
Бетсен коры үгет-нәсихәт.

Бүгенге бу шаулы заманада
Күренмичә ята Хакыйкать.
Ә балачак үзенекен итәр,
Уены да булыр, чыны да.
Үз җирендә хуҗа булыр өчен,
Кечкенәдән кеше чыныга.

*1986–2003*

## Эт

Әй сикерә, уйный, якын килсәң!
Тамагы тук.
Яшәве ару.
Күзләрендә генә чагылып китә
Ниндидер бер мескен ялвару.

Белсәң иде, чылбыр буе ирек
Нинди кыска! Ничек газаплы!
Син уйлыйсың аны уйный диеп,
Ә ул сорый синнән азатлык...

*1981*

# Җимерелмәс манаралар

Бәләкәчләр юеш комнан
Манаралар төзиләр.
«Төзүче булып уйныйбыз,
Шәһәр салабыз»,– диләр.

Усал малай килеп чыкты,
Туп тотып, әллә каян.
«Мин монда футбол уйныйм, – ди, –
Бу җиргә капка куям!»

Шулай диеп, бар көченә
Типте бер манарага.
Ни булды? – Усал малайның
Күзләреннән яшь ага!

Сәбәп шунда, бер бәләкәч
Төзергә бик ашыккан,
Тиз булсын дип, манараның
Эченә кирпеч тыккан...

*1980*

# Кечкенә хуҗа

Чакырганнар кунакка
Әти белән әнине.
Өйдә бүген хуҗа итеп
Калдырмакчылар мине.

Әни әйтә: «Кечкенә
Түгел инде син, улым.
Күз-колак бул сеңлеңә,
Син бит минем уң кулым.

Без югында, көнозын
Мал-туарны ач тотма.
Сеңлеңә ботка ашат,
Акбайны да онытма».

Барысын да җентекләп
Әни аңлатып китте.
Ярый, эшкә тотыныйм,
Төш вакыты да җитте.

Сыер, әни югында,
Торыр, калган аш ашап.
Тавыкларга печән бар,
Акбайга салам башак.

Сарыкларга – җим. Ботка –
Бәтиләргә, билгеле.
Ә аннан соң сеңлемә
Кала юкә миллеге.

...Ахмак малай бу димәгез,
Эткә башак бирмәдем.
Кызык итим әле диеп,
Юри бутап сөйләдем.

*1983*

# Әйберләр фетнәсе

Сикергәләп, зур-зур атлап,
Үз-үзенә җыр такмаклап,
Сызгыргалап дәртле көйгә,
Рәшит кайтып керде өйгә.
Килде җәйләр, уку бетте,
«Икеле»дән курку бетте.
Шулкадәрле балкый алыр
Комлап юган җиз самавыр.
Авызы да камыр кебек,
Җәелә гел юктан көлеп.
Кайтып керде, салды сөрән:
«Әни, тагын өч-дүрт көннән
Чыгабыз без сәяхәткә,
Табигатьтәге рәхәткә
Велосипед белән һәркем.
Мин гармун алам, дип әйттем.
Чөнки туктап һәр авылда,
Концерт куячакбыз юлда!»

Инде әйбер җыя башлады,
Кайсын алды, кайсын ташлады.
Әйберләре аның күп иде,
Кайсы кирәк, кайсы чүп иде.
Чүп булса да, матур, кыйбатлы,
Хаҗәте аз, ләкин бит затлы!

Ошатмады бу походны әйберләре,
Ачуланып шыгырдады кайберләре.
Зәңгәрләнде ачуыннан телевизор:
«Хәзер инде аңа мин дә кирәкмимдер,
Ничә сәгать минем янда булды элек,
Көйсезләнсәм, боргалады җаем белеп,
Ташламады, иптәшләре чакырса да,
«Күзең бетәр!» дип, әнисе кычкырса да.

Башка миңа шундый тугры иптәш тумас,
Ахры, чынлап, бераз күзен бозмый булмас...»

Ялтыратып яшел күзен,
Магнитофон башлый сүзен –
Ике кәтүк тасма суза,
Тасма җыр кабызып уза,
Барабаннар дөбер-шатыр,
Сүзләр ясый синтезатор:
«Хали-гали, буги-вуги,
Мин Рәшитнең колы түгел,
Аңа үзем хуҗа күптән,
Гармун уйнар чагы үткән,
Телгәләдем телем-телем
Туган җырын, туган телен,
Оныттырдым моңын-зарын,
Җирнең ямьле авазларын,
Моң сибүен гармунчының,
Чишмәләрнең көмеш чыңын,
Кош сайравын, яфрак шавын,
Кышларын кар шыгырдавын,
Күктән тамчылар агышын,
Чалгы кайраган тавышын...
Башына чүп-чар тутырам,
Гармунын да оныттырам,
Әйләнсен ул саңгырауга,
Иялэнсен минем шаугa».

Кызды сарайда мопед:
«Нигә ул велосипед?!
Күрсәтермен мин аңа,
Мин бит әле өр-яңа!
Биш ат көчем бар чакта,
Уяу торырмын сакта!
Педаль әйләндерүне
Һәм җәяүләп йөрүне

Онытсын ул гомергә,
Миннән төшмәсен бер дә.
Югалсыннар сукмаклар,
Тапталмасын яуган кар,
Бетсен аякта терәк,
Хәлсез сикерсен йөрәк,
Машина бассын җирне,
Һәр адәм булсын чирле.
Тырылдап тора мотор,
Төтене зәңгәр, матур,
Колакларны тондырам,
Хуш искә коендырам.
Мин ексам күпме батыр,
Һушын җыялмый ятыр.
Велосипедка, имеш,
Утырырга ул тиеш.
Мопед уенчык түгел,
Егып имгәтәм бүген!..»

Эңгер төшә, күзләр бәйләнә,
Рәшит тагын урам әйләнә,
Мопед белән кичке сәгатьтә,
Керел китте шулай гадәткә:
Магнитофон башта тыңлады,
Телевизор карап соңлады,
Күзләр күрми, колак ишетми,
Көчкә эзләп тапты ишекне.
Пыр туздырып бөтен урамны,
Оча Рәшит, юллар караңгы...
Төтен белән тузан, ургылып,
Капладылар Киек Каз Юлын.
Якты уты төште куакка,
Куркып очты кошлар як-якка.
Бар табигать куркып уянды,
Теше тешкә тими куянның.
Үз-үзләрен куркак керпеләр

Инәләргә тизрәк төрделәр.
Ояларда калды нәниләр,
Табылырмы барлык әниләр?
Табылырмы барлык оялар?
Кая бара соң бу дөньялар?
Язның айлы матур кичендә,
Үле тынлык төтен эчендә.

Кинәт дөнья бетте шикелле,
Күктән күпме йолдыз сибелде,
Җир әйләнә Рәшит тирәли,
Тукмый, таптый, ташка бәргәли,
Һәм, ниһаять, тынлык яңадан,
Тик әйләнә көпчәк һавада...

Муенына кулын асып,
Аягына йомшак басып,
Хастаханә буйлап килә бер малай,
Әйе, әйе, ул Рәшит бугай.
Әйе, әйе, мөмкинме соң ялгышырга –
Тирә-якны күмеп килә шаулы җырга –
Әйберләре коллыгыннан
Ычкынмасын диеп ялгыш,
Муенына асылынган
Кеп-кечкенә радиоалгыч...

*1985*

# Маратның «намус көндәлеге»

*(Яңа ел әкияте)*

Берзаманны һәммәбезгә өләштеләр
«Намус көндәлеге» дигән билет-дәфтәр.
Яңа елга керер вакыт җиткәч, имеш,
Шул билетны һәркем күрсәтергә тиеш.
Кем ни уйлый, кем ни сөйли, ни кыла, ди –
Ел буена шул дәфтәргә языла, ди.
Һаман уйнап, эшләмәгән эшләреңне,
Ялкауланып чистартмаган тешләреңне,
Вәгъдә биреп, үтәмәгән сүзләреңне,
Алдаганда йомылмаган күзләреңне
Шул дәфтәргә теркәп килеп һәр очракта,
Карыйлар, ди, Яңа елга кергән чакта.
Ләкин әле керер өчен Яңа елга,
Тиеш анда игелек тә язылырга.
Игелекләр белән үлчәп ялгышларны,
Хәл итәләр сакчылар, ди, язмышларны.

Марат килде Яңа елның ишегенә,
Бүген монда халык аның ише генә –
Бала-чагалар чираты бу арада.
Билет сорый сакчылары бусагада.
Билет карап, күрсәтәләр алга таба,
Кайберәүләр ут капкандай кире чаба.
Һәр ялгышын, калган эшен, ялган сүзен
Төзәтергә мәҗбүр саный һәркем үзен.
Менә Марат дәфтәренә күзен сала,
«Биш дәрестән качты» дигән җөмлә таба.
«Бетте баш!» ди, инде ничек төзәтергә,
Керер өчен иптәшләре белән бергә?
Аптырагач, үткен кайчы алып кулга,
Кисеп алды ялгышларын буйдан-буйга.
Телгәләнгән кәгазьләргә күзен салса –

Язулар бар ике якта да лабаса!
Әйбәт эшләр өчен икән икенче як,
Менә нинди җөмлә анда (һәр сүзе хак):
«Ярдәмчесез бер әбинең хәлен белеп,
Ташып торды кибетләрдән азык-төлек...»
Җиңел генә котылам, дип, яманаттан,
Күпме игелекне Марат кисеп аткан!

Тыз-быз килеп, арлы-бирле йөргәләде,
Иске елда югалырга теләмәде.
Керә алмый калган кебек шәп киного,
Менеп, сикереп карады зур коймага.
Әнә Вакыт машинасы бара үтеп,
Мәңгелекне айлар, еллар итеп сүтеп.
Көпчәге дә, чаңгысы да үз янында,
Йөзә хәтта диңгез суларында.
Очып чыга ала хәтта Галәмгә үк,
Вакыт эшли алмаган эш дөньяда юк.
Марат машина астына таш ыргытты,
Тәгәрмәченә нык, озын таяк тыкты.
Ләкин Вакыт бара, бара Яңа елга кереп,
Таш уалды, сынды таяк шырпы кебек.
Инде өмет менә-менә өзелгәндә,
Марат күрә – килә ашыгып бер бәндә.
Килә теге таныш әби, чана тартып,
Ә чанасы инде иске, сынык, ватык.
Әби мескен килә-килә хәлдән тайган,
Вакыттан ул инде күптән артта калган.
Тормышының авыр йөге – чанасында,
Мәшәкатьләр һәм борчулар арасында.
Авыр елларда тагылган зәхмәт-чирләр,
Иген игеп, урман кисеп түккән тирләр.
Үтсәләр дә ачлы-туклы заманалар,
Телгәлиләр җанын-тәнен һаман алар.
Авыр булса да кайвакыт иске елда,
Кем тели соң артта калып тукталырга?

Марат түзмәде, йөгереп килеп җитте,
Үзен-үзе әби чанасына җикте,
Үз иңенә алып борчу-мәшәкатен,
Чанадагы тормыш йөген җиңеләйтте.
Юк-бар үпкә-сагышларын тотып атты
Һәм әбигә җылы, йомшак урын тапты.
Чанада ул рәхмәт укып утырадыр,
Марат чана тарта, буран котырадыр.
Буран уйный, Вакыт оча, Вакыт үтә,
Инде елның соңгы мизгелләрен сүтә.
Чанасы да җиңел түгел, җил дә каршы,
Ләкин Марат һаман алга бара ярсып.
Соңгы мизгелләр чаң булып суккан чакта,
Туктадылар Яңа елда, яңа якта.
Сакчылар да каршылыксыз юл бирделәр,
Булыштылар һәм «Хәерле юл!» диделәр.

Вакытыңнан артта ерак калмыйм дисәң,
Киләчәккә горур, тыныч атлыйм дисәң,
Кызганмыйча шәфкатеңне, егәреңне,
Бушка үткәрмичә тиңсез көннәреңне,
Ашыгырга, ашыгырга кирәк алга –
Игелекле ямь өстәргә бу дөньяга!

*1983*


Поэмалар

# Чокырча* тавы

Безнең тауны тау дип әйткән чакта,
Ак түбәле таулар үпкәләр.
Тау – тау була, әгәр күкрәгенә
Ак болытлар кагылып үтсәләр.
Мактанырлык булмаса да аның
Биеклеге, иң һәм буйлары,
Без бу таудан очтык, тәвәккәлләп,
Канат итеп хыял-уйларны.
Болытларга түгел, йолдызларга
Очып җитү безнең хыяллар.
Юлда сынып калган каурыйларны
Яшьрәк, ныграк дуслар җыярлар.
Җыярлар да, яңа канат ясап,
Табар алар бәхет юлларын.
Ләкин онытмаслар безнең тауны
Чокырчаның моңлы улларын.
...Ул сузылган биек дулкын кебек,
Түбәсендә арыш кырлары.
Инеш булып ага чишмәләре,
Итәгендә борма юл ярып.
Таудан бәреп чыккан бу су юлы
Тормыш юлы кебек бормалы.
Су буенда үсә бөдрә таллар,
Чишмәләрдән бетмәс көч алып.
Давыл-бураннардан ышыкланып,

---

* Чокырча – туган авылым Аман Оштырманың иске исеме.

Таллы итәгенә сыенып
Яшәгәнгә авыл, авыр чакта
Күбрәк тауга төшкән кыенлык.
Китүчеләр тауга менеп киткән,
Таудан төшкән – өйгә кайтканнар.
Ил тетрәгән чакта, тау тетрәгән,
Еллар аккан, аккан ал каннар.
Соңгы озатучы юлчыларны
Һәм беренче каршы алучы.
Үз авылын күреп хозурланган
Тау башында торган һәр юлчы.
Китүчеләр тауга әкрен менгән,
Кайтучылар төшкән йөгереп.
Кайтучылар һәрчак әзрәк булган,
Тауны күргән алар иң элек.

...Тау сукмагын инде чирәм баскан,
Бетеп килә җәяү йөрүләр.
Картайды тау. Онытылды бераз.
Авыл бетә. Тиздән тау үләр.
Авыл кими. Заман шулай куша.
Үзәк утар матур булачак.
Тик танымый мондый матурлыкны
Тау буенда үткән балачак.
Ә алдагы буын яңа җирдә
Таусыз туган ягын яратыр.
Безгә генә шулай авыр булыр
Чокырчаны читкә тарату.
Авыл күчә. Җансыз тау кала тик.
Булмый, булмый тауны күчереп.
Онытмагыз тауны, китүчеләр,
Безнең истә чакта ул тере.

Әйе, без бу таудан очкан идек,
Тәвәккәлләп, тормыш күгенә.
Югарыдан кырлар чиксез кебек,

Алдагы юл киңрәк күренә.
Дөнья серле, чиксез кебек иде.
Күңел киләчәккә ашкынды.
Бата-калка кичүләр дә булды
Кайгы-хәсрәт тулы ташкынны.
Иң авыры... Әни иртә үлде...
Китек иде күңел, түземле.
Таудан төштем йөгереп, тик соң иде,
Әйтми калдым соңгы сүземне.
Сөймим озак кан-яшь агызырга
Һәм изәргә хәсрәт измәсен.
Шуны телим: әнкәм каберенә
Аяусызлар якын килмәсен.
Яңа очкан бәхет кошчыгының
Бер канатын давыл каерган, –
Тормыш төпләп кенә килгән парны
Мәңгелеккә сугыш аерган.
Сыңар канат – сыңар бәхетсезлек,
Күтәралмый бәхет күгенә,
Талпынып та дөнья киңәймәгәч,
Башын салган каен төбенә.
Ул җырлаган җырлар онытылмый,
Аның җаны – сагыш кыясы.
Әгәр дә мин шагыйрь була калсам,
Һәр шигырем – әнкәм мирасы.
...Тау каршында зират каеннары,
Хәтерлисезме сез мине дә?
Ә мин сезне онытачак түгел,
Әнкәм кабере кала биредә.
Сөймим озак кан-яшь агызырга
Һәм изәргә хәсрәт измәсен.
Шуны телим: әнкәм каберенә
Дуслар чәчәк куймый китмәсен.

Шушы таудан безне кабул итте
Зур мәктәбе күрше авылның.

Таудан читтә сиздек ачылыгын
Кар-буранның, җилнең, давылның.
Кышкы тауга бизәк булып ятты,
Сырлап менгән чаңгы эзләре.
Кайткан чакта кайчак, «очып» төшеп,
Чаңгы сыныкларын эзләдек.
Таудан читтә җилләр каты исә,
Сулар тәмсез, тормыш аяусыз.
Җиңел түгел кырыс бу дөньяда
Яшәү туган яксыз һәм таусыз.
Таудан бергә тәгәрәгән дуслар
Инде күптән үсеп җиттеләр.
Тәннәренә сеңгән тау егәрен
Тормыш арбасына җиктеләр.
Мин үзем дә хәзер таудан ерак,
Башка биеклеккә үрмәлим.
Бизәк булып кала каләм эзе,
Давыллардан, җилдән шүрләмим.
Белмим әле чын бәясен бүген
Үзем сызган «сырлы эзләрнең».
Тик шулай да әгәр «очып төшсәм»,
Бәхет сыныкларын эзләрмен.

Шушы таудан кабул итте инде
Зур мәктәбе кызу тормышның.
Тик азаплый безне сагыну чире,
Бу авыру, ахры, йогышлы.
Якташларны читтә күп очраттым,
Һәркем безнең тауны сагына.
Мин дә кайтып сихәт алдым бераз
Кукмараның таулы ягына.
Тауны онытмаган дуслар белән –
Нәрсә безгә юллар, кыенлык! –
Әнкәм итәгенә сарылган күк,
Мин дә кайтып тауга сыендым.

Ахры, тауның җанын ала инде
Замананың кызу еллары.
Онытмагыз тауны, онытмагыз,
Чокырчаның моңлы уллары.
Җансыз түгел ул тау безнең өчен,
Халык кебек моңлы, түземле.
Һәм ышану моңа авыр түгел,
Киңрәк ачсаң күңел күзеңне.
Авыл кими. Заман шулай куша.
Матур үзәк утар салалар.
Тудырырлар яңа балаларны
Тау буеннан күчкән аналар.
Бу алдагы буын яңа җирдә
Ямьле туган ягын яратыр.
Безгә генә шулай авыр булыр
Чокырчаны читкә тарату.
Еллар имин торсын. Авыл күген
Капламасын сагыш рәшәсе.
Балаларның күңеле кителмәсен
Һәм әниләр озак яшәсен!
Авыл күчәр. Күпме еллар узар.
Иске йортлар череп таркалыр.
Тик истәлек булып мәңгелеккә,
Авыл шәүләседәй, тау калыр...

*1978*

# *Алмагачлар сагышы*

*Безнең балалар йорты урнашкан һәм гомеремнең кечкенә генә бер кисәген үзенә алып, гомер буена онытылмаслык хисләр калдырган Субаш Аты авылына багышлыйм*

## Балалар йорты

– Менә, улым, әтиеңнең өе...
– О, шундый зурмы?

Әйдә, дустым, бер сөйләшик әле,
Хәтер сандыкларын актарып.
Барып кайтыйк күмәк йортыбызга,
Сагындырды Арча яклары.
Еллар үткән саен хәтерләрдә
Тоныклана ерак мизгелләр.
Бер-беребездән без дә читләшәбез,
Вакыт кыса, хисләр изелә.
Бәхетсезлек безне бергә җыйды,
Ризык, ышык бирде туган ил.
Ә таратты бәхет-хыялларны
Ерак офыкларга куган җил.
Җил генә дә түгел, давыл иде
Ул вакытта безнең күңелдә.

Шул давылда купкан тузан белән
Күпме шашкын уйлар күмелгән.
Чаптык алга, уңны-сулны күрми,
Качкан кошчык кебек читлектән.
Читлек булмады йорт, тик ни чара? –
Юллар ачык, егет җитлеккән...
Булмас, беркем, беркем дә хурламас
Ул чактагы кырыс елларны,
Еласак та кайчак, юрган белән
Башны каплап, кысып тыннарны.
Никтер шулай, истә гел яхшылык,
Онытыла үпкә-сагышлар,
Һәм борчыйлар, кайчак искә төшеп,
Бары үзебезнең ялгышлар.
Хәер, кемнәр генә хәтерлидер
Һәр тойгының көнен, сәгатен.
Кем әйтмешли, нигә актарырга?
Яшә күреп дөнья рәхәтен.
Ләкин күңел сулар сибеп саклый
Балачакның гөлле каберен.
Аңлап булмас кебек, гөлләр шиңсә,
Яшәү ямен, тормыш кадерен.
...Ярыйсы ук ерак таралыштык,
Күп хисләрне еллар юдылар.
Һәркемнең дә тормыш урамында
Үзе сайлап алган юлы бар.
Ул елларның ерак тамырлары
Кушылалар тик бер урында.
Әйдә, дустым, җырлыйк бер утырып,
Ап-ак алмагачлар турында.
Утыр, дустым, бер сөйләшик әле,
Искә алыйк малай чакларны.
Уйнап җибәр «Алмагачы» көен,
Сагындырды Арча яклары.

## Алмагачлар

Алмагачы чәчәк ата
Майның унбишләрендә.
*Татар халык җыры*

Ап-ак чәчәк, ап-ак чәчәк –
Алмагачларның бәйрәме.
Язның бакчага бүләге –
Ап-ак чәчәкләр бәйләме.
Бакчалардан ташып керә
Күңелләргә саф яктылык.
Һәрбер бакча – җиргә төшеп
Кунаклаган ап-ак болыт.
Чәчәк исе, чәчәк исе,
Баш әйләнә, йөрәк ярсый.
Бүгенгедән киләчәккә
Уйдан хыял болыт ясый.
Аерыла болыт җирдән,
Хыял җиленә карышмый,
Җир офыгы киңлегеннән
Күңел киңлеге калышмый.
Алмагачлар арасында,
Шушы йортта, шушы якта,
Бу безнең соңгы языбыз,
Соңгы борылыш бу чатта.
Имтиханнар алда, әле
Комнан хыяллар ишәбез,
Түбәләргә менеп ятып,
Тигезләмәләр чишәбез.
Тигезләмәнең бер ягы
Һәрвакытта да нуль була.
Шул нульләрне сыга-сыга,
Белем исемле күл тула.
Ләкин менә... алмагачлар,
Җылы кояш, чәчәк исе,
Какшаталар бар зиһенне,
Сихри җилләр булып исеп.

«Икс»ларның чын йөзләрен
Ачам, дисәң, ахыр чиктә,
Ап-ак болыт уйларыңны
Үзе белән элеп китә.
Һәркемнең дә уйларында
Алдагы юллары туры.
Һәркем бага, өмет итә
Җирдәге бәхетнең зурын.
Кар сулары күңелдәге
Гамьсезлекне юадыр ул.
Матурлыкка карап кына,
Матур уйлар туадыр ул.
Алмагачлар, алмагачлар,
Сихерләдегез бит тәмам.
Алда соңгы имтиханнар,
Ә мин уйларымда янам.
Табигать дигән Җәннәтнең
Бер почмагы – бакчагызда.
Ярый миңа, алма бирми,
Чәчәк кенә атсагыз да.
Чәчәк белән күңелләр тук,
Матди уйлар ялда әле.
Алма кирәк булыр вакыт
Алда әле, алда әле.
Үзебез дә чәчәк әле,
Килер алма булыр чаклар,
Алма булып авырайгач,
Билләребез әле чатнар.
Әчесе дә, баллысы да –
Ул бакчада барысы бар.
Түп-түгәрәк күңелләрне
Язмыш тешләп-тешләп карар.
Матурлыкка карап кына,
Матур уйлар туа шул ул.
Яши торгач, тормыш гаме
Хыялларны юа шул ул.

## Субаш-Аты

Гәрчә анда тумасам да,
Мин бераз торган идем.
*Г.Тукай*

Алмагачлар арасында
Гади авыл – Субаш-Аты.
Җәе җылы, кышы салкын,
Төне кара, көне якты.
Туган түгел, үги авыл,
Күңелгә җыр салган авыл.
Туганнарсыз калганнарны
Асрамага алган авыл.
Әллә нәрсә данлы түгел,
Холкы тыйнак, халкы моңлы.
Бар шәп укытучылары
Елмаеп искә алырлык.
Аз үсмәде ул авылда
Шәп егетләр, чибәр кызлар.
Бер чибәрен искә алып,
Ахры, йөрәк озак сызлар.
Кырлай якын ул авылга.
Урманындагы һәр нарат
Хәтерлидер күк Тукайның
Хәл җыйганын күккә карап.
«Тамашалар» куеп йөрдек
Күршедәге авылларда.
Җырладык та, биедек тә,
Сыздырып пар гармуннарда.
Субаш-Атыга гыйшкымның
Әллә сәбәбе шул инде:
Аерым-аерым кайгыларны
Күмәк күңеллелек җиңде.
Субаш-Аты, Субаш-Аты,
Назлы авыл, ямьле авыл.
Язгы чәчәкләре белән

Алды күңелемнең явын.
Туган түгел, үги авыл,
Йөрәкләрдә калган авыл.
Асрамага алганнарны
Туган итә алган авыл.

## Этюд

«Кимсетелгәнлек һәм ятимлек хисе,
ахры, мине гомер буена ташламас инде...»

*Бер хаттан*

Йөрәгемә үк уелып калган никтер,
Бер карасаң, гади генә бер күренеш:
Мич янында басып тора үксез малай,
Бөрешүдән кулын кулга кушкан килеш.
Беренчеме, икенчеме сыйныфта ул –
Хәтерләмим. Хәер, анысы мөһим түгел.
Нинди болыт каплаган соң ул мескеннең
Иң ваемсыз вакытының якты күген?
Күзләрендә шундый сагыш һәм моңсулык,
Ә йөзендә балалыкның эзе дә юк.
Нигә һаман җылыналмый соң ул бала? –
Мичкә яккан, өсте бөтен, тамагы тук.
Ятыйм дисә, ап-ак чиста урыны бар.
Киим дисә, бүреге бар, бишмәте бар.
Бар шуклыгын эшкә җигеп уйныйм дисә,
Үзе кебек дистәләгән иптәше бар.
Рәхмәт, рәхмәт балаларны багучыга,
Рәхмәт мичкә җылы итеп ягучыга.
Ләкин малай һаман туңа, һаман моңсу
Һәм кулларын һаман җиң эченә тыга.
Мич җылысы, тән азыгы монда көчсез.
Кулы түгел, ә күңеле аның туңа.
Әтисенә, әнисенә ул кирәкми,
Һәм җылынмый ул өшегән күңел шуңа.

Ярый, безнең сыенырлык беркем дә юк.
«Юк» дигәнне балалар да яхшы аңлый.
Аңлау авыр, «бар» икәнен белә торып,
Аны шулай үксез иткән бу дөньяны.
Мин хәтерлим, кайчак аны күрер өчен,
Килә иде тып-тын гына сәер ханым.
Һәм шулай ук тып-тын гына китә иде,
Кузгатып һәм ымсындырып сабый җанын.
Нәрсә соң бу? Аңсызлыкмы? Кансызлыкмы?
Мәҗбүр итте нинди сәбәп һәм авырлык?
Бармыни соң бу дөньяда шундый сәбәп,
Үз баlаңны чит кулларга ташлатырлык?
Аңлыйм кебек – тормыш кору җиңел түгел,
Кайчак ташка башны бәрердәй буласың.
Ләкин басып күз алдыма теге малай,
Бар аңымны таптап, изеп, тукмап ташлый.
Гомер буена күз алдымда ул никтер,
Бер карасаң, гади генә бер күренеш:
Мич янында басып тора үксез малай,
Бөрешүдән кулын кулга кушкан килеш.
Яшьлек үтә, ләззәт бетә, гомер кыска,
Озын бары картлык кына – үлем көткән.
Таянырлык байлыклар да табылмаган,
Яшьлек дигән алтын вакыт инде беткән.
Гомер үтә. Карт ятимнәрне өшетеп,
Юанычсыз, салкын, тын ялгызлык кала.
Ә кайдадыр тормыш корып, эшләп йөри
Таза, матур, бөтенләй чит... газиз бала.
Эх мескеннәр, әти-әниләр «элекке»,
Әйтер сүз дә, хөкем дә юк сезгә никтер.
Бу гаепләү белән хөкем арасында
Шушы юллар үталмаслык, ахры, чиктер.
Уянырсыз, уянырсыз, тик соң булыр.
Җир кечкенә, гомер кыска, таяныч юк.
Тагын нәрсә җитми сезгә җылынырга? –
Өйләр җылы, өсләр бөтен, тамаклар тук...

## Истәлекләр

Иртән торып тышка чыгам,
Кош куам алмагачтан.
Сезнең хәлегезне сорыйм
Сайраган сандугачтан.

*Татар халык җыры*

Ул бакчаны урап үсә
Койма кебек каеннар.
Шул каеннар белән уртак
Якты серләребез бар.
Өстә каен, аста куак,
Кырыйлары текә яр.
Шул яр буйлап, алма урлап,
Чапкан чакларыбыз бар.
Мүк шикелле тыгыз үскән
Карлыганга бакча тар.
Җиргә посып, ирен белән
Җиләк өзгәнебез бар.
Алмагачлар ишеткәндер
Күпме шатлык, күпме зар.
Кайгы-хәсрәтләрне шунда
Чыгып түккәнебез бар.
Җилфер-җилфер килә каен,
Телсез түгелдер лә ул.
Ак кәүсәсен ялтыратып,
Көнгә карап көлә ул.
Җилфер-җилфер килә каен,
Җансыз түгелдер лә ул.
Көзгә карап бер елый да
Язга карап көлә ул.
Бакчаны кочып үсә лә
Яшел койма – каеннар.
Шунда чыгып, сөйгәннәрне
Көткән чакларыбыз бар.
Өстә каен, аста куак,

Кырыйлары текә яр.
Шунда посып, иреннәрдән
Сөю өзгәнебез бар.
Сулык-сулык, җилфер-җилфер,
Сыгыла бөдрә каен.
Белүчеләр бармы соң ул
Гомерлек сөю җаен?
Җилфер-җилфер җилләр исә,
Чайкала бөдрә каен.
Чәрдәкләнә ак кәүсәләр,
Бөҗралар арткан саен.

Ай-һай, сыгылулары ла,
Каен түгелдер лә ул.
Тавышын чыгармаса да,
Үз газабын белә ул.
Сыкрап-сыкрап сыгыла ла,
Таштан түгелдер лә ул.
Үткән-беткән, көзләр җиткән,
Үз язмышын белә ул.
...Сыгыла каен салкын җилдә,
Каерылып ял сорый,
Алга карап уйлана да
Үткәнгә карап елый.
Алда еллар. Калды җырлар.
Яшь күңелгә дөнья тар.
Еллар буйлап, сөю урлап
Чапкан чакларыбыз бар...

## Уналтыдан узып барганда

Безнең хәзер тиң чагыбыз, тиң чагыбыз
Былбыл балаларына, Асылъяр.

*Татар халык җыры*

Төнге няня Фагыйлә апа усал иде,
Һәрбер төне безне саклап узар иде.

Уналтыдан узып барган малайларга
Сәгать унда йокларга гел кушар иде.
Безнең язлар гади язлар булмады шул,
Күңел көннәр белән генә туймады шул.
Таң атканда кайтып кереп ятар өчен,
Тәрәзәне дуслар бикләп куймады шул.
Тәрәзәдән тып-тын кереп ятар идек,
Күзне йомып, хыялларга батар идек.
Шул вакытта Фагыйлә апа килеп кереп,
Юрганнарны өстән алып атар иде.
«Каян кердең? Әле монда син юк идең!
Ах, мут егет, ахры, оятың юк синең!»
Әллә чынлап ачулана... Безгә нәрсә,
Киләсе төн буш урыннар шул ук иде...
Алмашчысы Миңниса апа юаш булды,
Елмаюы гашыйкларга кояш булды.
Ул булганда таң атканчы, сүз беткәнче,
Тик үзебез төнебезгә без баш булдык.
Уйламагыз, яшьтән артык без тузмадык,
Кирәкмәгән урыннарга кул сузмадык.
Барыбыз да әйтә алыр иде кебек:
Безнең сөю үбешүдән дә узмады.
Миңниса апа әллә безне аңлый иде,
Әллә безне егетләр дип санлый иде.
Фагыйлә апа гына һаман шулай безне
Күз дә йоммый гөнаһлардан саклый иде.
Теләгем юк, бу яхшы дип, бу начар дип,
Бу сүзләрдән һәркем нәтиҗә ясар дип,
Чагыштырып күрсәтергә. Хәзер уйлыйм,
Һәркемнең ерактан үз яме бар дип.
Шунсы дөрес: Фагыйлә апа усал иде,
Һәрбер төне безне саклап узар иде,
Унҗидегә җитеп килгән егетләргә
Сәгать унда йокларга гел кушар иде...

## Соңгы сәлам

Китәм, бәгърем, китәм, бәгърем,
Каласың Арчаларда.

*Татар халык җыры*

Кимсетмәде Субаш-Аты,
Йөзләп идек, күпсенмәде.
Яраларга кагылмады,
Күп сорашып төпченмәде.
Безнең өчен оекбашлар
Бәйләделәр аналары.
Үлчәп бәйләгән шикелле,
Төгәл иде чамалары.
Карт-карчыкка без дә килеп
Су ташыдык, утын кистек.
Артык сүзсез, бергәләшеп,
Көннәр ердык, еллар кичтек.
Үсеп җиткәч, көзгә кергән
Кошлар кебек таралыштык.
Кияү биреп, килен алып,
Тормыш өчен яр алыштык.
Субаш-Аты, халкың җансыз,
Тупас түгел иде бер дә.
Хет хәзер дә кунакка кайт,
Күчтәнәчләреңне төр дә.
Икеләнми әйтәм: һәркем
Кочак җәеп каршы алыр,
Кибеткә чабар, бәйрәм дип,
Ашка итен күбрәк салыр.
Искә алыр саклык белән
Ул тынгысыз елларны да,
Ил буйлап таралган, уртак,
Кызларны да, улларны да.
Юк, кимсетмәс Субаш-Аты,
Йөзләп кайтсак та күпсенмәс.
Онытса да күбебезне,

«Деттум» дисәң, күп төпченмәс.
Онытсаң да, без күп идек,
Син бер генә, Субаш-Аты,
Яныңдагы инешләрдән
Инде күпме сулар акты.
Истәлекләр генә һаман
Сулар белән китми агып,
Сөйләшергә сүз сорыйлар,
Күңел тәрәзәсен кагып.
Ерагайган арабызга
Еллар һаман киртә кора.
Ялваралар җанлы хисләр,
Каләмемнән сурәт сорап.
Матур чыккандырмы, юкмы –
Менә инде сурәт әзер!
Иң мөһиме, еллар корган
Киртәләр юк безгә хәзер.
Бу сурәт сәламем булыр
Сезгә, ерак ак каеннар.
Сәлам сиңа, Субаш-Аты,
Моңлы үги малаеңнан!

## Саубуллашу

Нинди генә матур итеп сөйләсәң дә,
Чит-ят илләр туган ил булмый.

*Татар халык җыры*

Ярый, инде саубуллашыйк, Субаш-Аты,
Ахры, озак синең белән күрешмәбез.
Ахры, синең чибәрләрең белән башка,
Агачларга сыена-сыена, үбешмәбез.
Бүтән төшмәс минем янга, су буена,
Ак тасмасын җилфердәтеп бер акыллың.
Бүтән булмас урамыңда гармун уйнап,
Моңга күмеп, җилкендереп бар авылны.

Һәр заманның үз вакыты, үз кызыгы,
Минем яшьлек алмагачлар белән калды.
Шуңа күрә ул ташландык ялгыз бакча
Сиңа тугры күңелемә сагыш салды.
Хәтер җиле кагылуга яңгырыйлар
Синнән миңа тарттырылган моңлы кыллар.
Кереп чыккан кунак йорты кебек итеп,
Һич онытып булмый сине ничә еллар.
Бәхет килсә, бер кайтырмын синең янга,
Кочакласрмын өй янында өч каенны.
Битем куеп чәрдәкләнгән карт кәүсәгә,
Ишетермен безне сагынып шаулавыңны.
Ак тасмасын җилфердәтеп кызчыгының,
Танымыйча, бәлки, мине китәр узып,
Алмагачлар, ак чәчәкләр арасында
Өзелеп-өзелеп сөя белгән кыю кызың.
Танымаса танымаслар, гаеп итмәм,
Үзем генә хәтер утларында яныйм.
Мин үзем дә шул вакыттагы үземне
Еллар аша зур авырлык белән таныйм.
Ярый, сау бул, Субаш-Аты, күп сөйләштек,
Ә хәзергә тәмам итик бу язуны.
Җыйдым татлы һәм шифалы истәлекләр,
Ап-ак гүзәл чәчәкләргә куныл-куныл.
Мин ышанам – хушлашабыз тик хәзергә,
Бу язмалар синең өчен бик кечкенә.
Ап-ак чәчәк арасыннан эзләп табып,
Чыгарырмын әле сине ил өстенә.

*1980*

# *Фатыйма мәхәббәте*

## 1. Фатыйма

Каян алып, нинди сүзләр белән генә
Ясыйм икән, Фатыймакай, сурәтеңне?
Каләм алып кәгаземә кагылырга
Куркып торам, Фатыймакай, күрәсеңме?
Ничек кенә таушалган сүз, ялган белән
Кагылмаска синең матур исемеңә?
Сүз күп бездә, тик күбесе ясалма моң,
Чүп кичереш, буш хыяллар ише генә.
Шаулы хисләр, гамьсез сөю ялкыннары
Туң җаннарны эретерлек түгел инде.
Ә син, авыл юлларыннан килеп кереп,
Сискәндереп, өтеп алдың күңелемне.
Искитәрлек катлаулы бу тормыш җирдә.
Уйлый-уйлый кайчак хәйран каласың да,
Бер күрәсең – нинди упкын икән, бергә
Гомер иткән ике кеше арасында.
Гаҗәп кайчак кинәт, кискен борылышлар,
Күпме серләр, күпме яшерен агымнар...
Сорауларга җаваплар юк, тик шулай да,
Тауларга каршы агырлык бер агым бар.
Серле, шашкын һәм яшерен дә бу агым,
Күпме сорау анда, күпме гади җавап –
Кешеләрнең тазалыгын үлчәп була,
Күңелләрдә булган мәхәббәткә карап.
Фатыймакай, күңелеңнең бөеклеге

Кермәгәндер синең тыйнак уйларыңа.
Тәннәреңне җимерерлек бу кодрәтең,
Сыймагандыр нәзек, зифа буйларыңа.
Син бик ерак инде бездән, чиксез ерак.
Монда хәзер үзгәрешләр, тизләнешләр.
Сезнең авыл да, Фатыйма, бер яшәрер,
Абынмыйча алга барыр тиздән эшләр.
Тик үзгәрми торган әле нигезләр күп –
Моңлы хисләр беркайчан да искермәсләр,
Көз җитмичә, агач тизрәк җимеш бирмәс,
Аналар да тизрәк бала китермәсләр.
Хәер, җирдә нинди генә ачыш булмас,
Тик кешелек, нигездә, бик мәрхәмәтле –
Кабул итмәс үзгәрешле тиз хәтерне,
Тизләнештә яңартылган мәхәббәтне.

Вакыт җиткәч, Фатыймакай, синең янга
Килсәм иде, моң илендә сакта торып,
Исемең белән сискәндереп тук җаннарны,
Нигезләрдән аермаслык җыр калдырып.
Ә бу җырны мин язмадым. Үзем түгел,
Каләмемне йөртте сәер, моңлы тылсым.
Ул тырышты, Фатыймакай, үзең төсле,
Сурәтең дә якты, гүзәл сынлы булсын.
Мин бары тик карышмадым сихри көчле,
Каләмемне йөрткән якты истәлеккә.
Аянычлы, аянычлы булды бу җыр,
Гомер кайчак сыя икән бер тәүлеккә.
Рәхмәт сиңа, Фатыймакай, көтмәгәндә,
Сискәндереп, өтеп алдың күңелемне.
Бер башлагач, сүз табыла. Ни әйтсәң дә,
Синекедәй йөгем авыр түгел инде.
Кил, илһамым, канатлы ат булып миңа,
Тапталмаган яшел чирәм якын-тирәм.
Гомеремнең тәүлекләрен, икеләнми,
Мәхәббәт һәм хәтер өчен өзеп бирәм.

## 2. Фаҗига

Болай башланды фаҗиганең тарихы –
Чирләп егылды Фатыйманың Салихы.
Кичкә таба төгәлләп ул барлык эшен,
Капкан иде бер утырып тәмәкесен.
Суырды да катып калды мескен хәлдә,
Бар дөньяны каплап алды кара пәрдә.
«Әһ» тә итми, ул сыгылып төште җиргә,
Хәлсезләнеп батты юеш, салкын тиргә.
Бөтен тәнен кысып алды утлы кыршау,
Ишетелде агымсудай сәер бер шау.
Бу – шуышып килгән әҗәл шавы иде,
Кыяфәте аның хәсрәт тавы иде.
Күләгәсе – кара пәрдә килде алдан,
Әҗәлгә бер адым гына ара калган...
Кичке ашка чакырырга чыккандырмы –
Фатыйма бер мизгел һуштан язып торды.
Искә килеп, су китерде Салихына.
Кара күләгә чигенде бераз гына.
Коткарыгыз! Коткарыгыз бу бәладән!
Бар әле, бар алда гомер яшәлмәгән!
Читенсенми күзләренә туры карап,
Көйсез чакларында карышусыз ярап,
Ашлар салып тәлинкәсенә, тутырып,
Кара-каршы чәйләр куертып утырып,
Мәшәкатьтән мәхәббәткә күчкәч төннәр,
Урын җәйгән саен салып ике мендәр,
Тупырдатып балаларын, оныкларын,
Югын бар итеп һәм саклап кына барын,
Бар әле, бар алда гомер яшәлмәгән!
Коткар, Ходаем, Салихны бу бәладән!

Бәладән зиһен чуалса, ни кылырсың?
Алла түгел, әллә кемне чакырырсың.
Буш авылда, заман юллары читендә,

Яшәү тыныч, ләкин кайчак бик читен дә.
Кече авыл заман исәбеннән чыккан,
Адәм түгел, Алла да аны оныткан.
Элемтә дә, табиб та юк анда хәтта,
Күпме бәхәс кызып алды бит бу хакта.
Бәхәс булды ләкин яклап туган җирне,
Нык тамырлар үз йортында кала бирде.
Калды тагын, сукыр күзләр кебек, гамьсез,
Гөл үсмәгән тәрәзәләр җансыз, ямьсез...
Кая гына, кемне генә эзләп барма –
Карт алаша бар авылда, ватык арба.
Фатыймага соңгы өмет – шул ат калды,
Җигә белде, арбага Салихын салды.
«Әйдә, малкай, коткар безне, атла тизрәк,
Әҗәл куа, өлгерергә безгә кирәк.
Соңгы тапкыр коткар безне, эшләр яман,
Игелекле мал диләр бит сине һаман.
Соңгы булыр сиңа, малкай, бәлки, бу юл,
Шулай кирәк, кичер, зинһар, һәм... бәхил бул.
Кичер, малкай, җаным елый, йөрәк яна,
Суккан саен дилбегә белән аркаңа.
Тынсыз ята иң кадерле кешем минем,
Әҗәл куа, юк башкада эшем минем.
Исән калсак, карт күңелең итмәм китек,
Кадер-хөрмәт белән риза-бәхил итеп.
Коткар, малкай, тик син генә бар терәгем,
Рәнҗеп китмә, чыдамаса карт йөрәгең».
Фатыймакай елый-елый атын куа,
Күз яшьләре белән шул гөнаһын юа.
Карт алаша өркеп дөньясын оныткан,
Киерелгән күзләренең агы чыккан.
Юып була гөнаһларны елый-елый,
Тик әҗәлдән елап кына качып булмый.
Әҗәл куа арттан кара шәүлә кебек,
Өчесенең берсен алачагын белеп...

Картлыктамы, саулыктамы – кайда гаеп?
Ат чайкала башлый тиздән хәлдән таеп.
Газапларның бу әле тик башы гына,
Көтмәгәндә, каерылып, тәртә сына...
Нишләр иде монда акыллырак адәм?
Утырыр да елар иде көтеп ярдәм.
Ләкин туктатып булмады Фатыйманы,
«Юләрлектән» аны акылы тыймады.
Бәла килсә, һәркемдә көч арта, диләр,
Тарталмаслык йөкне кеше тарта, диләр.
Аты күренми, тик арба алга бара,
Фатыйманың кызу тәнен каеш яра...
Нинди өмет белән үзе җигелгәндер,
Әҗәл дә тетрәнеп бераз чигенгәндер.
Шаккаткандыр хәлсез карт алаша хәтта,
Арба һаман хәрәкәттә, хәрәкәттә!
Әкият һәм юк-бар могҗиза сөйләмим,
Могҗизаның тормыш икәнен беләм мин.
Тормыш шул бу. Сакла, илһам, чүп-чар сүздән!
Фатыйма да хәлсезләнеп туктар тиздән.
Әкрен генә сыгылып төшәр тезләренә,
Кирәк чакта юк машина эзләренә.
Сыгылып төшәр, тик туктамас ул өметсез,
Сырхау иргә кул селтәмәс игелексез.
Җилкәсенә салыр аны ахыр чиктә,
Коткарырга, коткарырга теләр бик тә.
Шул йөк белән әҗәлдән ул качып килә,
Тик әҗәл дә эзләренә басып килә.
Күләгәсе төшеп килә үзләренә,
Фатыйманың тоныкланган күзләренә.
Күңелендә сөйгәне, тик бер ул гына,
Күзләрендә кара пәрдә һәм юл гына.
Көч таба ул, мәхәббәткә тугры калып,
Алда калган гомер исәбеннән алып.
Алда әле үтеләсе күпме юл бар,
Җир чайкала, калтырыйлар аяк-куллар.

Юл читендә баганалар... баганалар...
Юлны тугел, гомерне үлчәп калалар.
Кара шәүлә булып арттан кырлар аша,
Әллә әҗәл килә, әллә карт алаша...
Юк, мин һич тә чүп-чар әкият сөйләмим,
Чын бәясен бу могҗизаның беләм мин.
Изге могҗиза бу! Илһам, сакла юк-бар сүздән!
Фатыйма бит бөтенләйгә туктар тиздән...
Шифаханә баскычына йөген салыр,
Ишек шакыр, башын күтәрми тын алыр.
Ишек ачык. Кемгә монда ярдәм кирәк?
Ә Фатыйма һаман шакый: тизрәк! тизрәк!
Соңгы тамчы көчен алган бер ишарә –
Салихына төртеп күрсәткән, бичара.
Һәм тынычлап ятып калган, изрәгән дә,
Йөрәгенең туктаганын сизмәгән дә.
Унбиш чакрым куып килгән әҗәл арттан,
Ә баскычта Фатыйманы гына тапкан...
Сөенечле хәбәр әйтергә чыкканнар –
Фатыйманың гәүдәсенә абынганнар.

## 3. Салих

Таң ата сызылып, таң ата кызарып,
Уяна басулар, урманнар.
Машина артыннан ургылып-ургылып
Агыла юлдагы тузаннар.
Машина эченә салынган мәетнең
Ак җәймә ябылган битенә.
Күптәнме әҗәлдән котылган Салих та
Утырган ак җәймә читенә.
Фатыйма янында, моңаеп, уйланып,
Кырларны күзәтеп кайта ул,
Уйлары иркендә. Беркем дә әйталмас –
Якынмы, еракмы – кайда ул?
Бер ватык арба юл читендә күренде,

Янында ауный карт алаша.
Аңламый, танымый үтмәстер, шәт инде,
Көчәнеп хәтерләп караса...

Мәетне юганда, аптырап, шаккатып,
Карчыклар елаган тын гына –
Пар күкрәк арасын сыдырып сузылган
Җәрәхәт алиһә сынына.
Салихның сагышын багарлык дәртем юк,
Күңеле ачылмас йозаклы.
Озакка сузмыйча (татарда шулай бит),
Мәетне зиратка озатты.
Ике көн моңайды... Дүртенче көн үтте...
Биш көннән төзәтте арбаны.
Кичен карт алаша җигелде... Тик Салих
Печәнгә, утынга бармады.
Килделәр ипле бер тол хатын йортына.
Капканы әллә җил ачтымы?
Ашыгып арбага төялде кемнеңдер
Сандыгы, юрганы, ястыгы...
Болытлар җыела. Яңгыры булырмы?
Ә ялгыз каенны җил бөгә.
Каеннан чишелеп, алаша өстенә
Сызгырып төште куш дилбегә.
«Йә, малкай, кузгалыйк, тиз атла, югыйсә
Чыланыр ястыклар, юрганнар!»
Ә артта болытлар, төн кебек күләгә,
Күренми басулар, урманнар.
Атлый карт алаша иснәнеп, пошкырып,
Киләме кемнедер таныйсы? –
Фатыйма тәненә ышкылып уелган
Каешта тир исе, кан исе...
Борынын киереп, күзләрен тутырып,
Алаша борылып карады.
Арбада таныш ис хуҗасы күренми,
Караңгы ул якта, караңгы.

Арбада чит хатын, ястыгын кочаклап,
Юрганын ышыклап утыра.
Һәм башын күтәреп болытка карый да
Салихка атны тиз кудыра.
Тузаннар туздырып, урамны тутырып,
Кем кайта Салихның йортына?
Җавап күп көттерми – озын куш дилбегә
Сызгырып төшә ат сыртына.
Чайкала алаша, гәүдәсе калтырый,–
Белмиләр кешеләр чаманы.
Йорт саен әрнеп ул арттагы елларын,
Арттагы юлларын санады.
Ташылды ничә ел утыны, печәне,
Капчыклап ташылды икмәге.
Тик әле беркем дә кан исе бөркелгән
Каешка уратып җикмәде.
Авырмы югыйсә ястыклар, юрганнар...
Ә бәлки,ояттыр аңа да?
Егылды ул кинәт Салихның йортына
Җитәргә өч адым арада.
Әллә бу түзмәслек сызлану булганмы?
Әллә бу әрнүле юл еккан?
Беренче тапкыр ул җигүдә егылды,
Картлыктан булмаса, хурлыктан.
Яшьнәде яшеннәр, күкрәде дөньялар,
Күктән су коелды чиләкләп.
Ә Салих күтәргән яңа мал-мөлкәтен,
Йөгерә кәләшен җитәкләп.
Алаша яңгырда чыланды, хәл алды,
Беркемне дә яшен сукмады.
Тузаннар басылды, игеннәр яшәрде,
Табигать ярсудан туктады.
Кич керде йортларга, кабынды утлар да,
Сузылып төн ята түбәгә.
Буш арба урамда. Алаша юк анда.
Пәрдәгә төшә пар күләгә.

Кызарып-кызарып, оялып таң ата,
Уяна басулар, урманнар.
Салихның йортында бернинди сагыш юк,
Коймада кибә чит юрганнар.
Яңа кич җитүгә, күмәк бу юрганнар
Кыйнала-кыйнала кагылыр.
Фатыйма исеме тузанга әйләнеп,
Басулар өстенә агылыр.

## 4. Хәтер

Тыныч тормыш телим сиңа, Салих,
Озак яшә, башка чирләмә.
«Шәхси тормышыма тыгылды» дип,
Шагыйрьне син берүк тиргәмә.
Чын күңелдән минем бу теләкләр.
Яраткан бит сине Фатыйма.
Шул хисләргә лаек бәндә булып,
Кайчак киләсең күз алдыма.
Гомер – яшәр өчен. Ахыр чиктә,
Кемдә кемнең нинди эше бар?
Бар икән шул. Җирдә үз гомерен
Безгә бүләк иткән кеше бар.

Мәңге яшәр өчен килгән кебек,
Нык нигезләр, йортлар салырга.
Соңгы көнне яшәгәндәй, көн дә
Сөйгәннәрне сөеп калырга.
Әйе – безгә! Туган халкыбызның
Хакы бардыр мондый шөһрәткә.
Кемдер кирәк һәйкәл куяр өчен,
Күктән төшмәгән бу кодрәткә.
Һәркемгә дә тормыш – соңгы тапкыр.
Беренче һәм соңгы, ахыргы.
Бер гомердә хәлләр була кайчак
Бар дөньяга чаңнар кагырлык.

«Шундый вакыт...» дибез. Вакыт, имеш...
Аның бездә нинди эше бар?
Кешелекне саклап килә Җирдә
Кеше булып калган Кешеләр.

Фатыймакай, еллар узган саен
Ерагая безнең арабыз.
Ләкин, хикмәт, ерагайган саен,
Сиңа таба без дә барабыз.
Очрашырбыз җирдә туфрак булып,
Якынлашып еллар буена.
Күтәрелеп җитә алмасак та
Синең биек, зифа буеңа.
Фатыймакай, зиратыңа килеп,
Шаулап үлән үскән урында
Кабереңә сибәм бу сүзләрне,
Уйлыйм һаман синең турында.
Иңгән кабереңә бу моңнарым
Сары яфрак булып коела.
Һәм юанам – син бу авазларны
Ишетәсең кебек тоела.
Кеше – биек. Син шул биеклекнең
Җаны булып миңа дәшәсең.
Мин ишетәм сине...
Исемең җирдә
Мәхәббәтне саклап яшәсен!

*1987*

# Җинаять эше

1

Болытлы кара төн төбендә
Тын калган караңгы авыллар.
Котырып-котырып җил исә,
Кайдадыр, күрәсең, давыл бар.
Җепшек кар кырларда, юлларда,
Кыш ае бит әле югыйсә.
Күкләрдә болытлар тәгәри,
Ыргылып-ыргылып җил исә.
Шаулашып чыршылар сыгыла,
Каеннар бөгелә чайкалып.
Шыгырдый капкалар, коймалар,
Түбәдән тамчылар тамгалый.
Сызгыра да улый – җил исә
Офыкка, упкынга убылып.
Кайдадыр эт өрә, эт елый,
Җил искән авазга кушылып.
Яз түгел әле бу, кырларга
Юлларын бутаган җил керә.
Адашып йөргәнен белгәндәй,
Аңа да, чит итеп, эт өрә.
Урамнар буш калган. Авылда
Көндезге мәшәкать тиз тына.
Чырасын сүндергән күбесе,
Ут алган бер-ике йорт кына.
Ялгышып адашкан җылы җил,
Йортларга сарылып зарлана –

Кышны яз итәрлек хәле юк,
Түбәдән тамчылар тамса да.
Төн үтәр, көн үтәр барыбер,
Киләсе төнгә кыш кузгалыр.
Басылган җылы җил юлында
Тайгак эз, мәкерле боз калыр.
Әлегә җылы җил кар кисә,
Көньяктан болытлар агыла.
Әлегә көн ягы адашкан,
Әлегә агым төн ягына.
Наратлар шаулашып сыгыла,
Тын гына чайкала каеннар.
Кайдадыр эт улый, эт өрә.
Кайдадыр, күрәсең, хәвеф бар.

2

Кырлар белән кырлар, урман белән урман,
Авыл белән авыл арасы.
Төнге юлда, соңга калып, әкрен генә
Атлый ике адәм баласы.
Әтисе дә улы. Аркаларда капчык.
Тагын биштәр ята чанада.
Ачыкканнар, талчыкканнар инде шактый
Икесе дә бер үк чамада.
Җепшек карга батып, җилгә каршы басып,
Сөенделәр күреп авылны.
«Ярый әле безгә итек киптерергә,
Ял итәргә урын табылды».
Әйтте әти кеше: «Түз, улым, түз бераз,
Хәл алырга өмет бар бугай.
Түз бераз, түз, ару гына сәүдә итсәк,
Өйләндерәм сине кайтуга.
Күрәсеңме алда утлы тәрәзәне?
Ерак түгел, әнә тегендә.
Иплэп кенә койма кагып карыйк әле

Шушы ышык капка төбендә».
Кемдер ишек ачкач, бер тибрәнеп алды
Сөенечле өмет кылы да.
«Кем бар?» – «Без һүнәрче юлчыларбыз идек,
Төн кунмак келибез җылыда».
Усал тавыш биргән хуҗа бәндә чыкты,
Ялт-йолт килде шомлы күзләре.
Баштанаяк карап бәя биргәннән соң,
Көтмәгәндә кисәк үзгәрде.
Бер алдында, бер артында юлчыларның:
«Әйдә, әйдә, рәхим итегез!
Мактап кына йөрисез лә икән безне –
Пешеп кенә чыкты итебез!»
Тешләренә тешләр тимәгәнгә инде,
Күзләрне дә күзләр күрмәде.
Йорт хуҗасы куштан Габделәхәт кенә
Үз уеннан үзе шүрләде.
Уйлар белән уйлар, юллар белән юллар,
Язмыш белән язмыш арасы.
Кайнар аштан изрәп, җылы мич башында
Йоклый ике адәм баласы.

3

Таң атканчы сәгать биштә үзе генә
Йөгереп кергән Габделәхәт күршесенә:
«Әй, Әхтәмҗан, тор әле, тор, уян тизрәк,
Аулак сүз бар, әүвәл киңәшергә кирәк!
Куна керде миңа Чистай мишәрләре,
Затлы тауар белән тулган биштәрләре.
Кесә-янчыклары да буш түгел бугай,
Сәгать биштә кузгалдылар тагын юлга.
Саба юлыннан Казанга барышлары,
Беркемгә дә ишетелмәс тавышлары,
Әгәр куып җитсәк урман уртасында,
Каенсарга китә торган юл артында...»

Юк, артык сүз кирәк түгел Әхтәмҗанга,
Барысы да аңлашылды күптән аңа.
Инкыйлабта күп кан койган бозык бәндә,
Большевиклар «яңа тормыш» төзегәндә,
Мәрхәмәтсез, таш йөрәкле, каты куллы,
Авылда да наган тоткан хаким булды –
Рәис иде сәвитләргә бик яраклы.
Чабатасын түргә элгән бу каракны
Урлап ашамаса туймас иде, диләр.
Чын булганмы, сөйли иде карт әбиләр:
«Оялмыйча күзгә карап көпә-көндез
Мал-туарны алып китә иде, денсез.
Ә урлагач, мыскыл итеп көлеп тора.
Дәшми беркем. Наган – хуҗа. Закон – ерак».

...Инде менә ат иярләп чыгып чапты,
Бер гөнаһсыз ике башны бәреп ватты.
Утырды да җылы мәет аркасына,
Тәмәкесен тартып алды тыныч кына.
Гел җәзасыз калгач инде, кем курыккан,
Аңа кан-яшь диңгезләре дә тубыктан.
Тик ялгышкан – утырганы мәет түгел,
Шөкер, монысы беркемгә дә гаеп түгел...

## 4

Каян куәт алып узгандыр ул
Урман белән авыл арасын –
Урам буйлап тере мәет килгән,
Кулы белән каплап ярасын.
Берәм-берәм халык җыелышкан,
Йорттан йортка хәбәр таралган.
Бите буйлап мишәр малаеның
Каны аккан ачык ярадан.
Үксеп-үксеп елый икән мескен,
Дер калтырап җылы өйдә дә.

Берәү әйткән: «Йә, тынычлан, улым,
Ни булганын тизрәк сөйлә дә».
Әйткән малай: «Йонлач бүрек тә күн бишмәт...
Аркылыга куйды ул атын...
Балта тотып безгә каршы килде,
Аннан соң мин аңым югалттым...»
Кемдер тешен, кемдер йодрык кыскан,
Аркалардан суык йөгергән.
Күз яшьләрен сөрткән кайберәүләр,
Вакыт җиткән – хөкем өлгергән.
Талап, изеп, асып, кисеп була,
Эшчән халык юаш, түземле.
Ләкин чик бар. Шушы чикне узсаң,
Таптап, изеп узар үзеңне.
«...Җитте, улым, ял ит, аңлашылды,
Болай да бит инде ап-ачык...»
Бәреп кергән авыл агайлары
Әхтәмҗанның имән капкасын.
Мунча кереп ята икән хуҗа,
Чистарына, имеш, юына.
Күсәк тоткан агайларны күргәч,
Наган тотып чыккан кулына.
«Йә, Әхтәмҗан, ташла коралыңны,
Кан акмасын йортың-бакчаңда.
Соңгы сәгать җитте. Котылу юк,
Хәтта инде туптан атсаң да».
«Соңгы көнең җитте. Шәфкать көтмә,
Артык озак түздек болай да.
Күзләренә кара авылыңның,
Урам уртасына чык әйдә!»
Күренә ки, нәфрәт чиктән ашкан,
Өмет тә юк. Булса, бик аздыр.
Атып егасың, ди, берсен йә икесен,
Бар авылны егып булмастыр.
Урам буйлап, капка, койма саен,
Яше-карты чыгып тезелә,

Яланаяк килгән Әхтәмҗанның
Төкерәләр кара йөзенә.
Чиста күлмәк, чиста ыштан кигән,
Күтәрелә ак пар иңеннән.
Әйтерсең лә үз вакытын белеп,
Юынган да актан киенгән.
Бала-чага, хатын-кызлар артта.
Үтенгән, ди, кырда Әхтәм бик:
«Кем сукса да, берәгәйле суксын,
Бер сугуда эшне төгәллик...»
Һәркайдагы кебек, соңгы теләк
Бу якта да төгәл үтәлгән,
Иң ярсыган, иң куәтле агай,
Тәвәккәлләп күсәк күтәргән...
Күмәр вакыт җиткәч, бәхәс купкан:
«Кайда гына казыйк каберен?
Изге зират сыйдыралмас моның
Бу дөньяда кылган җәберен».
«Юл астына салып күмик аны,
Кабердә дә тыныч ятмасын!»
«Юк, җәмәгать, мәет мәет инде,
Мыскыл итмик, Алла сакласын!»

...Юл читендә ялгыз, үксез кабер,
Авыл белән авыл арасы.
Билге булып, гыйбрәт, хәтер булып
Үсә анда миләш агачы.
Кояш кызу, җил аяусыз анда,
Такыр аның якын-тирәсе.
Карт-карчыклар сөйли иде: «Менә
Әхтәмҗанның ачы миләше...»
Габделәхәт калды бер җәзасыз,
Шунсы гына менә бик начар.
Караңгыда калды, караңгыда,
Бу әләкче, куркак юлбасар.
Ләкин һаман бер үк сурәт керә

Төшләренә аның төн саен –
Күсәк тоткан кемдер капка шакый:
«Эш синдәдер монда, мөгаен...»
«Ә бит мөсафирлар синдә кунган...»
Инде тыныч йокы юк аңа.
Ыңгырашып, чинап саташа да,
Тиргә батып, куркып уяна.
Хәтта көндез ишек шакысалар,
Йөгереп төшкән идән астына.
Инде әзер шуннан чыкмаска да,
Исән булсын бары баш кына.
Ничек шулай гомер итмәк кирәк?
Кайчан да булса бу бетәрме?
Эт тормышы дияр идем, ләкин
Яратам шул бик тә этләрне...

5

Фаҗигале бу тарихны
Сөйләгәннәр иде күптән.
Ерак калган шомлы көннәр,
Инде күпме вакыт үткән.
Мәрхүмнәрнең рухы миңа
Нигә тынгы бирми бүген?
Нигә көн дә нидер эзли,
Тыныч түгел һаман күңел?
Сүзләр җыям, сурәт ясыйм,
Салкын эзләр буйлап киләм,
Очраган бер авылдашка
Һаман бер үк сорау бирәм.
Тыныч кына сөйли алар,
Мине белеп бала чактан.
Эшчән, тупас кулларының
Буыннары шешеп каткан.
Уч төпләре дә кытыршы,
Җелекләре суырылган.

Җил ашаган чырайлары
Кояшларда куырылган.
Әйе, бүген әрни күңел –
Күзләремә авыл бага,
Язмыш аның башын ваткан,
Йөзе буйлап каны ага.
Таладылар илен, җирен
Һөнәрченең, игенченең,
Инде җанын алыр өчен,
Кисүчеләр булды телен,
Кылыч селтәп, мылтык терәп,
Кәгазь тотып, вәгазь укып,
Яу тамгасы – козгын кебек,
Кунган саен башын чукып.
Җылы җилләр алдадылар,
Аяк асты боз иде бит.
Иске тунны утка ягу –
Яраларга тоз иде бит.
Бар идек без, бай идек без,
Тик бер генә бездә хурлык –
Телен, динен, илен саткан
Куштаннарга да бай булдык.
Берәгәйле каһарманнар
Шәһит китте берәм-берәм.
Татар башын татар чукый
Җаһил куштаннары белән.
Бурычларны түләүче юк,
Күргәнем юк сораучысын.
Түләп бетерерлек түгел
Күз яшьләрен, тир ачысын.
Авыл һаман билен бөгеп,
Баш күтәрми... Бу нинди эш?
Күзләрендә үпкә-үч юк,
Әйтерсең лә шулай тиеш.
И авылым, моңлы иттең,
Күңелемә шом салдың да,

Гаебем бар кебек хәзер
Череп тузган йорт алдында.
Әнә чыгып килә аннан
Ялгыз карчык, бик бетәшкән,
Куырылган, суырылган,
Әби булган илле яшьтә.
Ике куллап күрешә дә
Күзләремә карый туры,
Әйтерсең лә күзләрендә
Авылымның соңгы нуры.

Эх, дөньясы! Кузгатырмы
Кемдер бу җинаять эшен,
Үз бәясен үзе белми
Узган гомерләре өчен?
Аерылганны аю ашый,
Шаһитлар, сез ник дәшмисез?
Гарасатта читкә качып,
Нигә бүген берләшмисез?
Тыныч түгел, әрни күңел,
Нидер эзли, нидер көтә.
Җинаятьче табылмаган,
Тикшерену дәвам итә...

*1992*

# Бакча

Түбән очта, зират янында ук
Бар иде бит бакча кисәге.
Бүгенге шул ятим җиргә карап,
Ямьле чагын күрәм кичәге.
Туган якның гүзәл почмагында,
Җирдә аунап безнең шикелле,
Үсте анда сусыл кыярлар да
Бөртек-бөртек яшел сипкелле.
Ә әниләр анда кыяр җыйды,
Бергә-бергә «әбәт» ясадык –
Урталайга ярып һәм тоз сибеп,
Ипи белән кыяр ашадык.
Зираттагы авыл мәрхүмнәре,
Чәчәк булып безгә бактылар,
Шыгырдатып безнең сусыл кыяр
Ашаганны тыңлап яттылар.
Хәтердә тик чаткы гына калган,
Үткән көннәр – сүнгән учаклар.
Ничек тәмле иде ул кыярлар!
Нинди ямьле иде ул чаклар!

Бишекләрдән күтәрелде башлар,
Җиргә очты кысыр имезлек.
Әниләрнең итәгеннән төшеп,
Сукмакларга беркөн сибелдек.
Сукмакларның сәер үзлеге бар –
Түбән очка һәрчак илтәләр.
Күз алдында сусыл кыяр ята,

Бик тәбәнәк кебек киртәләр.
Каравылчы Вәли абзый әнә,
Башын кыңгыр салып, җыр көйләп,
Үз өенә таба менеп бара,
Кайчан төшәр кире, кем белә?..
Кемдер инде койма аша кергән,
Кыяр өзә, ялт-йолт каранып,
Изүенә сала һәм исәпли
Вәли абзый үткән араны.
Дер калтырап кыяр умырганда,
Бар тирә-як шомлы тоела.
Каешсыз, буш чалбар бөрмәсеннән,
Җыелганы кире коела.

Вәли абзый төшеп килә инде,
Кай арада ашап өлгерә!
Бакчадагы каракларны күреп,
Артларыннан куа, йөгерә.
Ул яшь түгел инде, тыны бетеп,
Куа соңгы барлык көченә.
Ә малайлар черек койма аша
Сикерәләр зират эченә.
Ләкин Вәли абзый – әллә инде
Мәрхүмнәрдән бераз шүрләде –
Юк сәбәптән зират туфрагына
Аяк басуны хуп күрмәде.
Безгә зират ерак төшенчә бит,
Ә ул үләр көнен уйлады,
Хәрәм кыярларның үз бәясен
Зираттан да олы куймады.
Җыеп алды җирдән кыярларны,
Йөгергәндә бездән коелган.
Җыр көйләде тагын. Юкка гына
Безгә усал булып тоелган.

Усал булган ул да, үткән чакта

Европаның утлы юлларын,
Чабар өчен вәхши фәлсәфәнең
Илне буган канлы кулларын.
Бөреләнгән кыярларны ташлап,
Яу кырына алар киткәннәр.
Тыныч, тәмле, йомшак «кыяр» сүзен
Сугыш тәртәсенә җиккәннәр.
«Кыяр кирәк! Кыяр кирәк!» – дигән
Кече сержант мәхшәр көнендә.
Хәтта тормыш кыл өстендә чакта,
Менә шундый сәер элемтә.
«Кыяр кирәк!..» Димәк, озакламый
Минометның уты өзелә.
«Кыяр кирәк!..» Димәк, мина кирәк,
Ыргытырга дошман өстенә.
Миналар юк, алар чолганышта,
Инде боҗра якын һәм тыгыз.
Соңгы хәбәр: «Тозлы кыяр кирәк!»
Димәк: «Безнең өскә атыгыз!»
Шулай була, иле өчен солдат
Икеләнми сала гомерен,
Шул кабергә әгәр ала алса
Үзе белән дошман өерен.
Хакыйкатькә тарих аяк чалса,
Хакын җуя фани әйберләр.
Европада яисә Азиядә
Аз булдымы андый каберләр!
Үз гомерен чүпкә санап түгел,
Ил гомерен куеп югары,
Каберләрдән күтәрелеп, безнең
Күзгә карый Ватан уллары.
Бурыч таләп итмиләр һич алар,
Зарланмыйлар сару кайнатып.
Тик шулай да, әйе, тик шулай да
Рәнҗиләрдер кебек кайвакыт.
Бер ялвару бары бу күзләрдә,

Булмаса да һичбер үкенеч:
«Онытмагыз безне!» – бу алардан
Безгә соңгы, өнсез үтенеч.

Беркайда да юктыр, ахры, җирдә
Чирәм баскан зират юллары.
Каберләрне барлап, җыештыра
Исәннәрнең җылы куллары.
Ә авылда үлем-төшем булса,
Кабер казу төшә ир-атка.
Вәли абзый башка ирләр белән
Төшми калмый иде зиратка.
Күз алдымда һаман ындыр юлы:
Көрәк тоткан олы абзыйлар
Салмак атлап түбән очка төшә,
Димәк, бүген кабер казыйлар...
Бу көннәрдә алар күп сөйләшми,
Тынлык саклый таныш каберләр,
Чүп күренә кайбер вак ызгышлар,
Онытыла үпкә-җәберләр.
Вәли абзый башын кыңгыр салган,
Кыяфәте берни сөйләми.
Атлавы да элеккечә кебек,
Җырын гына ләкин көйләми.

Хәтергә дә Вакыт аяк чала,
Онытыла кайчак каберләр.
Хакыйкатьнең хакы истән чыкса,
Баш күтәрә фани әйберләр.
Тормыш өчен тормыш биргәннәр бар,
Яннарыннан үтик яланбаш.
Тапталмасын мәрхүмнәрнең рухы,
Уяулыгың җуйма, замандаш!
Тук гамьсезлек җанны алдамасын,
Күңел күзен ябып, йоклатып.
Хәтеренә кеше үзе хуҗа,
Ә кешегә хуҗа тик Вакыт.

Буыннардан буыннарга үтеп,
Йөрәк янсын, күңел моңлансын.
Тынгысыз җан җирдә һәр бөҗәкнең,
Һәр үләннең зарын тыңласын.

...Вәли абзый озак яшәмәде,
Әҗәл килде – өзде сулышын.
Әллә сәбәп ачлык елларымы?
Әллә Бөек Ватан сугышы.
Җыелгандыр, ахры, барысы да,
Һәр ел саен йөрәк кысылган –
Тук еллар да хәтта төзәтмәслек
Тирән яра аңа сызылган.
Бушап калды авыр еллар йөген
Тартып килгән, ябык беләге.
Туктамады тормыш, тик шулай да
Какшады күк авыл терәге.
Көрәк тотып, ындыр юлы буйлап
Төшеп бара әнә абзыйлар.
Вәли абзый гына юк анда тик,
Димәк, аңа кабер казыйлар...
Ул зиратка керде бөтенләйгә,
Язын чәчәк булып үрелә.
Койма аша аңа аннан башка
Ятим калган бакча күренә.

Авыл инде, шөкер, ярлы түгел,
Өйләр иркен безнең, тамак тук.
Агрономнар, тракторчылар бар,
Кыяр үстерүче генә юк.
Минем хыял – агач сука түгел,
Тракторга без дә куандык.
Калды кебек тимер чолганышта
Җир-су белән рухи туганлык.
Коллыгында әрсез чүп үләннең
Бәрәкәтле туфрак тилмерә.
Койма череп ауган, ә малайлар

Хәзер күбрәк кәнфит кимерә.
Авыллар да картаялар икән...
Яңа тормыш кызу һәм әрсез.
Югалсалар әгәр ул кыярлар,
Югалырбыз без дә хәбәрсез.
Кыяр кирәк! Ниндидер бер моңлы
Күңел кылы, димәк, өзелә.
Кыяр кирәк! Туры карар өчен,
Авыл мәрхүмнәре йөзенә.

Мәрхүмнәрне, зират-каберләрне
Бераз артык, ахры, борчыдым.
Бөтерелеп китсә, туктыймы соң
Хәтер-моңнар, уйлар орчыгы?
Сузыла җеп ерак еллар аша,
Бөтерелә орчык каләмем
Һәм китерә миңа балачакның
Сагынычлы, моңлы сәламен.
Сизми калдык замананың безне
Тормыш тәртәсенә җиккәнен,
Урлап качкан авыл кыярларын
Кайтарырга вакыт җиткәнен.
Һич булмаса, калган орлыкларны
Вакыт инде җиргә салырга,
Карт авылның Олы Тарих йөген
Үзебезнең кулга алырга.
Вакыт инде нәсел-тарихыңны
Балаларың җыеп сөйләргә,
Үз телеңдә үз җырыңны көйләп,
Үз бакчаңа сулар сибәргә.

...Җырлар өздем хәтер бакчасында,
Камиллеккә, моңга ашкынып,
Һәм йөгерәм кызу заман буйлап –
Арттан куа вакыт ташкыны.
Вакыт куа. Вакыт аяусыз ул.
Мин йөгерәм алга... зиратка.

Мин йөгерәм. Өзгән хатирәләр
Бәреләләр талгын йөрәккә.
Бу замана тоташ йөгерештә,
Күпме байлык җиргә коела.
Хәтерсезләр рухи хәлсезлектән
Егылырлар кебек тоела.
Тарих өчен афәт түгелдер бу,
Ә бары тик Кояш баешы.
Ачык булсын күңел изүләре,
Кысып бәйлик хәтер каешын.
Әйләнүдән Җир туктамас әле,
Иртән Кояш тагын кабыныр.
Без югалткан яшел кыярларны
Җыючылар әле табылыр.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Кирәк булса, уттай балкырлык
Һәм алардан рухи мирас безгә –
Тырыш хезмәт, тыйнак батырлык.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Күпне биреп, азны алучы.
Илнең тере тарих сәхифәсе,
Татар авылының намусы.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Алар бизи тарих сәхнәсен.
Алар белә тормыш хакыйкатен,
Алар аңлый яшәү мәгънәсен.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Яу кырында башын салганнар.
Сугышсыз бу якты көннәр хакын
Белә бары исән калганнар.
Һәр авылда Вәли абзыйлар бар,
Китеп бара алар, үкенеч.
«Онытмагыз безне...» – бу алардан
Безгә соңгы, өнсез үтенеч.

*1986*

## Йорт иясе

### 1

Бисмилламны әйтеп башлыйм әле,
Сөйләр сүзем – гыйбрәт маҗара.
Илаһи дәрт һәм таяныч кирәк
Чамадан тыш сурәт ясарга.
Үз күзләрем белән өрәк күрдем,
Ялгыз калган идем бу төндә, –
Боргаланып, күзләремне ачкач,
Айнып киттем кинәт бөтенләй.
Уңга-сулга сыгыла да төшә
Кара шәүлә ап-ак ишектә.
Котсыз калып җиктем бар көчемне,
Һушым җыяр өчен ничек тә.
Җил-давыллы җәйге кара бер төн,
Күкне каплап, болыт агыла.
Ни булды бу диеп, тәрәзәдә
Күренеп китте тонык ай гына.
Күпне күрдем. Әҗәлнең дә инде
Килеп тотканы бар якадан
Һәм аптырап кире киткәне бар,
Килер өчен тагын, яңадан.
Җен-пәридән курку күптән беткән инде,
Әҗәлне дә алмыйм исәпкә.
Ләкин бүген һушсыз кала яздым,
Кара шәүлә күреп кисәктән.
Ул чайкала, ә мин һушым җыям,

Фикер йөртәм әкрен, кымшанмыйм.
Күптән беләм: хәвеф-мазар килсә,
Куркудан да начар дошман юк.
Тыныч зиһен белән, кабаланмый,
Мизгел буйлап уйлар ашыга
Һәм фикергә килә: куркыныч юк,
Йорт иясе тора каршыда.
Мин таныдым аны, иллә дә хак,
Таныдым да җиңел суладым,
Суладым да, моңсу хәтер белән
Туган йорт турында уйладым.
Искә төште күргән-белгәннәрем,
Маҗаралар, дөнья серләре,
Иясез йорт идәненә төшеп,
Аунап яткан сәгать герләре.
Моңсу уйлар... Ерак истәлекләр...
Йорт иясе һаман чайкалды,
Һәм таралды болыт, күк йөзендә,
Китек тәңкә булып, ай калды.
Бисмилламны әйтеп башлыйм әле,
Игълан өчен түгел базарда,
Савап булсын әби өйрәткән сүз,
Изге илһам булсын язарга.

2

Сиксән яшьлек Хәербанат карчык ялгыз,
Җиңеләйгән бу бераз дип уйламагыз.
Сөйләшә ул кем беләндер, үзе генә,
Кеме белән сөйләшкәнен үзе белә.
Кайчак кемне тыңлагандай тынып кала,
Аннан тагын моңын-зарын сөйләп ала.
«Югарочтан тракторчы Габделбарый
Сирәк айный, тик шулай да эшкә ярый.
Бетәмени йомыш-җитешләр вак-төяк,
Бүген менә утын алып кайтты төяп.

Җиде йөз ат көчле тимер тарантаста
Җиде түмгәк утын тәгәрәшеп ята.
Актарылды капка янындагы чирәм,
Җитмәсә, бер ярты сорый теге бирән.
Әйтмәс идем битен ертып, ләкин көн дә
Бу ыштыр бит һаман хайван өммәтендә.
Хатыны да китте күтәреп баласын,
Чыдар әмәлең юк икән, ни кала соң?
Ә бу эчә, кәсеп булгачтын эчәрлек,
Курыкмый да Алла каһәре төшәр дип.
Җитмәсә, шул кибетен дә яптырдылар,
Хәмер белән көрәшүче «акыллылар».
Денсез сәүдәгәрләр хәзер симерәләр,
Күз яшьләре сатып, дөнья җимерәләр.
Күпме кыен ашап монда михнәт чиктем,
Сугыш чыккач иген иктем, урман кистем.
Үз утыным ничек кисим, ничек ярыйм?
Кем янына хәзер башым иеп барыйм?
Оныттылар тук бәндәләр иманнарын,
Бер рәхмәтнең мең бәладән коткарганын.
Торам дисәң, тыныч тормыш күреп булмый,
Үләм дисәң, тиктомалга үлеп булмый...»
Сиксән яшьлек Хәербанат карчык ялгыз
Җиңеләйгән бу бераз дип уйламагыз.
Кеме белән сөйләшкәнен үзе белә,
Берьялгызы бу дөньяда, үзе генә.
Китеп бара «ахырзаман тарантасы»,
Урамдагы чирәмнәрне изеп-басып.
Авыраеп ярты айлык пенсиягә,
Үргә көчкә менә, гүя таш төягән...

## 3

Сәрхуш Габделбарый беркөн тракторда
Аммиаклы су сибәргә кырга чыккан.
Башы чатнап, кәефе юк чагы икән,

Шуңа күрә Габделбарый бик ашыккан.
Тамак өчен без хәзер бит барыбыз да
Ашламага әсир төштек инде күптән.
Ләкин сәрхуш Габделбарый бик ашыккан,
Аммиаклы суны саф инешкә түккән.
Мәшәкатьле вакыт булган икән кырда,
Кем тикшереп-белеп торган эш барышын?
Исәпләнгән – ашламаны Барый, имеш,
Кырга сипкән, калдырмыйча бер тамчысын.
Буй-буй яшел, кызыл канатлы балыклар
Агуланып калкып чыккан берәм-берәм.
Кайберләре судан ярга сикергәннәр,
Нәрсәгәдер соңгы сәер өмет белән.
Тик ул балыкларны Барый күрмәгән дә,
Борчылмаган һич тә ни кылганын уйлап.
Җигүдәге җиде йөз ат көче белән
Төшемле эш эзләп киткән авыл буйлап.

...Инде кичке эңгер-меңгер төшкән булган,
Инде тынган савыт-саба, чүмеч-чиләк,
Инде тәрәзәләр саен ут кабынган,
Инде Барый эчкән булган күпме кирәк.
Түбән очтан Хәниф белән тал төбендә
Очрашкан, ди, югарочның Хәмдиясе.
Күргәннәр, ди, су буйлатып килә икән
Ап-ак яулык япкан бөкре Йорт иясе.
Иелә дә нидер җыя, ди, тукталып,
Сөйләшә, ди, үзе белән үзе һаман.
Кара төндә шомлы шәүлә шаукымыннан
Аптырашта калганнар, ди, яшьләр тәмам.
Тал янына килә икән, нидер көйләп,
Әллә елап, әллә җырлап адым саен.
Ишетелгән аңлашылмый торган сүзләр:
«Ләхәүлә вә куатә... ай, балакаем...»
Баскан җирен күрмәсә дә караңгыда,
Җиңел атлый икән үзе өрәк кебек.

Әйтерсең ул көн дә инеш буйлап йөргән,
Туып моннан берничә йөз еллар элек.
Балкый икән су буенда ак яулыгы,
Әйтерсең ул ак кәфенен ябып чыккан.
Кыяфәте белән үзе охшаган, ди,
Авылдагы бик борынгы бер карчыкка.
Бу шомлыкны күрсә, һәркем шүрләр иде
Якынлашкан чакта шәүлә тал төбенә,
Заман кызы комсомолка Хәмдия дә:
«Әбәү, җаным!..» – дип елышкан егетенә.
Ә егете нишләсен соң, катып калган,
Чытырдатып ябышуга Хәмдиясе,
Ниһаять, бер киерелеп тын алган да
Дер калтырап пышылдаган: «Йорт иясе...»
Яшьләр янында туктаган, таныгандай,
Карап торган авыр сулап, сагыш белән,
Күз яшьләрен сөрткән, алъяпкычын селкеп,
Сасы балыклар коелган итәгеннән.
Бер сүз әйтми киткән өрәк. Тал төбендә
Үле балык кына калган, ди, өелеп.
Буш тыкрык буйлап яшьләр йөгергәннәр,
Исән-имин калганнарына сөенеп.
Бер сүз әйтми кулын селтәп киткән өрәк,
Бер сүз әйтми киткән әллә өмет өзеп.
...Бара торгач, буш мичкәгә терәлгәндер
Сасып яткан үле балыкларның эзе.

## 4

Көлешә яшьләр урамда –
Бар икән бит Йорт иясе!
Хәниф сөйли, аның сүзен
Җөпләп тора Хәмдиясе.
Алар сөйли, кемдер көлә:
«Кем ышансын уйдырмага!
Әбиеңә сәлам әйт, – ди, –

Килсен, имеш, утырмага!»
Иң кимендә сигез сыйныф,
Кем дип белдегез аларны!
«Әйдә, төшеп карыйк, – диләр, –
Котыгызны алган ярны».
Елгыр, тәвәккәл егетләр
Утырдылар «матайларга»,
Акыртып бер газ бирделәр,
Юл тотып шик тулы ярга.
Төнге тын һаваны ярып,
Атылдылар берәм-берәм.
Кемнеңдер әтәче куркып,
Вакыт җитми салды сөрән.
Тынып калдылар егетләр
Кисәк бу хәвефле төндә –
«Матай» утлары кисеште
Үле балык өемендә...

Капка төбендә аптырап,
Утыралар егет-кызлар.
Җемелдиләр, шомга салып,
Күктәге ерак йолдызлар.
Гәп сата яшьләр тын гына,
Сөйләп күргән-белгәннәрен.
Искә төшә серле сүзләр,
Догалары әбиләрнең.
«Күренә, ди, Йорт иясе,
Песи булып, кеше булып.
Яши икән йә чормада
Яки мич башында кунып».
«Сүгенергә дип, бер агай
Ачкан икән, ди, авызын –
Тибеп төшергән, ди, «теге»
Мич башыннан чәй савытын».
«Кисеп уйганда бер малай
Атын миләш агачына,

Тикмәгә моржадан кирпеч
Төшә язган, ди, башына».
«Яңа йортка күчә, ди, ул
Үз хуҗасы белән бергә.
Ияләшкән бәндәләрдән
Китми, ди, гомер-гомергә».
«Ни теләсә, шундый аваз
Чыгара, ди, кайберләре.
Күчергәләп йөрткәли, ди,
Өйдә кайчак әйберләрне».
«Мәчет манарасын кискән
Хәй абзый яшь, юләр баштан.
Йорт иясен төштә күреп,
Бу арада бик саташкан.
Килгән, ди, Банат түтигә,
Җыеп юк-бар соңгы көчен,
Сораган намаз укырга
Иске кыйбла юнәлешен».
«Аның белән дуслык булса,
Тими, ди, бернинди чир дә.
Тормыш бөтенләй бетә, ди,
Йорт иясе киткән җирдә».
«Дин өчен дә, фән өчен дә,
Ачык түгел әле, ди, ул.
Аракы күп эчкәннәргә,
Кайчак күренгәли, ди, ул.
Ярым-йорты шәүлә-сурәт
Әлҗе-мөлҗе килә икән,
Тиле-миле азгын сәрхуш
Бу чирдән тиз үлә икән...»
...Барысы бар бу сүзләрдә,
Дин дә, җен дә, уйдырма да.
Тып-тын гына сөйләшәләр
Яшьләр төнге утырмада.

## 5

Инде тәрәзәләр саен утлар сүнгән,
Инде авыл татлы төшләр күргән күптән.
Инде яшьләр таралырга җыенганнар,
Инде төн уртасы чаң уйнатып үткән.
Сөйләшәсе сүзләр бетеп, нидер көтеп,
Тыныч кына шулай утырган вакытта,
Бөтен тирә-якны кинәт сискәндереп,
Чәчрәп тәрәзә ватылган күрше йортта.
Тәрәзәдән очып чыккан Габделбарый,
Яшел-зәңгәр, ямьсез авазлар чыгарып,
Төнге тынлык, шомлы сүзләрдән сагайган
Егетләрнең сизгер колакларын ярып.
Кара төндә үтерәләр кемне диеп,
Якын-тирәнең уянган карты-яше.
Габделбарый урам буйлап йөгерә, ди,
Кычкыра, ди: «Йорт иясе! Йорт иясе!»
Башы-кулы канга баткан, ди, суелып
(Шул буладыр инде сәрхушларның чире),
Чабып кергән ачык капкалы бер йортка
Һәм шулай ук чабып чыккан аннан кире.
Җылы йокы түшәгеннән торып, өйдән,
Хәвефләнеп, инде һәркем чыгып җиткән.
Авыл буйлап бәргәләнеп йөри торгач,
Хәлдән тайган Габделбарый ахыр чиктә.
Бәласеннән башаяк, дип, тыгыз бәйләп
Кертеп салганнар Барыйны үз өенә.
Тыпырчынган әле озак һәм саташкан,
Аяк-кулы бәйле-тышаулы көе дә.
Банат карчык шунда колһуалла укып,
Өшкереп тә караган, ди, ул мескенне,
Барый тынып, тонык күзләрен ачкан да
Сискәндергән, тагын кычкырып, һәркемне.
Иртән сырхауга куркулык litt коя өчен,
Куар өчен бимазалы шик-шомнарын,

Банат карчык иртүк торып, намаз укып,
Алып килгән Коръәнен һәм им-томнарын.
Тик тиешле табибларга тапшырырга,
Киселгәнгә кулы-башы, күзе-кашы,
Алып киткән аны арбасына салып,
Үзенең үк «ахырзаман тарантасы».
Инешне дә кире борып булмагандай,
Савыгу юк, диләр, инде мондый чирдән.
Ләкин Барый исән чакта, үз аңында,
Күргәннәрен бераз гына сөйләп биргән.
Җилкәсенә кулын салган аның кемдер,
Гырлап йоклап яткан чакта салган баштан.
Әйле-шәйле Барый башта унлык сузган аңа,
Бер «кызыл»га җибәрмәкче булган башта.
Ә биләмче кымшанмыйча тик тора, ди,
Гүя кергән йортка кемнеңдер Әҗәле...
Бу караштан өнсез калып шашкан Барый
Ватып чыккан өендәге тәрәзәне.
Ә калганын сез беләсез... Ләкин Барый
Өлгермәгән сөйләп барлык күргәннәрен...
Елар кеше табылмаган бу мәхлукка,
Сөйләделәр ашык-пошык күмгәннәрен.

## 6

Банат карчык яткан үлем түшәгенә,
Күз карашын текәп агач түшәменә.
Үлем-җитем хәстәренең үз җае бар –
Бәхилләшә җыелышып карт-карчыклар.
Хушлашалар, күпме гомер кичеп бергә,
Өметләнеп ахирәттә күрешергә.
Ләкин карчык үлем түшәгендә ялгыз,
«Ялгыз» сүзе ялгыш диеп уйламагыз.
Алла колы ни язганын үзе белә,
Соңгы юл каршында һәркем – үзе генә.
Юк хәрәкәт, юк мәшәкать – тик ялгызлык,

Котылгысыз, җан өшеткеч кара тынлык...
Инде күптән алып куеп, үзе теккән
Саф акбүздән кәфенлеген үлемтеккә.
Карап чыгып тыныч кына бар әйберен,
Күтәрергә кушкан кинәт сәгать герен.
Үз көенә яши адәм, үзе генә.
Көе сынса, үз вакытын үзе белә.
Өзелеп җан биргән шулай кичке якта...
Сәгать калган мизгел агымында сакта.
Җирләгәннәр иртәгесен мәрхүмәне,
Тик авылда җәйге мәшәкать күп әле.
Үлгән белән үлеп булмый, дигән кебек,
Исәннәрдә дөнья гамедер иң элек.
Калган утынны алырга, өйләдән соң
Китергәннәр үле йортка «җен арбасын».
Абзыкайлар утын төягән вакытта,
Кинәт гөрселдәгән нәрсәдер буш йортта,
Һәм ачылып киткән черек тәрәзәдән
Гөл чүлмәге җиргә төшеп тәгәрәгән.
Артыннан ук чабып чыккан ап-ак мәче –
Мәрхүмәнең соңгы бердәнбер иптәше.
Дөнья күргән авыл абзыйларын, беләм,
Куркытырлык түгел юк-бар өрәк белән.
Ышанмыйча сихер-тылсым, җен көченә,
Ипләп кенә күз салганнар йорт эченә –
Идәнгә төшкән ычкынып сәгать гере,
Тик шул гына икән сәер аваз сере.
Ә күкесе авыз ачып катып калган,
Соңгы сәлам булып җиргә сау еллардан.
Кычкыра ул, гүя кемдер буа аны,
Тик тавышы чыкмый, ахры, чыга җаны.
Кычкыра ул, гүя ничә ел буена
Зарлы сүзен әйталмыйча җир буыла.
Гүя көтә безне бары бер киләчәк –
Ватык чүлмәк уртасында сынык чәчәк...

## 7

Шактый гына еллар узгач,
Онытылган сәер хәлләр,
Сер мәетләр белән киткән,
Ә зираттан юк бер хәбәр.
Еллар үтә, йортлар бушый,
Үлә-китә карты-яше.
Шуннан бирле күренмәгән
Беркемгә дә Йорт иясе.
Түбәдәге морҗаларны
Кочып елап китеп барган
Каезланган, каешланган,
Чирәм беткән урамнардан.
Аккан гөрләвекләр булып
Түбәночка югарочтан,
Карлар булып яуган кышын,
Сары яфрак булып очкан.
Юк, әле ул тиз югалмас,
Бераз гына түзәр әле,
Орлык булып җиргә төшәр,
Агач булып үсәр әле.
Җаны барның күзләреннән
Тамчы булып тамар әле,
Тәлгәш-тәлгәш миләш булып,
Тәрәзәләр кагар әле.
Болыт булып кузгалыр да
Яңгыр булып килер әле,
Яшен булып күренер дә
Күкрәп сәлам бирер әле.
Без йокларбыз хәлдән таеп,
Тамак өчен фәхеш кылып,
Җирне талый-талый баеп,
Аракыга чират торып.
Нәрсә инеш? Нәрсә Барый?
Кем ишетә хәлсез зарны? –

Агулыйлар мизгел саен
Олы-олы елгаларны...
Шунсы гаҗәп: аек алар,
Зәгыйфь түгел, фәкыйрь түгел,
Йорт иясен ишетерлек
Алар җирдә шагыйрь түгел.
Яман төш күреп, саташып,
Уяныраыз әле без дә,
Җылынырга дип үзебез
Ут төрткән үз өебездә.
Чәчрәп чыгар безнең җаннар
Күккә ашкан таш тóрактан.
Таш урамда мәет калыр,
Туган җирен кочып яткан...

## 8

Ә мин күргән шәүлә – тик күләгә
Урамдагы яшел агачтан.
Убыр түгел, җен-пәри дә түгел,
Газраил дә түгел адашкан.
Җилле төндә лампа яктысында
Чайкала ул ап-ак ишектә,
Кайгысы бар кебек сыгыла да
Тураймакчы була ничек тә.
Нигә исә бу җил бертуктаусыз?
Ул мәңгелек түгел! Ул сына!
Ул бит шул ук, шул ук Йорт иясе!
Тик шул гына бары... Шул гына...
Тик шул гына иде әйтәсе сүз:
Безгә шундый тормыш эләгә –
Ишегенә һәркемнең дә инде
Килеп баскан кара күләгә.
Убыр түгел, җен-пәри дә түгел,
Фәрештә дә түгел адашкан –
Тик күләгә әле кичә генә

Шаулап торган яшел агачтан.
Җил-давыллы, якты заманада
Сыгыла ул ап-ак ишектә,
Буылып һәм соңгы көчен җыеп,
Тураймакчы була ничек тә.
Нигә исә бу җил бертуктаусыз?
Ул мәңгелек түгел! Ул сына!
Тик шул гына иде әйтәсе сүз...
Тик шул гына бары... Шул гына...

*1991*

## Ут

Тынгысыз ут, ник бәйлисең
Минем талгын күз карашым?
Ни сөйлисең, якынайтып
Кеше белән ут арасын?
Мең үзгәреш, мең яңалык
Сөйли безгә кызу телең.
Әллә кысылган вакытмы,
Ут гомере, һәр мизгелең?
Кеше белән ут арасы...
Без бит Кояш тамчысыннан!
Илаһи Җир пәйда булган
Галәм әвәләгән сыннан.
Ясалган чын, Илаһи сын,
Күкрәгендә уты калган.
Бикләнгән ут үз иркенә
Вулкан булып юллар салган.
Уттан тормыш яралганда,
Җир-Ананың сулышы бу.
Үле караңгылык белән
Якты тормыш сугышы бу.
Ут гомере булып балкый
Мең янарыш Җир өстендә.
Яналар һаман учаклар
Көн дә, төн дә. Көн дә, төн дә.
Һәм табигать үлем хәлен,
Торгынлыкны утка яга.
Ачыгыз! Утлар эченнән

Җирдә тормыш ишек кага!
Хәер, сүз бар: Җирдә тормыш
Чәчелгәндер, бәлки, читтән...
Юкса бу кадәр бизәкне
Аңсыз дөнья ничек чиккән?
Булуы бар. Галәмнәр киң,
Ачылмаган серләр чиксез.
Ләкин миңа кешелекнең
Уттан туганлыгы шиксез.
Ә табигать җансыз түгел,
Һәрбер учак – аның күзе.
Аның җаны һәр тарафта,
Шуңа күренми дә үзе.
Аның аңы һәр кешедә,
Кеше – иң матур бизәге,
Уттан алып, чорлар буе
Ясаган акыл кисәге.
Кисәге генә бары тик,
Бар табигать иң зур акыл
Һәм ул гына яхшы белә
Кеше акылының хакын.

Хәтта әле мәҗүсилек тә булмаган
Ерак чорга еллар, уйлар аша багам.
Ярым маймыл, ярым кеше, тирләп-пешеп,
Ауга йөри, агачлардан җиргә төшеп.
Җәнлек куа, балык тота, кош та аулый,
Җиләк-җимеш, үлән-тамырлар да калмый.
Ялт-йолт итеп кайчак аның башын сарып,
Килгәлиләр гаҗәеп уй чаткылары.
Акыл әле шыта гына һич тәртипсез,
Уй мәгънәсез, эшләр ямьсез, куллар ипсез.
Күңел кыргый, төннәр кара, куыш салкын,
Нидер тота торгынлыкта маймыл халкын.
Менә җәйнең бер төнендә давыл купты,

Корып кипкән тал-тирәкне яшен сукты.
Очкын чәчеп төн буена янды тирәк,
Куыштагы кабиләнең уен биләп.
Бу җылыга алар чыгып сыендылар,
Чаткы-чаткы уйлар утка җыелдылар.
Куркаклыгын шунда җиңде кыргый күңел,
Утка килгән җан иясе – җәнлек түгел.
Учак уты аңа илһам бүләк итте,
Очкын уйлар ут янында дөрләп китте.
Кешегә ут икеләтә туган булды –
Башта тәне, аннан җаны уттан туды.
Меңәр еллар – кешелекнең үткән юлы,
Юл башында учак яна маяк булып.

Еллар буйлап тарих салмак тартты
Чорлар сәгатенең серләрен.
Сиземләде кебек инде кеше
Сихри утның гади серләрен.
Ут ул саксыз, кыргый җәнлек кебек,
Холкы кызу, көче чамасыз.
Азык булса яна, ә булмаса,
Җиргә ятып үлә чарасыз.
Мәңге сүнмәс кебек күренсә дә,
Олы утлар сүнә барыбер.
Бар дөньяга нәни очкын да
Кайчак афәт булып сарылыр.
Әле вакыт шашып чапмаган чак,
Табигатьнең әле үз яме.
Кояшка һәм утка карап, кеше
Чамалады вакыт үлчәмен.
Ут табулар әле мөмкин түгел,
Ут сакчысы – тормыш сакчысы.
Ә бервакыт... күрми калды кеше,
Сүнде ялгыш учак яктысы.
Ут яктысы – тормыш ышанычы,

Ут югалткан – башын югалткан.
Куылды ул читкә, ялгызлыкка,
Куыштагы салкын тораклан.
«Йә ут табып кайтсын кабиләгә,
Йә үлсен ул, ялгыз, урманда.
Иң зур гаеп – утны саклый алмау,
Уйлый белгән башың булганда».
Ут табуга өмет юк диярлек,
Тормышлар да шулай сүнәрме?
Бар кабилә, салкын кышка кергәч,
Җылы тапмый туңып үләрме?
Утка мәңге гашыйк хәзер кеше,
Алга бора тормыш сәхнәсен,
Ут җылысын тоеп, утсыз калгач,
Күрми башлый яшәү мәгънәсен.
Маймыл чыккан тарих күперләре
Вакыт чыккан чакта ватылды.
Элеккечә утсыз яшим дисәң,
Ватып буламы соң акылны?
Артка юл юк. Тормыш алга бара.
Йә ут таба кеше, йә үлә.
Йә акылы балкып юл күрсәтә,
Йә югала туган кабилә.
Башка якта, башка кабиләләр,
Ут табарлар әле барыбер
Һәм кешелек рухи торгынлыктан,
Үз акылы белән арыныр.
Артка юл юк. Ут булырга тиеш.
Тормыш белән ул нык бәйләнгән
Һәм гасырлар буйлап, ут тормышка,
Тормыш утка һаман әйләнгән.
Шул чакта ут акыл учагының
Кисәүләрен тизрәк көйрәтте.
Үзеннән соң килгән варисларын
Кайгыга да үзе өйрәтте.

Ут хәлсез дә, рәхимсез дә була,
Ут тарихы зарны күп белә,
Көн дә сабак бирә кешеләргә –
Акыллы бул, сак бул ут белән!

Менә атлый безнең кеше
Урманнар буйлап,
Яңа укмаша башлаган
Уйларын уйлап.
Мәш киләләр кош-корт, бөҗәк,
Һәр тараф тулы.
Бар тик җәнлек сукмаклары,
Юк адәм юлы.
Тәлгәшләп кыргый җимешләр
Авызга тама.
Чишмәдәме, күлдәме су –
Сафлык бер чама.
Җәннәт кебек борынгы җир,
Бар тереклек тук.
Кеше – кеше булсын өчен,
Тик ут кына юк.
Атлый кеше. Ничә көннәр
Бер ут башында.
Менеп баса биек кенә
Кыя ташына.
Менеп баса да ялварып
Карый күкләргә –
Эзли куәт иянәрен,
Җиргә ут бәргән:
«Кайда син, дөнья хуҗасы?
Ут бир юлчыга». –
Шулдыр иң беренче тапкыр
Укылган дога.
Ә күктә кара болытлар
Куерып килә.

Ялт-йолт итәләр яшеннәр,
Күк күкри кинәт.
Сихри көчләр юк, әлбәттә,
Очраклы яңгыр.
Тик кеше хәзер Аллага
Мәңге ышаныр.
Нидер йөгереп эзли ул,
Бер күсәк таба
Һәм суза аны болытка –
«Аллага» таба.
Кул тиярлек якын болыт,
Кайный, агыла.
Чытырдап күсәк очына
Яшен кагыла.
Аллаларга сузылган кул
Кирәген алды.
Теләнчене яшен җиргә
Бөтереп салды.
Сизденме утлар дәһшәтен?!
Шәфкать юк монда!
Җир дә, кеше дә чүп кенә
Зур ут алдында.
Һәрбер утка кулың сузма!
Була төрле ут.
Җылысы бар, кылычы бар,
Биге, чиге юк.
Утның да үз дөньясы бар,
Үз тынычлыгы.
Борчысаң – көл итеп ташлар,
Бигеннән чыгып.
Уйла, эзлә – тик теләнеп
Сузма кулыңны,
Күкләрдән шәфкать эзләмә,
Тап үз юлыңны.
Сукыр фәкыйрь булсаң, утка

Килмә дә якын,
Белмәсәң әгәр үзең дә
Акылың хакын.
...Билгесез, серле утларга
Кулын сузганда,
Шикләнер кеше, сизенер –
Куркыныч алда!
Куркыныч алда! Сизенер,
Тик чикне узар.
Һәм, борынгы кеше кебек,
Кулларын сузар.

Еллар үтә, тормыш кайный, акыл үсә.
Яңа җирләр кеше кул астына күчә.
Шул чорларга караш ташлыйк еллар аша:
Ничек итеп утка явызлык тоташа.
Бер утрауда яши менә өч кабилә,
Һәр төркемгә тиешенчә мәйдан билән.
Бу утрауның бар мәйданы урман иде,
Урманына кош-корт, җәнлек тулган иде.
Яшәү өчен шалашлар бар, куышлар бар,
Җәнлекләрдән калган мирас – сугышлар бар.
Араларны бүлә биләмәләр, чикләр,
Чиктән ары яшәүчеләр инде читләр.
Биләмәне чикләр куеп биләгән күк,
Табигатьне бүлгәләрлек киртәләр юк.
Куган җәнлек кайчак чаба чит җирләргә,
Туктау читен ауда кызган чит ирләргә.
Чик бозыла, уттай дөрләп гауга чыга,
Һәм кешеләр бер-берсенә ауга чыга.
Кулга керә сөңгеләр һәм җәя-уклар,
Уклар очын чорнап ала кызу утлар.
Җылы биргән утның вазифасы яңа –
Ул аңламый, кая атсаң, шунда яна.
Ул аяусыз, каба дошман шалашына,

Мәрхәмәт юк анасына, баласына.
Очкын чәчеп утлы уклар оча гына,
Урман кереп бара ялкын кочагына.
Гаепсездән ут аермый гаепләне,
Җитте җәннәттәй урманның соңгы көне.
Уттан кача исән калган барлык халык,
Диңгез буенда егыла тынсыз калып.
Атау үлде. Кара тынлык җирдә ята.
Һаман диңгез, һаман диңгез тирә-якта.
Ләкин кеше үлмәс әле, көймә ясар.
Акыл исән. Эзләр, яңа атау ачар.
Акыл исән. Көймәләр бар. Ләкин нигә,
Кемне жәлләп, исән җаннар газап чигә?..

Кырык бишенче ел Көнчыгышта.
Август башы. Сугыш ахыры.
Берлиннардан күкрәп килә инде
Тынычлык һәм Җиңү яңгыры.
Тарих сөйләү монда кирәкмидер,
Аны һәркем яхшы беләдер.
Бу минутта, бәлки, самолетка
Тарих яңа бомба эләдер...
Хиросима һич тә уйламады
Таш каберлек булып каласын.
Тыныч хезмәт белән көнен күрде,
Бикләмәде өйдә баласын.
Ә балачак – тынгысызлар иле,
Кул-аяклар җитез, караш шук.
Иң беренче алар күргәннәрдер
Күк йөзендә ап-ак парашют.
Нинди парашют бу кешесез, дип,
Торганнардыр, бәлки, аптырап,
Төшкән чакта бу кечкенә бомба,
Кара тышы белән ялтырап.
Ә самолет ерак инде... Кинәт

Бар дөньяга шартлап ут тулды.
Бер мизгелдә, бары бер мизгелдә
Бөтен шәһәр янып көл булды!
Табигать, син ничек түздең икән
Коточкыч бу вәхши җәбергә?
Ак парашют күргән балаларың
Әле һаман керә кабергә.
Самолетын алып кайтты исән
Шәп очучы Клод Изерли*.
Җан өшеткеч приказ үтәгәнен
Ул әлегә аңлап бетерми.
Еллар үтәр, ул да каргый башлар
Аяусыз һәм дансыз язмышын
Һәм ишетә башлар төн йокламый
Янып үлгән шәһәр тавышын.
Күз алдына килер һәр төн саен,
Бомба төшеп киткән минутлар,
Ә аннан соң урам буйлап чапкан,
Ике аяклы, тере, күп утлар.
Кычкырырлар алар ярдәм сорап,
Шәһәр тулы тере күмерләр.
Бу күмерләр аңа йокы бирмәс,
Төшләренә елап керерләр.
Ул минутлар искә төшкән саен,
Үкенергә мең кат өлгерер,
Колакларын каплап, юләрләнеп,
Үлем эзләп чыгып йөгерер...
Кеше юлы һәм ут юлы шулай
Кисештеләр еллар аркылы.
Үзе кылган эшне сыйдыралмый
Җимерелде кеше акылы...

---

* К. Изерли — Хиросимага атом бомбасы алып барган очучы. Соңрак акылдан яза.

Табигатьнең хакыйкате үз эчендә,
Һәрбер чәчәк, һәрбер бөҗәк үз төсендә.
Һәр ялгышның, һәр уңышның үз сәбәбе,
Һәрбер эшнең үз вакыты, үз сәгате.
Ләкин кеше бит сәбәпне кора белә!
Куркынычны кире якка бора белә!
Чорлар аша салып килгән үз юлында,
Үзе тапкан утның биге үз кулында.
Аңа акыл да табигать бераз биргән,
Биргәч-биргәч, нигә аны бик аз биргән?
Күпме әле җирдә чикләр һәм киртәләр?
Күпме әле канга буялган иртәләр?
Шахталарга яшерелгән корыч уклар,
Ук очында коточыргыч кызу утлар.
Борынгылар ут саклаган кебек, бүген
Коткар, акыл, бу уклардан тормыш күген!
Юк, табигать аз бирмәгән безгә акыл,
Ут белән ул һаман үлчи аның хакын.
Акыл җиңә утны, тормыш алга бара,
Уклар сына, утлар тына, җир яңара.
Ә башкача һич тә булмас, без – мәңгелек
Һәм табигать үзе тормыш бит иң элек.
Безне сынап, и табигать, ни эзлисең?
Сыный-сыный нинди эшкә әзерлисең?

Яшенгә кул сузган кеше
Исән калды, үлмәде ул.
Очы ут алган күсәкне
Җибәрмәде кысылган кул.
Беренче яңгыр тамчысы
Аны һушына китерде.
Чыланганчы нәни утны
Чыбык-чабыкка ул төрде.
Ә аннан соң саклап кына,
Адым саен эзләп утын,

Алып кайтты кабиләгә
Үзе җуйган яшен утын.
Төннәр буе йокламыйча
Кайткангамы, утны саклап –
Вафат булды кайтып җиткәч,
Ләкин үлде үзен аклап.
Мәңге сүнмәс хәтер булып,
Уты калды бу дөньяда –
Иң беренче Мәңгелек ут,
Иң беренче таш ояда.
Тормыш өчен яшеннән ут
Алып, башын салганнарга
Һәйкәл булсын Мәңгелек ут,
Хәтер булсын калганнарга...

*1985*

# Эчтәлек

## Шигырьләр

### Җыр башлаган идек


Авыл моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Ай, былбылым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Асылъяр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Бердәмлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Галиябану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Ерак вальс көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кара урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Идел бит ул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Җырчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Моңлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
«Оштырма» көе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Саба җырчысы Рисәнә Мостафинага . . . . . . . . . 18
Соң башланган җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Ташып чыккан моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Халкым җырлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Хафизәләм, иркәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Һаваларда очкан кошлар кебек . . . . . . . . . . . . 23


### Ил эчендә ил


Арба . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Гармунчы карт монологы . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Демократик мокытлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Казан утлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Вак мәшәкать . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Ил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кыйбла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Өмет . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31

Өч сүз . . . . . . 31
Маңкортка . . . . . . 32
Тел-нәсел . . . . . . 32
Милләт абруе . . . . . . 33
Ук очы . . . . . . 34

## Мәңгелек сер

Бердәнбер мәхәббәт . . . . . . 36
Гамь . . . . . . 37
Гөл...гә . . . . . . 38
Әйтелмичә калган сүз . . . . . . 39
Илаһи мәхәббәт . . . . . . 40
Кемдер тәрәзә кага . . . . . . 41
Җил сурәте . . . . . . 42
Күк һәм күңел йолдызлары . . . . . . 43
Күрешербез әле . . . . . . 44
Мәхәббәт сурәте . . . . . . 45
Сөю йолдызлары . . . . . . 45
Серләр . . . . . . 46
Торна . . . . . . 46
Сүнмәс тойгылар . . . . . . 47
Ут капкач . . . . . . 48
Утсыз калган учак . . . . . . 49
Хөкем . . . . . . 49
Февраль бураннары . . . . . . 50
Мең дә беренче тапкыр . . . . . . 51
Хушлашу . . . . . . 52
Рәшә . . . . . . 53
Хыял кызы . . . . . . 54
Янды өмет . . . . . . 56

## Җир баласы

Август ахыры . . . . . . 57
Автобиография . . . . . . 58
Ана сагышы . . . . . . 59
Бәхет кылы . . . . . . 60
Гомер һәм тормыш . . . . . . 60
Диңгез . . . . . . 61
Әни . . . . . . 62

Йөрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Кабер янында ана . . . . . . . . . . . . . . 64
Җан сулышы . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Картлык һәм хәтер . . . . . . . . . . . . . 65
Җил егете . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Җил оясы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Җир баласы . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Килер ул көн . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Күз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Кукмараның үзәк урамы . . . . . . . . . . 69
Моңлы җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Нуриягә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Сез гөлләр булырсыз . . . . . . . . . . . 72
Табыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Таңнар яктысы . . . . . . . . . . . . . . 73
Тормыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Тәрәзәдә ут . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Түрә булган, имеш... . . . . . . . . . . . 75
Урам этләре . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Урманда Кыш . . . . . . . . . . . . . . . 77
Хәнҗәр-каләм . . . . . . . . . . . . . . . 77
Хөснелбанат түти . . . . . . . . . . . . . 78
Хуш инде, авылым . . . . . . . . . . . . 79
Шәкәр апа . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Юл читендә кызлар . . . . . . . . . . . . 81
Язгы этюд . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Язмыш үче . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Мылтык . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Яшьтәш дустым Фидаилгә . . . . . . . . 83
Егетләр... . . . . . . . . . . . . . . . . . 84

Дүртьюллыклар . . . . . . . . . . . . . . 85

**Туган телем хәрефләре**

Туган телем хәрефләре . . . . . . . . . . 100
Алия рәсеме . . . . . . . . . . . . . . . . 101
Мәктәп белән саубуллашу . . . . . . . . 102
Әбиләр һәм бабайлар . . . . . . . . . . . 103
Гөлбикә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

Ничек? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Беренче кар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Җәйге төндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Чаңгы ярышында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Шикәрле чәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Халык язмышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Эт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Җимерелмәс манаралар . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Кечкенә хуҗа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Әйберләр фетнәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Маратның «намус көндәлеге» . . . . . . . . . . . . . 116

**Поэмалар**

Чокырча тавы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 120
Алмагачлар сагышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Фатыйма мәхәббәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Җинаять эше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Бакча . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Йорт иясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Ут . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 177

Литературно-художественное издание

*Шарипов Раниф*

**Вечная тайна**

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Г.З.Хисмәтуллина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.З.Шиһапова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.04.2005. Форматы 70×90 1/32.
Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма
табагы 7,02. Шартлы буяу-оттиск 7,31. Нәшер-хисап табагы 7,18.
Тиражы 1000 д. Заказ А-266.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.